Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

Татар фольклоры дәүләт үзәге

# *Татар халык иҗаты*

## ***Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре***

***(Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы)***

Икенче китап

Казан 2006

*Татар фольклоры дәүләт үзәгенең Гыйльми Советы карары белән басыла*

Төзүче: *Дәүләтшина Л.Х.*
Редколлегия: *Җәүһәрова Ф.Х.* (җаваплы редактор), *Мөхәмәдова Р.Г.*, *Бакиров М.Х.*

Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. (Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы). Икенче китап. – Казан: , 2006. – б.

Җыентыкта фольклор мирасын өйрәнүгә һәм аның тарихка, мәдәниияткә, язма әдәбиятка мөнәсәбәтле мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, фольклор үрнәкләре тупланган. Халкыбызның мәдәни мирасы, фольклоры белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

# Төзүчедән

Мәдәният министрлыгы каршында эшләп килүче Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәгенең фәнни эзләнүләр даирәсе елдан-ел киңәя бара. Россия Федерациясенең, Татарстан Респуликасының татарлар яшәгән районнарына экспедицияләр оештыру, кыр материалларын фәнни яктан эшкәртеп фольклор җыентыклары, монографияләр бастыру, семинарлар, конференцияләр уздыру Үзәк тарафыннан татар фольклорын өйрәнү һәм кире халыкка кайтару юнәлешендә эшләнгән эшләрнең бер өлеше генә. Ел дәвамында башкарылган эшләргә йомгак ясау, нәтиҗәләр чыгару һәм киләчәккә планнар кору инде матур гадәткә әверелгән еллык хисап-йомгаклау конференциясендә гамәлгә ашырыла. Ул гына да түгел агымдагы елда Үзәкнең 15 еллык эшчәнлегенә нәтиҗә ясалды. “Хәзерге фольклористиканың актуаль мәсьәләләре” дип аталган фәнни-гамәли конференциядә 15 ел дәвамында татар халкының традицион мәдәниятен өйрәнү өлкәсендә башкарылган эшләргә йомгак ясалып, алдагы елларга перспективалар билгеләнде.

Җыентыкта урнаштырылган конференция материаллары тупланмасы ике өлешкә бүленде. Беренче бүлек Үзәкнең 15 еллыгына багышланган конференция докладларыннан оешты. Биредә Үзәкнең оешу, эшләп китү тарихына, эш юнәлешләрен ачыклауга, халык мәдәниятен тикшерү өлкәсендәге актуаль мәсьәләләргә, фондларны тулыландыру мөмкинлекләренә, татар халкының традицион мәдәниятен өйрәнү перспективасына, үткән буыннар туплаган рухи байлыкны шәхескә җиткерү, уку-укыту системасына кертү, борынгы традицияләрнең бүгенге көндә яңару процессына багышланган мәкаләләр урын алды.

Җыентыкның икенче бүлеге йола комплексларын комплекслы анализлау, төрки шигырь төзелешенең фольклор формаларын ачыклау, фольклор һәм язма әдәбиятның үзара бәйләнешен күрсәтү, төрки халыкларның мифологик күзаллауларын өйрәнү, хореографик фольклористика юнәлешен гамәлгә кую, халык биюен фиксацияләү, милли уен коралларын укыту процессына кертү мәсьәләләренә багышланды.

Күрүебезчә, җыентыкның тематикасы фольклористиканың төрле өлкәләрен (теоретик, методик һәм гамәли) үз эченә ала. Гасырлар дәвамында камилләшеп килгән традицияләрнең югалуга таба йөз тотуы халыкның иҗади мирасын барлау, саклау һәм үзенә кайтару мәсьәләсенең гаять актуальләшүенә китерә, чөнки халык мәдәнияте турыдан-туры милләтнең үзбилгеләнү процессы белән бәйле. Халыкның сүз калыпларын, ышану-ырымнарын, йола-гадәтләрен, җыр сәнгатен, бию хәрәкәтләрен - гомумән мәдәниятен саклап калганда гына, милләтнең югалмавына ышанырга мөмкин.

# I БҮЛЕК

*Ф.Х. Җәүһәрова,*
ТФДҮнең директоры, КДУ доценты,
филол. фәннәре канд.

## *Татар фольклоры дәүләт үзәгенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге*

Мәдәният министырлыгы каршында оешкан Татар фольклоры дәүләт Үзәгенә 15 ел тулды. 15 ел кеше гомере, тарих хисабы белән үлчәгәндә, әлләни зур дата түгел, ләкин Рәсәй чынбарлыгы бизмәненә салып караганда, ул шактый зур. 2006 ел баскычыннан 1991 елга таба борылып артка карасак, бу арада илебезнең бик зур тарихи, сәяси, икътисади үзгәрешләр кичергәнен күрербез. Аларны биредә санап китү мәҗбүрияте юктыр, чөнки илебезнең һәр кешесе, ул үзгәрешләрдә турыдан-туры катнашып, авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәрде. Биредә шушы үзгәрешләр кысасында Үзәкнең оешу, эшләп китү тарихына да күз салу мәслихәт булыр.

80нче еллар ахырында Советлар Союзында яшәүче милләтләрнең үзбилгеләнү теләге кискен күтәрелеш кичерә башлый, шушы елларда бер төркем галимнәр, шул исәптән фольклорчылар да (В. Гусев, Н. Толстой, Д.С. Лихачев) фольклорны өйрәнү институтлары кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыгалар. Д.С. Лихачев 1987 елның көзендә КПСС Үзәк комитетына, халыкларның традицион мәдәниятен өйрәнүгә җитди мөнәсәбәт кирәклеген ассызыклап, хат белән мөрәҗәгать итә. Бу хатка җавап буларак Министрлар советы РСФСРның Мәдәният министрлыгына рус һәм башка халыклар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәге ачу мәсьәләсен хәл итүне йөкли, һәм 1990 елның июнь аенда Мәскәүдә Рус фольклоры республика үзәге ачылып эшли башлый. Шуннан соң Советлар Союзының кайбер республикаларында, РСФСРның күп кенә өлкәләрендә рус фольклоры үзәкләре, йортлары ачыла. Нәкъ менә шушы елларда бер төркем галимнәр, сәнгать эшлеклеләре Татар фольклоры үзәген оештыру турында сүз кузгаталар. Алардан (М.Х. Бакиров, К.М. Хөснуллин) инциативалы төркем төзелә, һәм Татар фольклоры дәүләт үзәгенең концепциясе әзерләнә. Анда Татар фольклоры үзәген төзү кирәклегенең алшартлары һәм сәбәпләре ачыклана, совет чорында чын, табигый фольклорның үзешчән сәнгать һәм “мәдәни агарту” эшенә кайтарылып калдырылуы һәм әлеге күренешнең традицион мәдәниятнең саклануына тискәре йогынты ясавы турында әйтелә. Советлар Союзында фольклористика фәненең төп игътибары фольклорны популярлаштыруга түгел, ә фәнни-тикшерү проблемаларына гына юнәлдерелүе тәнкыйтьләнеп, Татар фольклоры дәүләт үзәгенең оештырылу принциплары, эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм төзелеше ачыклана.

Юнәлешләр асылына:

- Россиянең татарлар яши торган өлкәләрен һәм Татарстанның үзенчәлекле фольклоры булган төбәкләрен системалы һәм комплекслы өйрәнү өчен башка оешмалар һәм вузлар катнашында даими эшләүче фольклор экспедицияләре оештыру;

- фольклор текстларын, шулай ук татар халык музыкасы һәм биюләренең, календарь-көнкүреш йолалары һәм бәйрәмнәренең аудио, видеоязмаларын туплау, эшкәртү, саклау фондын булдыру;

- халык иҗатының төрле жанрлары һәм музыка, бию, йола фольклоры буенча фәнни-популяр җыентыклар бастыру;

- халык иҗаты җәүһәрләре хисабына профессиональ артистлар һәм коллективларның репертуарларын баету мөмкинлекләре тудыру;

- татарларның төрле этник төркемнәре иҗатына мөнәсәбәтле теоретик, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү алына.

1991 елның октябрь аенда Татарстанның Министрлар кабинеты карары буенча Республиканың Мәдәният министрлыгы каршында шушы концепциягә нигезләнеп, Татар фольклоры дәүләт үзәге төзелә. Үзәк үзенең беренче адымнарын, даими эшләүче фәнни экспедиция группасы төзеп, Россиянең төрле төбәкләренә чәчелгән татарлар янына юл тотудан башлап җибәрә.

15 ел эчендә оештырылган экспедицияләрнең санын гына исәпләсәң дә, алар утыздан артып китә. Үзәкнең эш юнәлешләрен билгеләп, фольклор фестивальләре үткәреп, халыкка мәдәни традицияләрен кире кайтаруда, инде халыкның көндәлек яшәешеннән төшеп калып баручы тальян гармун, курай, кубыз кебек уен коралларын популярлаштыру максатыннан “Гармунчылар”, “Курайчылар һәм кубызчылар” конкурсларын оештырып җибәрүдә Үзәкнең беренче директоры, фольклорчы галим һәм композитор Котдүс Мирзасалих улы Хөснуллин күп көч куя. Ул җитәкләгән елларда Үзәк эшенең юнәлешләре билгеләнә, видеодокументлар, сирәк кулъязма һәм басма китаплар фондына нигез салына, төбәкләр белән элемтәләр урнаштырыла, “Әстерхан татарлары фольклоры”, “Урал буе татарлары фольклоры” кебек зур конференцияләр уздырыла. “Татар халык музыка иҗаты” (Р.А. Исхакова-Вамба), “Татар халык киемнәре” (Р.Г. Мөхәмәдова), “Керәшеннәр. Тел һәм йола үзенчәлекләре” (Ф.С. Баязитова), “Туйлар, туйлар” (Д.Б. Рамазанова), “Татар халык бию көйләре” (Р.А. Исхакова-Вамба) “Татар көйләренең баян өчен эшкәртмәсе” (Р. Валиев), “Хромкада уйнарга өйрәнү өчен үзөйрәткеч” (Р. Валиев), “Шигърият дөньясына сәяхәт” (М.Х. Бакиров), “Мөнәҗәтләр һәм бәетләр” (төзүчесе К.М. Хөснуллин) кебек хезмәтләр дөнья күрә.

Биредә Үзәкне оештыруда һәм аның эш юнәлешләрен билгеләүдә үзенең зур көчен, сәләтен биргән Котдүс Мирзасалих улына рәхмәт әйтү урынлы булыр. Әле күптән түгел генә аңа 65 яшь тулды. Аны гомеренең бу датасы белән чын күңелдән тәбриклибез. Үзе авыру сәбәпле бүген безнең арада булмаса да, туганнары аркылы рәхмәт һәм котлау сүзләрен җиткерергә телибез. Үзәкнең 15 еллык эшчәнлегендә аның өлеше, һичшиксез, зур һәм лаеклы урын били.

Соңгы елларда Фольклор үзәге үзенең эшен планлаштырылган, системалы эзләнүләр таләп итүче программалар кысасында алып бара. Шундый программаларның берсе – “Казан арты татарлары фольклоры: үткәне һәм бүгенгесе”. Бу җидееллык программа үз эченә 2002-2009 елларны ала.

Әлеге программа буенча Үзәкнең даими эшләп килүче экспедицион төркеме Татарстанның Кукмара, Балтач, Саба, Теләче, Балык Бистәсе, Мамадыш, Арча, Әтнә, Биектау, Лаеш, Марий Эл Республикасының Бәрәңге районнарында эшләде. Эш барышында фольклор традицияләренең сакланышын тикшерү һәм буыннан буынга тапшырылу механизмнарын ачыклау максатыннан махсус методика булдырылды. Шулар нәтиҗәсендә Казан арты авылларында Сабантуйның XX гасыр кысасында кичергән үзгәрешләрен билгеләрлек материаллар тупланды, этнографлар тарафыннан халык көнкүрешеннән төшеп калган дип исәпләнүче Сабантуй алды йолалары: “Карга боткасы”, “Зәрә боткасы” бәйрәмнәренең хәзер дә саклануы ачыкланды, аларга мөнәсәбәтле видеодокументлар әзерләнеп фондка тапшырылды. Моңа кадәр галимнәр тарафыннан татарларның өмә комплексында билгеләнми килгән орчык өмәсе ачыкланды һәм видеодокумент буларак Үзәк фондында үз урынын алды.

Әлеге эзләнүләр нигезендә халыкта сакланып калган Сабантуй бәйрәме комплексы йолаларыннан “Нәзер аты”, “Бирнә тәбәсе” кебекләренең дә хәзер дә Казан арты авыллары көнкүрешендә яшәве ачыкланды. Бу урында әлеге йолаларга видеодокументлар әзерләү эшендә үзәккә зур ярдәм күрсәтүләре өчен Саба муниципаль районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Хафизов Миннехәт Гатовичка, районның Кече һәм Олы Шыңар муниципаль җирлеге клубы хезмәткәрләре Садыкова Фәридә, Билалова Әлфия, Рабгутдинова Гөлсинәгә зур рәхмәтләр ирештерәсебез килә. Халык мәдәниятен белеп, яратып эшләүче коллегаларыбыз ярдәмендә Үзәкнең видеофонды “Боз озату”, “Нәзер аты”, “Бирнә тәбәсе” кебек йолаларның оригиналь (фәнни телдә әйтсәк визуаль антропология материалы буларак) халыкта ничек сакланып калган шул килеш төшерелгән версияләре белән баетылды. Бу уникаль язмалар киләчәктә фольклор фәне чыганагы буларак кына түгел, ә социология, культурология, тарих фәннәре өчен дә зур әһәмияткә ия документлар булырлар дип ышанабыз. Хәзерге көндә дә Фольклор үзеге визуаль документлар туплау юнәлешендә эшен дәвам итә. Мәсәлән, балаларның хәзерге уеннарына һәм имләү-ырымнарга караган яңа видеодокументлар 2006 елда Үзәк фондында лаеклы урын алды.

“Казан арты татарларының фольклоры: үткәне һәм бүгенгесе” программасы буенча экспедицион эзләнүләрдән тыш, төшеп калган йола-гадәтләрне торгызу эше дә алып барыла. Мәсәлән, 2002 елда Кукмара районына оештырылган экспедиция рамкаларында район авыллары җыеннары турында да мәгълүматлар тупланды. Экспедиция нәтиҗәләрен галимнәр район үзәгендә оештырылган фәнни-гамәли конференциядә халык белән рәхәтләнеп уртаклаштылар. Шушы конференция резолюциясендә районның кечкенә авылларында җыеннар уздыру традициясен торгызу мәсьәләсе дә каралды, һәм 2004 елдан башлап Төркәш җыены (бу җыенга районның 4 авылы керә) уздырыла башлады.

Болардан тыш Кукмара район мәгәриф бүлеге бәлән Үзәк арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелеп, район мәктәпләрендә фольклорны фәнни юнәлештә өйрәнү эше башланып китте. Бу юнәлеш матур гына нәтиҗәләр дә бирә башлады. Гомумиләштереп әйтсәк, “Казан арты татарларының фольклоры: үткәне һәм бүгенгесе” программасы үзен шактый аклап килә. Бу программа кысаларында Казан арты авылларының

изгеләштерелгән урыннары, аларга бәйле ышану, ырым, йола комплекслары буенча материаллар тупланды. Шуларга таянып “Сабантуй”, “Каз өмәсе”,”Кичке уен”, “Аулак өй”, “Бәбигә исем кушу”, “Никах”, “Карга боткасы” кебек йола бәйрәмнәре турында методик фильмнар әзерләнде.

Фольклорны җыеп бетерү мөмкин түгел, чөнки халыкның һәр көне үзенчәлекле фольклоры белән үрелеп бара, ул халыкның теле, үзаңы сакланганда, мәңгелек дәвамчыл процесс. Ләкин шунысы да ачык: фольклор мирасын җыюга никадәр масштаблы һәм комплекслырак якын килсәң, халык мәдәни традицияләрен киләчәк буынга шулкадәр тулы канлырак итеп саклап тапшыру мөмкинлеге арта бара. Бүгенге көндә Үзәк галимнәре нәкъ менә шуны күз алдында тотып эшләргә тырышалар да. Әлбәттә, Үзәкнең санаулы гына галимнәре белән төрле планда зур, масштаблы эзләнүләр алып бару мөмкин түгел. Ләкин шулай да район мәдәният бүлекләре ярдәме белән эшнең нәтиҗәлелеген арттыру мөмкинлеге юк түгел. Мәсәлән, Мамадыш муниципаль районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Спиридонов Степан Петрович Үзәкнең экспедицион төркемен, районда эзләнүләр башланганчы, авыл клубы мөдирләре белән очраштырды. Бу очрашуда экспедициянең максат-бурычлары, эш планнары турында сүз алып барылды. Менә шушы очрашудан бирле Үзәкнең район авыллары белән элэмтәләре һаман да өзелми. Без бергәләп халык мирасын туплау эшендә. Бу уңайдан Степан Петровичның үзенә дә керәшен татарлары фольклорыннан бай материаллар туплауда даими ярдәм итеп килүе өчен зур рәхмәтләребезне җиткерәсебез килә. Ул - халык традицияләрен чын күңелдән яратучы, аңлаучы һәм популярлаштыручы. Киләчәктә дә бергәләп, нәтиҗәле эшләребезне дәвам итеп, халкыбызның искиткеч матур күңел җәүһәрләрен саклап калуда үз өлешебезне кертә алырбыз дип ышанабыз.

Фольклор үзәге кабул иткән программалар алда күрсәтелгәннәр белән генә чикләнми. Тагын бер үзенчәлекле программа буларак “Рәсәй Федерациясе регионнарында яшәүче татарлар фольклоры. Традицияләр һәм үзгәрешләр” программасын атарга кирәктер. Бу программаның төп максаты – татар фольклорының башка мәдәни мөхит тирәлегендә сакланышын өйрәнү. Әлеге гамәл кысаларында Үзәк галимнәре Россиянең Идел буе регионнарында яшәүче татарларга экспедицияләр белән чыктылар. Әстерхан шәһәрендә беренче мәртәбә төбәктә яшәүче татарларның фольклорын өйрәнү һәм саклау мәсьәләсен күтәргән Өлкә халык иҗаты үзәге белән берлектә фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Конференциядә уртак җыентык чыгару мөмкинлекләре, татар фольклор коллективларын яңадан торгызу мәсьәләләре күтәрелде.

2006 елның декабрь аенда Түбән Новгород өлкәсенең Сергач шәһәрендә “Туган як” татар милли мәдәни автономиясе белән берлектә “Түбән Новгород өлкәсе татарлары фольклоры. Өйрәнү һәм саклау мәсьәләсе” исемле конференция уздырылачак. Шушындый ук конференция 2004 елда Свердловск өлкәсе Красноуфим шәһәрендә үтте. Әлеге конференция кысаларында өлкәнең татарлар яшәүче өч район вәкилләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, татар авылларының клуб җитәкчеләре һәм Свердловск өлкәсе фольклор йорты хезмәткәрләре катнашты. Конференция нәтиҗәсендә төбәк татарларының мәдәниятен саклауга игътибар шактый артты, Өлкә фольклор йорты ел саен татар фольклорына бәйле семинарлар

үткәрә башлады. Бүгенге көндә өлкә фольклор йорты белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзелде.

Үзәкнең фәнни эшчәнлегендә тагын бер мөһим юнәлешләренең берсе – җыелган фольклор материалларын саклау, аларны системалаштыру. Бүгенге көндә бу мәсьәләдә эшләр шактый җайга салынды. Үзәк мирасханәсендә җиде фонд барлыкка китерелде, алар даими рәвештә тулыландырылалар. 2003 елда Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Үзәктә фольклор үрнәкләрен консервацияләү өчен заманча җиһазландырылган бүлек оешты, биредә фондларга кергән һәр документ, аудио, видеоязма, фотокадр цифрлана һәм юллама белешмә төзелеп теркәлә. Үзәкнең фонд бедән эшләү юнәлеше моның белән генә чикләнми. Агымдагы елда “Татар халкының традицион мәдәнияте” исемле электрон каталогын төзү эше дә башланып китте. Бу эшнең җитәкчесе Г.М. Ханнанова, аның кул астында каталогка кертелүче һәр саклау берәмлеге җитди фәнни атрибуция үтә, системалаштырыла. Шуны да ассызыкларга кирәк: каталогны гамәлдә куллану өчен безнең алда хәзергә бер зур киртә бар. Ул - мондый каталоглар өчен татар телендә төзелгән программаның булмавы. Мондый программаны булдыру, ким дигәндә 300 мең сум чыгымнар таләп итә. Бу шартка карамастан Үзәктә каталогның контентын әзерләү эше дәвам итә. Киләчәктә программа белән эшләр көйләнеп, татар традицион мәдәнияте каталогы белән интернет аша танышу мөмкинлеге булыр һәм татар халкы җәүһәрләрен дөнья мәдәни казанышларына интеграцияләү юллары ачылыр дип өметләнәбез.

Халык мәдәни традицияләрен өйрәнү – гаять күпкырлы эш. Ул, әлбәттә, академик тикшерүнеләрне дә, гамәли юнәлешле эзләнүләр алып баруны да таләп итә, шунлыктан Татар фольклоры дәүләт үзәге галимнәре ике юнәлешкә дә игътибар бирергә мәҗбүрләр. Бүгенге көндә Үзәктә эшләп килүче олуг галимнәребездән М.Х. Бакиров “Татар фольклоры жанрлары спецификасы” исемле теоретик хезмәтен төгәлләде, шул ук вакытта “Татар туйлары” исемле китап әзерләде һәм аны хәзерге туй мәҗлесләрен үткәрү сценарийлары белән баетты. 2005 елда Р.Г. Мөхәмәдова “Керәшен татарлары киеме” исемле китап-альбомын, заманча стилизацияләнгән кием модельләре белән тулыландырып, халыкка кайтарды. Үзәкнең музыка фольклоры белгече Й.Н. Исәнбәт татар музыка фольклоры өлкәсенә мөнәсәбәтле әйтелгән фәнни фикерләр тупланмасын әзерләү эшен дәвам итә. С.М. Гыйләҗетдинов Беренче бөтендөнья сугышы әсиренең бәетләр җыентыгын “Әсир дәфтәре” исеме белән дөньяга җиткерде, 2006 елда Үзәкнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар фонды тасвирламасын эшләп бетерде. Ф.И.Урманчеев татар мифологиясенең энциклопедик сүзлеген төзү эшен дәвам итә. Гомумән бүгенге көндә Фольклор үзәгендә катлаулы мәсьәләләрне чишә алырлык иҗади коллектив оешты дип әйтергә була. Үзәктә төрле буын галимнәре кулга-кул тотышып, уртак максатларга ирешү өчен бергәләп эшлиләр. Алар арасында: 2 фәннәр докторы, 6 кандидат, 3 аспирант бар.

Үзәктә әзерләнгән хезмәтләрне тикшерү, бастыру мәсьәләләрен хәл итүче Гыйльми совет даими эшләп килә. Төрле оешмалар һәм югары уку йортлары белән эләмтәләр елдан-ел ныгытыла бара. Менә инде өч ел рәттән Фольклор үзәгенең экспедицион төркеме җәйге планнарын КДУның татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары белән берлектә үти. Казан дәүләт университеты студентлары катнашында октябрь айларында

экспедиция йомгакларына багышланган фольклор конференциясе һәм кичәләре үткәрү инде гадәткә керде. Казан дәүләт консерваториясе укытучылары да безнең экспедицияләрдән читләшмиләр.

Һичшиксез, алда саналган эшләр барысы да халкыбызның йөзен, менталитетын саклау максатларыннан моннан 15 ел элек төзелгән Татар фольклоры үзәге концепциясенә туры китерелеп эшләнә. Ләкин концепциядә планлаштырылган бар юнәлешләр гамәлгә ашырылып бетте дияргә шактый иртә. Үзәкнең 10 еллыгын билгеләп үткәндә ассызыкланган “Татар халык иҗаты” журналын булдыру мәсьәләсе хәл ителми кала бирә. Югыйсә бөтен татарга халыкның фольклорын, сөйләш үзенчәлекләрен, мәдәни традицияләрен (шул исәптән халык җыр, бию, киенү, бизәнү сәнгатьләрен) саклау мөмкинлекләрен сөйләүче бер журнал чын мәгънәсендә кирәк, һәм ул әлләни зур чыгымнар сорамый да. Күрәсең, без үзебез татарлыгыбызны кабат күрсәтеп, кемнәндер журнал ачып бирүен көтәбез.

Хөрмәтле галимнәр, сәнгать әһәлләре, безнең фикеребезчә, безгә кичекмәстән инициативалы төркем оештырып, булачак журналның структурасын, юнәлешен күз алдына китереп, концепциясен эшләп, тиешле Министырлыкка мөрәҗәгать итү кирәк. Мондый журнал без галимнәрдән бигрәк, бүген халык белән ничек эшләргә белмичә йөдәп утыручы, атнага бер тапкыр клубын кичке дискотекага гына ачучы клуб мөдирләренә дә, халык фольклорын өйрәнәбез дип, ел саен аулак өй, кичке уен күренешләрен күрсәтүдән башканы күз алдына китерә алмый аптыраган күп кенә мәктәп укытучыларына да кирәк бит! Журнал төбәк татарларына үз җирле материалларын һәм аларның этнолингвистик аспектларын ачыкларга да, көнкүрештән төшеп калган музыка уен кораллары турында сөйләп, бию-җырларыбызны күрсәтеп, халкыбызның телен, мәдәниятен сакларга да мөкинлекләр тудырыр иде. Миңа калса, Фольклор үзәге белән бергәләп Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИ һәм Ш. Мәрҗәни ис. Тарих институты да күтәрелсә, бу эш башкарылып чыкмаслык түгел. Әлбәттә, журналны булдырып, барлык проблемаларны хәл итәрбез дип әйтү беркатлылык булыр иде. Бүгенге көндә татар фольклористикасы алдында торган мәсьәләләр шактый күп, һәм аларның сәбәпләре тирәндә ята.

Иң актуале - халык мәдәниятен комплекслы тикшерү өчен белгечләр җитмәве. Музыка фольклоры өлкәсендә татар телле яшь белгечләрнең бик аз булуы үзен нык сиздерә. Халык бию сәнгате өлкәсендә бер генә белгечнең дә булмавы нинди зур мәдәни мирассыз калу куркынычы алдында торуыбызны еллап түгел, көнләп әйтә. Алардан тыш халык мәдәниятенең хәзерге яшәешен, фольклорын өйрәнерлек әзерлекле белгечләребез дә җитми. Халык тыюларының, ырым-ышануларының семантикасы, этимологиясенә керерлек галимнәребез дә күренеп тормый. Башлыча, фольклор фактларын филологик, музыкаль текст буларак барлау, җыентыкларга теркәү эше белән шөгыльләнәбез. Сүз дә юк, алар да бик җитди һәм кирәкле. Ләкин алар белән параллель тирәнрәк катламнарны, теге яисә бу текстның халык яшәешендәге вазыйфасын, традициясен, саклану һәм трансформацияләнү сәбәпләрен ачыклауга юнәлтелгән эзләнүләр дә кирәк.

Ничек кенә булмасын, Татар фольклоры дәүләт үзәге үзенең 15 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә киләчәккә оптимизм белән карый, күз уңында тоткан планнырын үтәп, югары үрләрне яулау теләгендә тора.

*Ф.И. Урманче,*
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре,
ТӘҺСИнең халык иҗаты бүлеге мөдире,
филол. фәннәре д-ры, профессор

## *Борынгы традицияләрнең яңаруы*

Соңгы ун-унбиш елда илдә, Русиядә һәм Татарстанда яшәүче халыклар тормышында бик күп төрле, катлаулы, каршылыклы үзгәрешләр булуы турында байтак сөйләнде, язылды һәм язылып килә. Рәсми нигездә җитәкче даирәләр әлеге үзгәрешләрнең уңай нәтиҗәләре турында сөйләргә һәм язарга яратсалар, халыкның икенче бер төркеме, иң зур күпчелеге, башлыча интеллигенция, зыялылар, язучылар, галимнәр, гади халык, бигрәк тә өлкән буын вәкилләре хәзерге тормыш шартларын, һич бетмәс реформаларны каһәрлиләр, аларның нәтиҗәләреннән зарланалар. Мондый күренешләр һәр дәвердә булган, бар һәм булачак дип кенә дә тынычланып булыр иде. Бик күпләр, бигрәк тә Русиядә, шулай эшли дә!.. Тик әлеге мәсьәләнең икенче – тагын да катлаулырак ягын да истән чыгарып булмый. **Безнең көннәрдә тормышның алга баруы, гомуми эволюция бик нык тизләште.** Нәкъ әнә шуның нәтиҗәсе буларак, илдә көн дә саен диярлек һич уйланылмаган, көтелмәгән, нигездә фаҗигале вакыйгалар-хәлләр әледән-әле кабатланып тора. Мондый хәл-вакыйгаларның байтагы Галәм – Җиһан – Космостагы зур һәм принципиаль үзгәрешләр, катлаулы процесслар белән турыдан-туры бәйләнгән дип ышанучыларның саны да торган саен арта бара. Коточкыч җир тетрәүләр, су басулар, цунамилар белән бәйле ураганнар нәтиҗәсендә йөзләгән, меңләгән, берничә йөз меңнән артык кешеләр һәлак була. Мондый трагик вакыйгалар элегрәк тә кабатланып торган. Тик безнең заманда аларның күләме дә зуррак, кабатлануы да ешрак, корбаннарының саны да күбрәк.

Җир дип аталган планетада гомер кичерүче адәм балаларының көндәлек тормышы Югары Күк, шундагы Ай, Кояш, Йодызлар белән турыдан-туры бәйләнгән дигән карашларның инеш башы борынгы Бабил – Вавилониягә, б.э.к. 2 меңъеллыкның башында – 539 елда хәзерге Гыйрак җиредә урнашкан ил мифологиясенә барып тоташа. Ни хикмәттер, берара, конкретрак алганда, Совет чорында (1917-1990 еллар) «оныттырылып» торган әлеге карашлар соңгы унъеллыкларда яңадан «терелә-тернәкләнә» һәм халык, хәтта зыялылар арасында да ифрат та киң таралыш таба. Шулар арасында фән буларак беркайчан да танылмаган астрология, эзотерика, сихер һәм сихерчелек, магия, төрле юрау-юрамалауларга, ырымнарга ышану һәм шул нигездә хәрәкәт итү халыкның көндәлек тормышының аерылгысыз бер өлеше булып әверелде. Астрологик фаразларны, әйтик, «Вечерняя Казань» көн дә саен, ә инде иң абруйлы гәзитләрдән «Мәдәни җомга» атна саен бастырып бара. Һәм бик күпләр аларны кызыксынып укыйлар.

Күрсәтелгән «измнар» киң таралып, халыкның рухи тормышында җитди роль уйнавы совет чорында капиталистик, буржуаз мәдәниятнең җимерелүенең конкрет чагылышы дип игълан ителә иде[1]. Хәзер безнең Русия һәм Татарстан җәмгыятендә дә шундый ук хәл күзәтелә икән, димәк, бездә дә традицион мәдәният, халык мәдәнияте тәмам җимерелеп таркалу юлына аяк баскан булып чыга. Һәм моның, чыннан да, шулай булуын без үзебез дә көн дә саен күреп торабыз кебек. Көндәлек тормышта булмаса – тәүлек буе телевизор экраннарыннан.

Бүгенге көн тормышын Ислам тәгълиматыннан алынган «мәхшәр» сүзе белән билгеләү шулай ук киң таралган күренешләрнең берсе булып әверелде. Махсус сүзлектә әлеге сүз түбәндәгечә аңлатыла. «**Мәхшәр** 1) җыелу. 2) *дини* Динчеләр уенча, кыямәт көнендә яңадан терелгән кешеләрнең җыелу урыны яки вакыты»[2]. Шул ук җөмләдә кулланылган «кыямәт» сүзе дә турыдан-туры дини тәгълиматлар белән нисбәтле: «**Кыямәт** 1) *дини* ахирәт көне, дөнья беткән көн. 2) Тавыш, гауга, шау-шу, тәртипсезлек»[3]. Соңгы чиктә, биредә кулланылган «ахырзаман» сүзе дә шул ук фикерләрне раслый булса кирәк: «**Ахыр заман** 1) *дини.* Имештер, дөнья бетәр алдыннан булган вакыт, дөнья ахыры; 2) артык тәртипсезлек, ыгы-зыгы турында»[4].

Китерелгән сүзләрнең барысы да безнең көннәр вәзгыяте белән шулай ук турыдан-туры бәйләнгән. Һәм моны, дөресен әйткәндә, беркем дә инкарь итә алмый. Мәсьәләнең асылы хәтта анда гына да түгел. Әлеге сүзләрнең барысы да хәзер нигездә тирән һәм үзенчәлекле дини мәгънәләрен югалтып, безнең көндәлек тормышта гади һәм гадәти сүзләр буларак кулланыла башладылар. Бу хәл, үз чиратында, көндәлек тормышның, безнең көннәр чынбарлыгының көзгесе булган язма әдәбиятта да чагылыш таба. Хәзерге шигърияттә әлеге процессларның ничек гәүдәләнүе турында шушы юллар авторы, дистәдән артык мәкаләләрдән тыш, махсус өч монография дә язып чыгарган иде. Бу очракта сүз «Дастаннарга лаек замана. Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия»[5]; Татарстанның Халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь»[6] һәм шулай ук Татарстанның Халык шагыйре Роберт Миңнуллин шигърияте турындагы «Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре»[7] дигән хезмәтләр турында бара.

Ә инде бүгенге проза әсәрләренә килсәк, анда без тагын да үзенчәлеклерәк күренешләргә тап булабыз. Соңгы елларда басылып чыккан проза китапларының, кайберсенең генә булса да, исемнәренә генә игътибар итеп карыйк. Зиннур Хөсниярның роман-дилогия, повесть һәм хикәяләрдән

---

[1] Оккультизм // Атеистический словарь. – М., 1983. - С. 349-350.

[2] Хәмзин К.З. Гарәпчә–татарча–русча алынмалар сүзлеге / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. – Казан, 1965. – Б. 338-339.

[3] Шунда ук. – Б. 217.

[4] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. - Т. 1. – Казан, 1977. – Б. 88.

[5] Урманче Ф.И. Дастаннарга лаек замана. Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия / Ф.И. Урманче. – Казан, 1990.

[6] Урманче Ф.И. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. Татарстанның Халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш / Ф.И. Урманче. – Казан, 2002.

[7] Урманче Ф.И. Роберт Миңнуллин: Шигъри осталык серләре / Ф.И. Урманче. – Казан, 2005.

торган китабы «Эттән туган» дип атала[1]. Дилогия булгач, димәк, роман ике китаптан тора: «Терсәк сугышы» һәм «Эттән туган». Китапка кергән повестьның исеме бик тә үзенчәлекле: «Кәҗә йөри кыектан». Китап белән таныша башлагач та, «Ай-һай, бер унбиш-егерме ел элек мондый исем белән китап чыгарып булыр идеме икән?» – дип уйлап куясың. Алай дисәң тагы! Зиннур Хөснияр «эттән туган» сүзләрен безгә күптән мәгълүм кире мәгънәсендә генә куллана. Ә инде тирәннәнрәк уйлап карасаң, мәсьәлә бөтенләй башкача хәл ителә икән. Халык иҗатында аерым мифологик персонаж булган **эт** һәрвакыт диярлек уңай герой булып йөри. Өстәп тик шуны гына әйтәсе кала: Борынгы Шәрекътә безнең эрага кадәрге XV-X гасырларда оешкан һәм **Зәрдөштлек** дип аталган дини-мифологик системада изгелек ягыннан эт кешедән соң икенче урында торган[2]. Икенче төрле итеп әйткәндә, Зәрдөштлектә эттән туу бер дә кире мәгънәгә ия булмагандыр дип уйларга кирәк.

Солтан Шәмси китабының «Күк капусы ачылса...» дигән исемен укыгач та[3], «ә ачылмаса?» – дип сорап куясы килә. Хәер, автор үзенең «фән буларак танылмаган» һәм югарыда күрсәтелгән оккульт, эзотерик күзәтүләре нигезендә түбәндәге нәтиҗәләргә килә: «Хәзерге көндә кешелек дөньясы гадәттән тыш озын һәм авыр тоелган, адәми затны бастырып торган, зур корбаннар таләп иткән Тимер Гасырдан чыкты. Дөресен әйтергә кирәк, кеше аннан гаять кырысланып, кыргыйланып, рухияттән, Раббыбыздан бик нык ераклашып, матдиятчелеккә тәмам кереп баткан хәлдә чыкты. Хәзер Җирдә елдан-ел рухият арта, дөнья торган саен яктыра, камилләшә барачак. Бу яктан бернинди дә шик-шөбһә, өметсезлек, икеләнү булырга тиеш түгел»[4]. Шулай гына булсын иде дә бит! Тик кайчан? Әлегә көндәлек тормышта фаҗига-бәхетсезлекләр бер-берсен куа килүен дәвам итә.

Галимҗан Гыйльмановның зур гына шау-шу, төрле бәхәс-дискуссияләр уяткан һәм «Албастылар» дип аталган хыялый кыйссасы хәзерге проза әсәрләре арасында иң күп укыла торган, соң дәрәҗәдә мавыктыргыч әсәрләрдән берсе булса кирәк[5]. Бу әсәр белән ихлас күңелдән танышып, аның аның турында махсус мәкаләләр дә яза башлагач, үтә үзенчәлекле һәм кырыс закончалыкларга тап буласың. Язучы үзенең әсәрен «хыялый кыйсса» дип атый. Хыялый икән, димәк, ярым-фантастик әсәр. Һәм бу, чыннан да, шулай.

Борынгы грек һәм рим әдәбиятын өйрәнүчеләр арасында антик чор шагыйре Публий Овидий Назонның «Метаморфозы» дигән китабын шул чор, ә бәлки борынгырак дәверләрнең дә мифларын берләштергән грандиоз әсәр дип бәяләү дә бар[6]. Без биредә Галимҗан Гыйльманов әсәрен Овидий Назонның «Метаморфозы» дигән китабы белән бер дәрәҗәгә куярга җыенмыйбыз, әлбәттә. Мәсьәлә бөтенләй башкада. Әмма ни хикмәттер, язучының «Албастылар» кыйссасын укый башлагач ук, минем хәтергә антик

---

[1] Хөснияр Зиннур. Эттән туган. – Казан, 2005.

[2] Рак И.В. Мифы древнего и раннесредневекового Ирана. Зороастрийская мифология / И.В. Рак. – СПб., 1998.

[3] Шәмси Солтан. Күк капусы ачылса... / Солтан Шәмси. – Казан, 2006.

[4] Шунда ук. – Б. 21.

[5] Гыйльманов Г. Албастылар / Г. Гыйльманов. – Казан, 2003.

[6] Публий Овидий Назон. Любовные элегии. Метаморфозы. Скорбные элегии/ Публий Овидий Назон. – М., 1983.

шагыйрьнең шул китабы килде. Һәм бу үзе табигый бер күренеш булса кирәк, чөнки Г. Гыйльмановның «Албастылар»ында төрки-татар мифологиясе атрибутларының, барысы булмаса да, бик зур күпчелеге чагылыш таба. Әлеге әсәрдә нindидер гәүдәләнеш тапкан гайре табигый күренешләр нигезендә хәтта мифологик сүзлек төзергә мөмкин. Башка фәнни һәм әдәби чыганаклардан да киң файдаланып, билгеле.

Алай дисәң тагы! Хәзерге шигърияттә борынгы мифларның чагылышы турында югарыда әйтелгән иде инде. Карап торсаң, хәзерге татар прозасында да шул ук хәл икән. Конкретрак итеп әйткәндә, Г. Гыйльмановның «Албастылар»ы гына түгел, аның башка әсәрләре дә, әйтик, үтә дә үзенчәлекле, шулай ук ярым фантастик, ярым мифологик рухта язылган «Оча торган кешеләр»е дә; башка язучылардан Н.Гыйматдинованың «Болан», М. Галиевнең «Нигез» һ.б. шул ук рухта язылган.

Югарыда күрсәтелгән һәм биредә саналмаган хәзерге язма әдәбият әсәрләренең байтагын бүгенге конкрет тормышның, чынбарлыкның чагылышы дип карау – шулай ук табигый күренеш булса кирәк. Һәм мәсьәлә моның белән генә дә чикләнми. Соңгы елларда язма әдәбиятның мифологизмы мәсьәләсе хәзерге әдәбият белеменә дә үтеп керә; бу проблема буенча мәкаләләр, монографияләр һәм диссертацияләр языла. Тема бөтенләй һәм принципиаль яңа булганга, әлеге теоретик хезмәтләр дә зур кызыксыну уята.

Китерелгән һәм биредә телгә алынмаган фактлар җитди бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: борынгылык, халыкның шул чорлардагы карашлары, Дөньяны һәм көндәлек тормышны күзаллавы – безнең көннәрдә махсус күзәтү һәм фәнни яктан тирәнтен өйрәнү объекты булып әверелә бара. Бу процесс алга табан тагын да көчәер һәм тирәнәер дип уйларга кирәк. Моның күзгә күренеп торган объектив һәм бик тә мөһим сәбәпләре дә бар. Алар, гомумиләштереп әйткәндә, түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Билгеле булганча, Советлар Союзы, СССР чорында аерым, бигрәк тә төрки халыкларның борынгы тарихын, әдәбиятын, сәнгатен, көндәлек тормыш үзенчәлекләре - этнографиясен өйрәнү, турыдан-туры тыелмаса да, һич тә хупланмый иде. Әйтелгәннәр халыкның рухи дөньясын, дастаннарын, бәет-мөнәҗәтләрен, бигрәк тә Ислам диненә дә билгеле бер мөнәсәбәте булган ышану-ырымнарын, йолаларын, мифологиясен өйрәнүгә дә, беренче чиратта, кагыла иде.

Җылы җилләр, тыйнак, бик тартынып кына булса да, уңай якка да исә башлагач, борынгылыкка игътибарны көндәлек тормыш, безнең бүгенге чынбарлык үзе тартып чыгарды һәм без, язучылар, галимнәр, гомумән – зыялылар алдына яңа һәм ифрат та катлаулы бурычлар «өеп куйды». Югарыда сөйләнгәннәрнең барысы да әнә шул бурычларны үтәү юнәлешендәге мөһим адымнар дип кабул ителергә тиештер.

Сөйләнгәннәрдән шундый бер җитди сорау да калкып чыга: безнең көннәрнең рухи тормышында халыкның үз иҗаты, үзе иҗат иткән әсәрләр нинди дә булса урын алып торамы? Әллә алар бөтенләй юкка чыкканмы? Бу, билгеле бер дәрәҗәдә провокацион сорауга җавап моннан элегрәк тә кат-кат куелып, аңа җаваплар да төрлечә бирелеп килде. Әйтик, XX гасыр башында, бөек Тукай чорында, татар фольклористикасы тарихында беренче мәртәбә

булса кирәк, бер төркем галимнәр «халык иҗаты, фольклор акрынлап юкка чыга», дип язып чыктылар[1].

Ярты гасырдан артык вакыт узганнан соң, 1952 елда совет чоры урыс фольклоры турында кирпеч зурлыгында бер китап басылып чыккан иде[2]. Шул китаптагы: “Совет чорында фольклорның барлык төрләре чәчәк ату дәрәҗәсенә күтәрелә”, - дигән фикер байтак галимнәрнең «җенен кузгатты»; бер-бер артлы 1953-1955 һәм 1959-1961 елларда булып узган ифрат та киеренке һәм кискен ике дискуссиягә китерде. Шул дискуссияләрнең төп нәтиҗәләреннән берсе: XX гасырның уртасына табан фольклорның дастан, әкият, традицион җыр, йола фольклоры кебек төрләре тәмам юкка чыгуга йөз тотты, – дип белдерелде.

Әлеге дискуссияләрдән соң ярты гасыр вакыт үтте. Тик фольклор һәм этнография буенча фәнни экспедицияләр, бигрәк тә Татар дәүләт фольклор үзәге тарафыннан, әле бүгенге көннәрдә дә оештырыла, һәм ел саен ифрат та бай фольклор һәм этнография материаллары җыеп кайтыла. Әгәр фольклор моннан ярты гасыр элек тәмам бетүгә йөз тоткан булса, каян килә соң бу материаллар? – дигән, үтә дә мөһим сорау калкып чыга. Аңа төпле җавап бирү өчен, фән буларак фольклористиканың методологиясенә яңача якын килү таләп ителә. Эш менә нәрсәдә. Мәдәниятле һәм әдәбиятле халык буларак халык бар икән, димәк, аның күңел көзгесе булган үз шигъри иҗаты да булырга тиеш, чөнки халык иҗатының төп һәм фундаменталь жанрлары халыкның рухи тормышы белән шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки: алар беркайчан да һәм берничек тә бөтенләй, тулысынча юкка чыга алмый. Дөрес, безнең көннәрдә халык арасында әкиятләр яки дастаннар язып алып булмый. Һәм бу аңлашыла да. Безнең көннәр кебек «информацион бум» заманнарында күрсәтелгәндәй зур күләмле әсәрләр халык күңелендә саклана алмый. Дөресен әйткәндә – моның кирәге дә юк!

Алай дисәң тагы! Узган XX гасырның 60 нчы елларында Нәкый Исәнбәт, аңа ияреп шушы юллар авторы да: безнең **бәетләр**, әйтик, юкка чыгуга йөз тотты, дип язып чыккан идек. Шуннан соң узган 40-50 ел безнең принципиаль ялгышуыбызны күрсәтте. Көн дә саен коточкыч фаҗигаләр булып торган безнең көннәрдә бәетләр беркайчан да булмагандай интенсив иҗат ителү һәм актив яшәү дәверен кичерә. Дөрес, андый бәетләрнең байтагы сәнгать әсәренә куела торган таләпләргә җавап бирә алмый. Әмма бусы инде – мәсьәләнең принципиаль башка яссылыгы.

Бәетләргә якын торган **мөнәҗәтләр** белән дә шундый ук хәл. Безнең көннәрдә алар юкка чыкмый гына түгел, ә бәлки нәкъ киресенчә – шулай ук интенсив үсеш дәвере кичерә. Бу күренеш тә безнең җәмгыятьтә соңгы ун-унбиш елда башланган һәм әле хәзер дә дәвам итүче кискен үзгәрешләр белән бәйләнгән: илдә билгеле бер дәрәҗәдә сүз һәм вөҗдан иреге игълан ителгәч, һәм алар, бик акрын гына булса да, тормышка да ашырыла башлагач, җитмеш ел буена «игътибарсыз яткан» мөнәҗәтләр, яңа стимуллар алып, зур тизлек белән халык арасына яңадан таралып, яңа бер баскычка күтәрелделәр. Моның тагын бер ифрат та үзенчәлекле сәбәбе бар: билгеле булганча, мөнәҗәтләр

[1] Урманчеев Ф.И. Г.Тукай и татарская фольклористика начала XX века / Ф.И. Урманчеев // Габдулла Тукай. – Казань, 1968.

[2] Очерки русского народнопоэтического творчества советской эпохи. – М., 1952.

Ислам тәгълиматы белән дә тыгыз бәйләнгәннәр. Соңгы унъеллыкларда Ислам диненең яңадан аякка басуы мөнәҗәтләр язмышында да, һичшиксез, уңай роль уйнады.

Билгеле булганча, **йола фольклоры** – халык иҗатының иң борынгы һәм халыкның көндәлек тормышы белән үтә дә тыгыз бәйләнгән төре. Җәмгыятьтә, тормыш-көнкүрештә булган һәм буласы уңай үзгәрешләр әлеге төр йолаларның, шулар белән бәйле җырларның, такмак-такмазаларның, җор сүз – афористик жанрларның да яшәү рәвешенә берсүзсез уңай үзгәрешләр алып килде.

Фольклор жанрларының кайберсе халыкның сөйләмә теле белән нык бәйләнгән. Шундыйлар рәтенә барыннан да элек **афористик жанрлар: мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, сынамышлар, алкышлар, каргышлар, антлар, җор сүзләр, теләкләр** һ.б. керә. Бер милләт яши икән, аның үз туган теле бар икән, димәк, афористик жанрларның күрсәтелгән төрләре дә яши һәм яшәячәк!

Халык иҗатының иң борынгы төрләреннән булган **мифлар һәм мифология** белән дә мәсьәлә шулайрак тора. 70 ел буена «яшеренеп яткан» мифлар да безнең көннәрдә яңадан туу һәм халык арасына яңадан таралу процессы кичерә. Шул уңайдан конкрет бер фактка аерым тукталып үтү артык булмас. 2004-2006 елларда шушы юллар авторына татар халык иҗаты 25 томлыгының беренче томын әзерләү өстендә эшләргә туры килде. Ул түбәндәгечә атала: «Татар халык иҗаты. 25 томда. Т. 1. Мифлар, мифологик хикәятләр һәм мифологик әкиятләр». Бүгенге көндә әлеге том эшләнеп бетте һәм фәнни мөхәррир Л.Ш. Җамалетдиновка тапшырылды. Күләме – компьютерда 453 бит, ягъни – 28 табак. Шул китапны әзерләгәндә, бихисап теоретик монографияләрдән, энциклопедияләрдән, мифологик һәм әдәби энциклопедик сүзлекләрдән тыш, халык иҗаты әсәрләреннән торган яки шуларны да үз эченә алган байтак чыганаклардан, гәзит-журнал материалларыннан файдаланырга туры килде. Биредә әлеге чыганакларның, кайберсен генә булса да, махсус күрсәтеп үтү артык булмас: татар халык иҗаты күптомлыгының йола һәм уен җырларына, балалар фольклорына, риваять, легенда һәм әкиятләргә багышланган томнары[1]; Н.Исәнбәт китаплары[2]... һ.б.

Татар халык иҗатының милли мифологиягә багышланган томын әзерләүдә филология фәннәре докторы Ф.С. Баязитова тарафыннан халыктан җыеп алынган һәм галимәнең күпсанлы китапларында басылып чыккан материаллар бик зур ярдәм күрсәтә ала. Ул төзеп чыгарган китаплар барыннан да элек татар теле диалектларын өйрәнүгә хезмәт итә. Димәк, әлеге материаллар татар халкының аерым һәм, әйтергә мөмкин – һәрбер этник төркеменең телен, йолаларын, ырымнарын, ышануларын, гореф-гадәтләрен һәм, әлбәттә, мифологиясен нәкъ шул этник төркемнәр буенча фәнни өйрәнү өчен киң юл ача. Аларда керәшеннәр, Әлмәт төбәге, Себер, Әстерхан, Урта

---

[1] Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан, 1980; Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. – Казан, 1993; Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан, 1987; Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 китап. – Казан, 1977; 2 китап. – Казан, 1978; 3 китап. – Казан, 1981.

[2] Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре / Н. Исәнбәт. - Т. I-III. – Казан, 1959, 1963, 1967; Исәнбәт Н. Татар халык табышмаклары / Н. Исәнбәт. – Казан, 1970.

Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары һәм татар-мишәр диалект-сөйләшләрендә чын фәнни нигездә язып алынган материаллар тупланган[1]. Әлеге китапларда урын алган һәм турыдан-туры татар мифологиясенә дә караган материаллар соңгы унъеллыкларда язып алынган. Димәк, алар татар халкы рухи мирасының хәзерге тормышын ачыкларга да ярдәм итә.

Ачыкланган мәгълүматларга караганда, татар мифлары арасында Җиһан, Ай, Кояш, Йолдызлар, Җирнең һәм Күкнең барлыкка килүе белән бәйләнгәннәре элек тә бик аз булган. Хәзер исә алар тагын да сирәгрәк очрый. Татар мифологиясенең әлеге атрибутларына хас үзенчәлекләрне мифлар һәм мифологик легендалар нигезендә генә өйрәнеп булмый. Бу очракта галим халык иҗатының мифологик әкият; мәкаль, әйтем, табышмак, сынамыш кебек жанрларында, борынгы һәм урта гасырлар язма әдәбиятында, милли телдә, археология материалларында сакланып калган мәгълүматларга да мөрәҗәгать итәргә тиеш була. Икенче төрле итеп әйткәндә, безнең көннәрдә халык иҗатының борынгы һәм бик борынгы төр-жанрларының яңадан туып, халык арасына киң таралуы – күзгә күренеп торган, катлаулы һәм каршылыклы, шул ук вакытта ифрат та үзенчәлекле процесс.

Өстәп тик шуны гына әйтергә кирәк: әлеге докладны язганда, без Татар фольклоры дәүләт үзәге хезмәткәрләре җыйган бихисап, әйтеп бетергесез бай материаллардан файдаланмадык. Тик шикләнмичә әйтергә мөмкин: күрсәтелгән һәм фольклор үзәгендә саклана торган материаллар, әгәр аларны фәнни нигездә өйрәнә башласаң, югарыда әйтелгән фикерләрнең берсен дә кире какмаячак. Ә бәлки киресенчә, аларны нигезләү өчен ифрат та бай яңа мәгълүматлар бирәчәк. Сезгә мәгълүм булганча, мәсьәләнең бу аспектын махсус өйрәнү буенча аспирант Зәлия Арикеева эшли. Һәм киләчәктә ул әлеге мәсьәләне тирәнтен өйрәнеп, махсус һәм үзенчәлекле хезмәт язар дигән өмет бар!

*С.М. Гыйләҗетдинов,*
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре,
Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең өлкән фәнни хезмәткәре,
филол. фәннәре канд.

---

[1] Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары (Рухи мирасыбыз хәзинәсеннән) / Ф.С. Баязитова. – Казан, 1995; Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. Татар халкының гаилә йолалары / Ф.С. Баязитова. – Казан, 1992; Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты / Ф.С. Баязитова. – Казан, 1997; Баязитова Ф.С. Әлмәт төбәге татарлары. Рухи мирас: көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор текстлары / Ф.С. Баязитова. – Казан, 2001; Баязитова Ф.С. Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор / Ф.С. Баязитова. – Казан, 2001; Баязитова Ф.С. Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор / Ф.С. Баязитова. – Казан, 2002; Баязитова Ф.С. Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор / Ф.С. Баязитова. – Казан, 2002; Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор / Ф.С. Баязитова. – Казан, 2003.

# *Фольклор үзәге фондындагы гарәп, фарсы һәм татар телендәге кульъязмалар*

Татарстан җөмһүриятенең Мәдәният министрлыгы каршында оешкан Татар фольклоры дәүләт үзәгенең кульъязмалар фонды тарихы 1992 елдан башлана. 1992-2006 елларда Фольклор үзәге хезмәткәрләре, 1992-2001 елларда Үзәкнең башлап оештыручысы һәм 10 ел буена аның даими җитәкчесе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Котдүс Хөснуллин, 2002-2006 елларда филол. фәннәре канд., Үзәкнең яңа директоры Фәнзилә Җәүһәрова җитәкчелегендә Рәсәйнең татарлар күмәкләп яшәгән Әстерхан (1992, 2004), Төмән (1992, 1996), Рязань (1995), Марий Эл (1996), Пермь (1996), Пенза (2000), Красноярск (2000), Оренбург (2001), Самара (2002), Башкортостан (2002), Свердлов (2003), Горький (2005), Мордовия (2006) төбәкләренә ясаган комплекслы экспедицияләр, шулай ук Татарстанның төрле районнарына күпсанлы сәфәрләре вакытында халык иҗаты әсәрләрен язып алганда, кульъязмалар һәм гарәп шрифтында басылган иске китаплар җыю белән дә шөгыльләнделәр. Нәтиҗәдә, Фольклор үзәгендә 650 берәмлектән торган кульъязма һәм иске китаплар җыелмасы барлыкка килде. Шуларның 240ын гарәп, фарсы һәм төрки-татар телендәге кульъязмалар тәшкил итә. Бу елны без фондтагы кульъязмаларның тасвирламасын китап итеп әзерләдек. Иншалла, ул киләсе ел башында басылып чыгар дип өметләнәбез. Китапка 200 кульъязманың тасвирламасы керде. Алар барлыгы 272 исемдәге 339 тасвирламаны тәшкил итәләр. Шуларның 33 (24 әсәр) – фарсы телендә, 109 (82 әсәр) – гарәп һәм 197 (166 әсәр) – төрки-татар телендә. Эчтәлекләренә карап алар 3 тематик бүлеккә төркемләнеп бирелде: I. Әдәбият. II. Фән. III. Дин. Гарәп һәм фарсы телендәге тасвирламаларга XVIII–XIX гасыр татар мәгърифәтчеләре әсәрләре дигән IV нче бүлек тә өстәлде.

Кульъязмаларның репертуарына килгәндә исә, аларның эчтәлеге язылган телнең функциясенә бәйле. Билгеле булганча, гарәп теле, беренче чиратта, мөселманнарның изге китабы – Коръән Кәрим теле. Бу телдә гасырлар буенча Коръән тәфсирләре, дини әсәрләр, мөселман юриспруденциясе - фикыһ буенча рисаләләр, фәлсәфи трактатлар язылган, Коръән нөсхәләре күчерелгән. Бу хәл Үзәкнең кульъязмалар җыелмасында да ачык чагыла. Китапка кергән гарәп телендәге 109 тасвирламаның бары 13 генә әдәби әсәрләр тәшкил итә (7 шигъри әсәр һәм 6 мөнәҗәт). Фән бүлеге 17 тасвирламадан тора (12 әсәр). Калганнары исә, ягъни 59 исемдәге 79 тасвирлама дини эчтәлекле әсәрләрдән тора. Шуларның 14 нөсхәсе Коръән Кәрим күчермәләре, 6 сы Коръән тәфсирләре, Коръән уку кагыйдәләре һәм Коръәннең изге хасиятләренә багышланган рисаләләр.

Фән бүлегенә караган кульъязмалар арасында Әсир әд-Дйн бине Мофаззал бине Гомәр Әбһәринең (1264 елда вафат) неаплатоник Порфиринең (232-305) “Арестотель категориясенә кереш” дигән әсәренә таянып язылган “Исагуҗи әл-Мантыйк” дигән логика дәреслеген күрсәтергә була. Татар мәдрәсәләрендә укытылган бу популяр трактатның Үзәк җыелмасында 6 нөсхәсе саклана.

Дини хикәяләр (религиозные сказания) арасында аеруча популяр әсәрләрнең берсе – “Дәкаикыль Әхбар вә хакаикъ әл-игътибар”. Төрле исемнәрдә йөртелгән һәм төрле авторларга нисбәт ителгән, мавыктыргыч дини хикәяләрдән торган бу рисалә гарәп телендә һәм татарча тәрҗемәдә Казанда күп тапкырлар басылган. Китапка аның ике нөсхәсенең тасвирламасы керде. Тасвирламаның гарәп телендәге бүлегенең күпчелеген мөселман юриспруденциясе – фикыһ буенча әсәрләр тәшкил итә. Алар арасында татарларда аеруча популяр булган һәм мәдрәсәләрдә дәреслек булып хезмәт иткән “Мохтасар әл-Викая” (авторы – Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Таҗ әш-Шәригать (1346 елда вафат), 2 тасвирлама), “Җамигъ әр-румуз” (авторы Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Куһстани (1554 елда вафат), 1 тасвирлама), “Төхфәт әл-мүлүк” (авторы Зәйнетдин Мөхәммәд бине Әби Бәкр әр-Рази (XIII гасырда яшәгән), 1 тасвирлама) әсәрләрен күрсәтергә була.

Фарсы теле Көнчыгышның әдәбият-шигърият теле булып исәпләнә. X–XV гасырларда фарсы телле шагыйрьләр Рудаки (X), Фирдәүси (XI), Фәридетдин Гаттар (XII), Гомәр Хәйам (XIII), Сәгъди Ширази (XIII), Низами (XIII), Хафиз (XIV), Җәләлетдин Руми (XIII), Габдрахман Җами (XV) һ.б. үзләренең үлемсез әсәрләрен иҗат иткәннәр. Шуңа күрә Үзәкнең җыелмасында фарсы телле кульъязмалардан яртысының (II исемдәге 17 тасвирлама) шигъри әсәрләр тәшкил итүе бер дә гаҗәп түгел. Мәшһүр суфи шагыйре Фәридетдин Гаттарның (1120-1229) әсәрләрен татар халкы үзенеке итеп күреп бик яратып укыган. Профессор Габдрахман Таһирович Таһирҗанов язганча, Ф. Гаттарның “Пәнд намә” поэмасын мәдрәсә шәкертләре генә түгел, бәлки абыстайларда белем алган кызлар да яратып укыганнар, күп хатын-кызлар, шул исәптән Габдрахман аганың әнисе дә, поэманың шигырьләрен яттан белгәннәр (1, 117). Китапка “Пәнд намә”нең 5 тасвирламасы керде. Ф. Гаттарның икенче мәшһүр поэмасы “Мантыйк әт-Тайр” (“Кошлар сөйләшүе”) шулай ук татар халкы арасында киң таралган булган. Казан һәм Санкт Петербургның мирасханәләрендә бу әсәрнең татарлар тарафыннан күчерелгән дистәләгән нөсхәләре саклануы шул турыда сөйли. Фольклор үзәге җыйнамасында да “Мантыйк әт-тайр”ның ике нөсхәсе саклана, һәм алар тасвирламага керделәр. Икенче мәшһүр Иран шагыйре Сәгъди Ширазиның (1292 елда үлгән) “Гөлстан” һәм “Бустан” әсәрләре шулай ук татар мәдрәсәләрендә дәреслек булып хезмәк иткәннәр. Китапка “Бустан”ның бер, “Гөлстан”ның ике тасвирламасы керде.

1969 елда Казандагы Көнчыгыш кульъязмаларын тикшергән совет мөстәшригы Ю.Э. Брегель Казан университетының кульъязмалар җыелмасы турында болай дип язган иде: “Белгечләр өчен бу җыелманың төрки телдәге кульъязмалары мөһимрәк булырга тиеш, алар арасында Идел буенда XVI–XX гасырларда язылган әсәрләр күп, шулай ук фольклор язмалары да игътибарга лаек” (2, 363). Безнең фикеребезчә, бу бәяләмә Татар фольклоры дәүләт үзәгенең төрки-татар кульъязмалары өчен дә бик урынлы яңгырый. Дөрестән дә Үзәк җыелмасының иң кыйммәтле һәм иң күпсанлы өлешен төрки-татар кульъязмалары тәшкил итә. Бу кыйммәтле мирасның күбесе әдәби әсәрләрдән гыйбарәт (96 исемдәге 120 шигърият үрнәкләре тасвирламасы һәм 6 исемдәге 6 чәчмә әсәр тасвирламасы). Җыелманың шигърият өлеше 6 бүлекчәгә төркемләнеп бирелде: 1. Гомүмтөрки шагыйрьләр. 2. Татар шагыйрьләре. 3.

Мөнәҗәтләр. 4. Мөнәҗәт җыентыклары. 5 Шигырьләр һәм бәетләр. 6 Шигырьләр, бәетләр һәм мөнәҗәтләр җыентыклары.

XII гасырда Төркестанда яшәп иҗат иткән, суфичылыкның Йәсәвия тарикатына нигез салган, бөек суфи шагыйре Әхмәд Йәсәви (1166 елда вафат) хикмәтләре белән татар халкы Урта гасырларда ук таныш булган. Революциягә хәтле Әхмәд Йәсәви хикмәтләре Казанда 4 тапкыр басылып та чыга, ә Казан һәм Санкт Петербург мирасханәләрендә аның күпсанлы кулъязма нөсхәләре саклана (3, №№ 938-960). Китапка аның өч әсәренең тасвирламасы керде.

Әхмәд Йәсәвинең укучысы һәм замандашы Сөләйман Бакыргани (1186 елда вафат) әсәрләре шулай ук татар халкы тарафыннан яратып укылганнар. Габдулла Тукай үзенең беренче шигырьләрен Бакырган иҗатына таянып язган (“Тотса Мәскәүләр якаң” – “Тотса Газраил якаң”). Тасвирламага “Бакыргани китабы”ның өч, “Ахырзаман” яки “Тәкый гаҗәп” поэмасының бер нөсхәсе керде.

Татар халкы XVIII-XIX гасырларда ук төрек шагыйрьләре әсәрләре белән якыннан таныш булган. Сөләйман Чәләбинең (1422 елда вафат) “Мәүледе нәби” поэмасы татар шәкертләре тарафыннан яратып укылган. Ул Казанда күп тапкырлар нәшер ителгән, кулъязма нөсхәләре киң таралыш тапкан, ә поэманың аерым өзекләре халыклашып төрле вариантларда мөнәҗәт булып көйләп укылган һәм хәзер дә укыла.

Йазиҗи Углының (Мөхәммәд Чәләби) (1451 елда вафат) күләмле “Мөхәммәдия” поэмасы шулай ук татар халкының яраткан әсәрләренең берсе була. Ул беренче тапкыр Казанда А. Казембек тарафыннан 1845 елда китап рәвешендә басылып чыга, аннан соң күп тапкырлар нәшер ителә, шәкертләр тарафыннан һәр мәдрәсәдә диярлек күчерелеп языла. Татар апалары-әбиләре әле хәзергә хәтле “Мөхәммәдия”нең аерым шигырьләрен мөнәҗәт итеп көйләп укыйлар (4, 606-611). Китапка поэманың Үзәктә саклаган нөсхәләренең 4 тасвирламасы керде.

XV–XVII гасырда Урта Азиядә яшәп иҗат иткән Вафа'и (1464 елда исән була) һәм Мәҗлисинең (1688 елда исән була) “Равнак әл-Ислам” һәм “Кыйссаи Сәйфелмөлек” поэмалары шулай ук татар халкы арасында киң таралыш тапкан, күп тапкырлар нәшер ителгәннәр, күчереп язылганнар. Китапка “Равнак әл-Ислам”ның 4, “Сәйфелмөлек”нең 2 нөсхәсенең тасвирламасы керде.

XVIII гасыр төрки шагыйре Суфи Аллаһйарның төрки һәм фарсы телендә язылган поэмалары татар шәкертләренең яраткан әсәрләре булган. Төрки телдәге “Сөбат әл-гаҗизин” һәм “Фәвз ән-нәҗат”, фарсы телендә “Морад әл-гарифин” һәм “Мәсләк әл-мөттәкыйн” поэмалары оригиналда һәм татар телендә тәрҗемәдә күп тапкырлар нәшер ителгәннәр, кулъязма нөсхәләре киң таралыш тапкан. Бу уңайдан “Сөбат әл-гаҗизин” поэмасының исеменә тукталып китәргә кирәк. Рус тюркологлары да (Л.В. Дмитриева), татар галимнәре дә аны “Твердость слабых” – “Гаҗизләрнең ныклыгы” дип тәрҗемә итәләр. Тәрҗемәнең эчтәлегендә үк каршылык ята. Гаҗиз, ягъни хәлсез “слабый” кеше ничек итеп нык була ала соң? Эш шунда ки: сүзлекләрдә гарәп сүзе “Сөбат” яисә “Сәбат”ның “ныклык” – “твердость” дигән мәгънәсе генә бирелә. Әмма “Сәбат” шәкеле белән “имя действия”, ягъни масдар да аңлатыла, һәм ул “утверждение” – ныкландыру дигән

мәгънәгә ия, ә сүзлекләр, гадәттә, масдарның тәрҗемәсен бирмиләр. Поэманың төп функциясе гаҗиз, көчсез кешеләргә белем биреп аларны нык, белемле итү, шуңа күрә, безнең фикеребезчә, "Сөбател гаҗизин"нең дөрес тәрҗемәсе "Гаҗизләрны ныкландыру" – "Утверждение слабых" булырга тиеш.

Поэзия әсәрләренең күпчелек өлешен татар әдипләре шигырьләре, поэмалары, мөнәҗәтләр һәм бәетләр тәшкил итә. Алар арасында татар әдәбиятына нигез салучы Кол Галинең мәшһүр "Кыйссаи Йосыфы" (2 тасвирлама), Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдйарның "Нуры содур" поэмасы (1 тасвирлама) бар. Мөхәммәдйар әсәрләренең кулъязма нөсхәләренең сирәк булуын искә алганда, "Нуры содур"ның тулы булмаган нөсхәсе саклануы Үзәк җыелмасының кыйммәтен тагын да арттыра дип исәплибез.

Танылган шагыйрь һәм галим Габдрәхим Утыз Имәни әл-Болгариның (1854 - 1834) әдәби мирасы бай һәм күпкырлы. Фольклор үзәге җыелмасында аның "Төхфәт әл-гораба вә ләтаиф әл-Газа'а", "Гаварифе заман", "Мөһиммәте заман" поэмалары, "Мөнәҗәт", "Мәрсиәи Хәмидә", "Мәрсиәи Габденнаср" шигырьләре саклана. Китапка шулай ук Утыз Имәнинеке булырга мөмкин дип исәпләнгән "Гариб намә" һәм "Мәнзум әл-Камис" поэмаларының тасвирламалары да керде.

Габдрәхим Утыз Имәни үзенең әсәрләрен гарәп һәм фарсы телләрендә дә иҗат иткән. Китапка аның Суфи Аллаһйарның фарсы телендә язылган "Морад әл-гарифин" поэмасына гарәпчә язган шәрехе "Төхфәт әт-талибин фи шәрх әбйат "Морад әл-гарифин", Шәмсетдин Куһистанның "Җамигыр-ромуз" әсәрендәге авыр аңлаешлы сүзләргә гарәпчә-фарсыча-төркичә аңлатмалы сүзлеге "Кәшф әл-ләгат фи хәлл мәгъзилат ли шәрх Мавләна Шамсетдин" – берәр нөсхә, Болгар илендә кыска төннәрдә йәстү намазын уку мәсьәләсенә багышланган гарәпчә "Рисаләи шәфәкыя" әсәренең 2 нөсхәсенең тасвирламасы керде.

Югарыда без Суфи Аллаһйарның "Сөбател гаҗизин" поэмасына татар әдипләре тарафыннан шәрехләр язылган дигән идек. Хәзерге вакытта "Сөбател гаҗизингә" язылган ике шәрех билгеле. Беренчесен Утыз Имәни 1780 нче еллар башында Бохарада гарәп телендә язган. Ул басылмаган, кулъязма нөсхәләре генә билгеле. 1795 елда Таҗетдин Ялчыгол (1768-1838) тарафыннан "Рисаләи Газизә" исемендә язылган шәрех исә татар халкы арасында киң популярлык казана. Беренче тапкыр 1847 елда китап итеп басылганнан соң, ул революциягә хәтле 40 тапкыр нәшер ителә. Кулъязма нөсхәләре дә күп. Китапка аның бер нөсхәсенең тасвирламасы керде.

Әбүл Мәних Каргалыйның (1782-1833) "Тәрҗүмәи Хаҗи Әбүл-Мәних" һәм "Тәзкирәи Мәних хаҗи" шигырьләренең кулъязмалары сирәк очрый. Үзәк җыйнамасында бу әсәрләрнең тулы нөсхәләре саклана, аларның тасвирламалары да китапта үз урыннарын алдылар.

Һибәтулла Салиховның (1794-1867) "Тәндә җаным" шигыре күп мәртәбәләр басылган, 1905 ел революциясенә кадәр тынгысыз шәкертләрнең гимны булып саналган (5, 153). Кулъязма нөсхәләренең дә саны бихисап, алар халык арасында мөнәҗәт булып көйләп укыла. Шигырьнең ике варианты билгеле: 39 бәеттән торган нөсхәсе Һибәтулла Салиховныкы булып исәпләнә. 29 бәеттән торган икенче варианты 1904 елда Казанда басылган Ризаэддин

Бохар Задә дигән әдибнең “Диване Ризаи” дигән җыентыгында урнашкан. Бу мөнәсәбәт белән җитди бер мәсьәлә калкып чыга: “Тәндә җаным” шигыре Һибәтулла Салиховның үз иҗат җимешеме яисә ул Ризаэддин Бохар Задә әсәрен эшкәрткән генәме? Мәсьәлә ачыклануны таләп итә һәм үзенең тикшерүчеләрен көтә дигән фикердә калабыз. Китапка Ризаи вариантының ике, Һибатулла Салихов вариантының дүрт нөсхәсенең тасвирламасы керде.

Поэзия бүлегендәге әсәрләрнең иң күп өлешен мөнәҗәтләр һәм бәетләр тәшкил итә. Китапта 44 кульъязма җыентыкта урнашкан 176 мөнәҗәт, 7 җыентыктагы 24 бәет тексты бирелде. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр җыентыклары арасында “Әсир дәфтәре” дип аталган кульъязма аеруча әһәмиятле. Аның авторы – Оренбург губернасы, Оренбург өязе, Блазир волосте, Йөзәй авылы кешесе Гыйззәтулла Габделмөэмин улы Яркәев (хәзер Оренбург өлкәсе Шарлык районы Йөзәй авылы). Беренче Бөтендөнья сугышында 1915 елда дошман кулына әсирлеккә төшкәч, Австриядә урнашкан лагерьларның берсендә ул үзенең эчке кичерешләрен, сугыш вакыйгаларын, әсирлеккә эләгүләрен тасвирлаган тирән эчтәлекле бәет-мөнҗәтләр яза. Сугыш беткәч, шигырь дәфтәрен дә авылына алып кайта. Кызганычка каршы, “Моабит дәфтәр”ен хәтерләткән уч төбе хәтле дәфтәренең күп битләре югалган, бары тик 2 бәет һәм 6 мөнәҗәт тексты гына калган. “Әсир дәфтәре” башка хәрби тоткыннарның әсәрләре белән бергә С. Гыйләҗетдинов һәм К. Хөснуллин тарафыннан басмага әзерләнеп, 2003 елда Казанда китап итеп басылды (6).

“Тәварихы Болгария”нең фән бүлегендәге кульъязмалар арасында Мөслимигә нисбәт ителгән һәм XVIII гасыр ахыры - XIX гасыр башында язылган дип исәпләнгән ике нөсхәсе, Таҗетдин Ялчыгол тарафыннан 1805 елда язылган бер нөсхәсе игътибарга лаек.

География буенча язылган әсәрләрдән XVIII гасырның соңгы чирегендә төзелгән (1751-1783) (7, 4) “Исмәгыйль ага сәяхәте”нең кульъязма варианты халык арасында киң таралыш тапкан. Китапка әсәрнең өч нөсхәсенең тасвирламасы керде.

Дин бүлеге нигездә Коръән уку кагыйдәләре-тәҗвидләр – 5 тасвирлама, дини хикәяләр – 14 исемдәге 15 тасвирлама, Мөселман юриспруденциясе - фикыһ буенча рисаләләр – 15 исемдәге 16 тасвирлама һ.б. гыйбарәт.

**Әдәбият**


1. Алеева А.Х. Путешествие Исмагил ага в Индию (XVIII в.) / А.Х. Алеева. - Казань, 1993.
2. Брегель Ю.Э. Восточные рукописи в Казани / Ю.Э. Брегель // Письменные памятники Востока. Ежегодник. 1969. - М., 1972.
3. Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской Академии Наук / Л.В. Дмитриева. - Москва, 2002.
4. Татар әдәбияты тарихы. - II том. - Казан, 1985.
5. Хөснуллин К.М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр / К.М. Хөснуллин. – Казан: Раннур, 2001.
6. Эхо веков. – 2000. - № 1-2.

7. Яркәев Гыйззәтулла. Әсир дәфтәре / Төз. С.М. Гыйләҗетдинов, К.М. Хөснуллин. - Казан, 2003.

*Д.Х. Ганиева,*
Республика мәгълүмати-методик тәэмин итү
һәм мәгариф өлкәсендә контроль
үзәгенең Кукмара муниципаль
районындагы филиалы директоры

## *Милли һәм региональ компонент буларак мәктәптә фольклор традицияләрен саклау мәсьәләсе*

Бүгенге җәмгыятьнең төп бурычларының берсе – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, барлап, аларның гомумкешелек тарафыннан иң кыйммәтле диеп табылган үрнәкләрен һәр шәхескә җиткерү. Ә бу изге эштә төп рольне мәктәп, аның укыту-тәрбия системасы башкара. Адәм баласында дөньяга дөрес караш формалаштыру гаять катлаулы процесс. Кешелекнең гүзәл сыйфатларын саклап калуда, яшь буында Ватанга, туган җирең̣ә мәхәббәт тәрбияләүдә, үз халкыңның мәдәниятен, тарихын тирәнтен белүдә, телен, традицияләрен күңел аша уздырып, ярату, горурлык хисләре тудыруда мәгарифне модернизацияләү кысаларында укыту-тәрбия системасына килеп кергән милли-төбәк компонентының әһәмияте аеруча зур.

Нәрсә соң ул милли-төбәк компоненты?

Бүгенге көндә барлык укыту фәннәреннән диярлек белем стандартлары булдырылды. Монда төп үзенчәлек шунда: белем стандартлары мәгарифнең федераль һәм милли-төбәк компонентларын үз эченә ала. Федераль компонент - белем эчтәлегенең барлык мәктәпләр өчен мәҗбүри булган инвариант өлешен тәшкил итә. Милли-төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен, хезмәтчел традицияләрен чагылдырган укыту материалын үз эченә берләштерә. Әйтергә кирәк, белем стандартының милли-төбәк компонентын булдыру эше Кукмара районы мәгариф системасында Россия мәгарифеннән 7-8 елга алданрак башланды. Педагогия фәннәре кандидаты, Россия Федерациясенең атказанган мәктәп укытучысы мәгариф бүлеге башлыгы Роберт Мияссарович Мансуров җитәкчелегендә бер төркем укытучылар тарафыннан география, тарих фәннәре буенча Кукмара төбәгенә багышланган дәреслекләр, саллы программалар эшләнде. Районыбызга килеп, Республика, Россия педагоглары җитәкчеләре тәҗрибә тупладылар.

Кызганычка каршы, ул елларда татар теленең, халык авыз иҗатының, традиция – гореф-гадәтләренең төбәк үзенчәлекләрен, күрше удмурт-мари халыклары белән мәдәни багланышларын өйрәнүгә игътибар җитмәде. Дөрес, халык педагогикасын укыту-тәрбия эшендә куллану максатыннан мәгариф учреждениеләрендә эш алып барылды. Бик күп онытылган милли бәйрәмнәр кире кайтарылды, укыту-тәрбия эшчәнлеге программалары булдырылды.

Ләкин фольклор өлкәсендә нәкъ менә Кукмара төбәгенә генә хас булган үзенчәлекләрне өйрәнү, бала күңеленә салу кебек изге эшкә фәнни яктан якын килү, системалы караш булдыру проблемасы арткы планда кала килде. Ә бит бала тәрбияләү өлкәсендә халык авыз иҗатының әһәмияте әйтеп бетергесез! Бигрәк тә сабый дөньяга килеп беренче аваз салган, тәпи киткән, әти-әнисе яшәгән тирәлек-мохитнең йогынтысы аеруча зур. Фольклор баланың тән һәм рухи яклардан үсешен оештыруда турыдан-туры катыша. Баланың җәмгыять һәм үз тирә-юне белән бәйләнешле оешкан һәм аваздаш булуына хезмәт итә. Аның нәфислек тойгыларын, зиһен һәм хыял йөгереклеген, зәвыгын үстерүгә зур этәргеч ясый.

Әлеге актуаль проблеманы чишү юлларын табуда безгә Татар фольклоры дәүләт үзәге ярдәмгә килде. Беренче очрашуыбыз 2002 нче елның май аенда әлеге үзәк Кукмара төбәген өйрәнергә экспедициягә килгәч булды. Педагоглар өчен, бигрәк тә татар теле, тарих укытучылары өчен бу экспедиция туган як тарихын халык аваз иҗаты аша өйрәнүгә зур этәргеч бирде. Зур Сәрдек гимназиясе, Зур Кукмара, Янил, Мәмәшир урта мәктәпләрендә төбәк фольклорын өйрәнү эшләре башлап җибәрелде.

2002 елның 12 декабрендә Татар фольклоры дәүләт үзәге тәкъдиме белән район мәдәният йортында район администрациясе, мәгариф, мәдәният бүлекләре белән берлектә экспедиция йомгаклары буенча "Кукмара районы татарлары фольклоры" темасына уздырылган фәнни-гамәли конференция татарның үткәне Изге Болгар җирендә, Казан каласында дип яшәгән бик күпләргә, шул исәптән кайбер педагогларга, җитәкчеләргә дә нык тәэсир итте. Баксаң, тарих җилләре безнең Кукмара төбәген дә читләтеп үтмәгән икән.

Конференция эшчәнлегендә мәдәният йортлары, китапханә җитәкчеләре, мәктәп директорлары һәм урынбасарлары, педагоглар – барлыгы 400 дән артык кеше катнашты. Әлеге конференциянең нәтиҗәсе буларак, Кукмара төбәге фольклорын, үрнәкләрен фәнни нигездә системалы өйрәнү эше башланып китте. Татар фольклоры үзәге белән бәйләнешләр тагын да тирәнәйде.

2005 елның 13 мартында Татар фольклоры дәүләт үзәге белән берлектә Зур Сәрдек гимназиясе базасында "Балаларга рухи тәрбия һәм белем бирүдә татар фольклоры мөмкинлекләре" темасына регионара фәнни-гамәли конференция уздырылды. Күршеләребез Киров өлкәсе укытучылары да катнашкан әлеге сөйләшү милли региональ компонент кысаларында мәктәптә фольклор тардицияләрен саклау, үстерү мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланды. Әлеге конференция безнең элемтәләрне тагын да ныгытырга ярдәм итте. Конференция барышында Татар фольклоры дәүләт үзәге һәм Кукмара районы мәгариф бүлеге арасында үзара хезмәттәшлек турында ике яклы килешү төзелде, эш юнәлешләре билгеләнде. Менә ул юнәлешләр:

1. Мәктәп кысаларында фольклор традицияләрен барлау, саклау, үстерү.
2. Балаларга өстәмә белем бирүнең эчтәлеген камилләштерү.
3. Мәктәп һәм ата-ана арасында бәйләнешне ныгыту.
4. Фольклор традицияләре нигезендә укытучыларның белемнәрен күтәрү. Укытучыларның, укучыларның фольклор өлкәсендәге эзләнүләренә фәнни җитәкчелек итү.

5. Район мәктәпләре базасында төрле халыклар фольклорын өйрәнү системасын булдыру.

6. Районда җыелган фольклор материалларын Татар фольклоры дәүләт үзәге ярдәме белән анализлау, системага салу, укыту-тәрбия эшчәнлегендә кулланырга әзерләү.

Бүгенге көндә үзара хезмәттәшлегебез нәтиҗәләре куанырлык.

1. Район укытучылары, укучылары Татар фольклоры дәүләт үзәге белгечләре белән хезмәттәшлек итеп фольклор темасына кагылышлы төрле мәртәбәле бәйгеләрдә катнашып, I, II дәрәҗәдәге дипломнарга, лауреат исемнәренә ия булдылар. Мәсәлән, 2005-2006 елларда К. Насыйри, Р. Фәхретдин бәйге-укуларында катнашкан дүрт укучыбыз I, II дәрәҗәдәге дипломнарга лаек булдылар, ике укучыбыз лауреат исеме алды.

2. Татар теле, тарих, музыка, башка предмет укытучылары Татар фольклоры дәүләт үзәге тарафыннан тупланып, безгә тапшырылган видеотека, медиатека материалларын иркен куллана.

3. Бүгенге көндә әлеге Үзәк тарафыннан әзерләнгән сораулыклар нигезендә районда фольклор җыю эше алып барыла.

4. Татар фольклоры дәүләт үзәге ярдәме белән район мәктәпләре музейларында фольклор почмаклары оештыру эше башланды. Һәр мәктәптә укучылар, укытучылар, әти-әниләрне берләштергән фольклор ансамбльләре оештыру эше бара. Бүгенге көндә район мәктәпләрендә өч удмурт, бер мари, уннан артык татар фольклор ансамбльләре эшли.

5. Соңгы елларда татар, керәшен фольклорын өйрәнү, балаларга җиткерү максатыннан фольклор түгәрәкләре челтәре киңәйде. Бүгенге көндә рйонда 12 фольклор түгәрәге эшли, ә 2-3 ел элек аларның саны 5 иде. Татар фольклоры дәүләт үзәгеннән алган материаллар нигезендә төзелгән түгәрәк программалары тирән эчтәлекле булулары белән аерылып торалар.

6. Соңгы елларда районда балалар арасында фәнни-эзләнү эшен оештыру киң җәелдерелде. Ике ел рәттән районда укучыларның фәнни-гамәли конференцияләре уздырыла. Монда катнашкан фәнни эшләрнең 20% фольклорны өйрәнүгә багышлана.

7. Төрле фән укытучылары, музей җитәкчеләре катнашында төбәк фольклорын өйрәнү, укыту-тәрбия эшчәнлегендә эффектив куллану проблемаларын яктырткан фәнни-гамәли конференцияләр уздыру традициягә әйләнде. Шундыйлардан 2005 елның апрель аенда Зур Кукмара урта мәктәбе базасында уздырылган тарих укытучыларының регионара фәнни-гамәли конференциясен, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының 2006 елның март аенда уздырылган фәнни-гамәли конференциясен, 2006 нчы елның апрель аенда өч мәктәп базасында төрле фән укытучылары катнашында уздырылган регионара конференцияләрне атап китеп булыр иде.

8. Районыбыз педагоглары фольклор җәүһәрләрен эшчәнлекләрендә генә кулланып калмыйча, тәҗрибә уртаклашу эшенә керештеләр.

Кукмараның 2 нче номерлы урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зөмәрә Җиһаншина беренче очрашулар нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән якташ язучылар иҗатын өйрәнүгә багышлаган укыту программасында балага аң-белем бирүдә татар фольклорының әһәмиятен курсәтеп уза. Мәктәптә туган якны өйрәнү буенча берничә хезмәт авторы Мәмәшир урта мәктәбе татар теле, тарих укытучысы

Тәнзилә Насыйбуллина да татар фольклорын, туган як фольклорын өйрәнүгә зур игътибар бирә.

9. Мәгариф һәм фән министрлыгы раслаган, Кукмара районы удмурт, мари мәктәпләрендә эшләүче татар теле укытучылары тарафыннан эшләнгән укыту программасы кысаларында Татар фольклоры дәүләт үзәге тәкъдиме һәм ярдәме белән 10-11 сыйныф укучыларына татар, удмурт, мари фольклор үрнәкләрен чагыштыру мөмкинлеге бирелде, чөнки беренчедән, балага үз теле аша башка халык мәдәниятен өйрәнү җиңелрәк бирелсә, икенчедән, татар, удмурт, мари телләре, традицияләре безнең төбәктә шул кадәр керешеп беткән ки, безнең татар теле укытучыларыбыз үзләре кызыксынып бу юнәлештә өйрәнү эшенә тотындылар.

Әлеге һәм башка бик күп укытучылар Татар фольклоры үзәгенә зур рәхмәтләрен җиткерәләр, чөнки алар хезмәтенең чишмә башында нәкъ менә әлеге үзәк тора. Хәер, алар үз фикерләрен, Фольклор үзәгенә куйган югары бәяләрен 2006 елның февраль аенда Татар фольклоры дәүләт үзәге оештырган фәнни-гамәли конференциядә әйттеләр инде. Әлеге конференциядә катнашкан укытучыларыбыз Зөмәрә Җаһаншина, Фирдәүсә Ризвановалар аннан рухланып канатланып кайттылар.

Укытучыларыбыз эшчәнлегенең нәтиҗәләре дә сөенерлек. Алда әйтеп үткән Зөмәрә Җиһаншина һәм Тәнзилә Насыйбуллиналар, туган төбәгебез тарихын, мәдәниятен, фольклорын өйрәнеп, зур уңышларга ирештеләр, киң җәмәгатьчелек арасында танылып, Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан тәкъдим ителгән приоритетлы "Мәгариф" милли проекты кысаларында узган конкурса җиңеп чыгып 100әр мең сум премия белән бүләкләнделәр. Билгеле, аларның әлеге зур унышларында Татар фольклоры дәүләт үзәгенең дә өлеше бар.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: әле Фольклор үзәге белән берлектә эшлисе эшләребез бик күп безнең, планнарыбыз зурдан. 2006-2007 уку елын керәшен татарлары фольклорын өйрәнүгә багышлап, гадәттәгечә март-апрель айларында Татар фольклоры дәүләт үзәге ярдәме белән Село-Чура мәктәбе базасында зур фәнни-гамәли конференция уздырырга тәгаенлибез, тупланган материаллардан Кукмара төбәге фольклоры җыентыгы эшләргә планлаштырабыз. Алга таба Фольклор үзәге башка район мәгариф бүлекләре белән дә эшчәнлекләрен ныгытыр, безгә фольклор өлкәсендә тәҗрибә уртаклашырга, аралашырга мөмкинлек ачылыр дип өметләнәбез.

*Г.М. Ханнанова,*
ТФДҮнең мирасханә җитәкчесе

## *Соңгы елларда Татар фольклоры дәүләт үзәге фондын тулыландыру мөмкинлекләре*

Халкыбызның традицион мәдәниятен барлау һәм җыйнау өлкәсендә күләмле эзләнүләр һәм шактый зур эш алып барган Татар фольклоры дәүләт

үзәге халкыбыз тарихына, аның рухи мәдәниятенә, көнкүрешенә караган бай материалга ия булган мирасханә туплады. Мирасханәне тулыландыру чыганагы булып, беренче чиратта, Үзәк тарафыннан татарлар яшәгән төрле регионнарга, Татарстан районнарына оештырлган комплекслы экспедицияләр тора. Унбиш ел дәвамында фәнни эзләнүләр алып барылган төбәкләрнең геогрфиясе шактый киң. Биредә Әстерхан, Төмән, Пермь, Рязань, Киров, Ульян, Түбән Новгород, Пенза, Красноярск, Самара, Свердловск, Чиләбе, Оренбург өлкәләре дә, Татарстанның Кукмара, Самара, Мамадыш, Балтач, Саба, Әтнә, Арча, Теләче, Лаеш, Балык Бистәсе кебек районнары да бар.

Экспедицияләр нәтиҗәсендә фондка кайткан материалларга күзәтү ясап, түбәндәге мәгълүматларны китерергә мөмкин. Мирасханәбезнең шактый өлешен фотокүчермәләр тәшкил итә. Биредә авыл, урам, йорт, каралты-кура күренешләре, көнкүреш кирәк-яраклары, кием-салым, бизәнү әйберләре, кул эшләнмәләре һ.б. фотокүчермәләр урын алган. Экспедиция барышында язып алынган материалларның шактый өлеше Үзәк мирасханәсенә аудио һәм видеоязма рәвешендә кайта. Бу язмаларда халкыбызның йола фольклорына караган мәгълүматлар, халык авыз иҗаты үрнәкләре, җырлар, бию һәм уен көйләре һ.б. бар. Көнкүрештә кулланыла торган материаллар: сөлгеләр, кул эшләнмәләре, костюм элементлары һәм бизәнү әйберләре рәвешендәге этнографик материаллар да мирасханәбезне тулыландырып тора. Мирасханәбез хәзинәләрендә булган борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар аеруча игътибарга лаек. Нигездә бу дини әдәбият, әмма алар арасында әдәби әсәрләр, дәреслекләр, сүзлекләр, кулдан күчерелгән мөнәҗәт-бәетләр дә бар.

Халкыбызның онытылып бара торган, әмма кайбер төбәкләрдә сакланып калган һәм бүгенге көндә дә яшәп килгән уен-җырларын, гореф-гадәтләрен, йолаларын язып алуны һәм алга таба шул язмаларны тирәнтен фәнни нигездә өйрәнүне күздә тотып эшләнгән максатчан командировкалар да мирасханәбезне баетудагы мөһим чыганакларның берсе булып тора. Мамадыш районы Кумырык авылында язып алынган “Бәрмәнчек”, “Пасха”, Җөри авылында “Нардуган”, Урта Кирмән авылында “Орчык бәйрәме”, Кукмара районы Тырыш авылында Сабан туе алдыннан йомырка җыю йоласы, Кнәбаш авылында “Карга боткасы”, Саба районы Кече һәм Олы Шыңар авылларында “Боз озату, “Нәзер аты”, “Бирнә тәбәсе” йолаларының видеоязмалары әлеге эшчәнлекнең күрсәткече булып торалар. Шулай ук татар халкының төрле этник төркемнәренең көнкүрешенә, кием-салымына караган фото һәм видеоматериаллар белән мирасханәбезне баету максатыннан да командировкаларга чыгу оештырыла. Мәсәлән, Санкт Петербург шәһәренең этнография музеенда саклана торган татар костюмы комлексларының шактый өлеше фәнни хезмәткәребез Р.Г. Мөхәмәдова тарафыннан өйрәнелеп, аларның кайбер үрнәкләре видео һәм фотокүчермәләргә төшерелеп мирасханә фондына алынды. Шулай ук Пенза өлкәсе Городище районы Урта Әләзән урта мәктәбе музеенда сакланучы мишәр костюмы комплекслары күчермәләре белән дә видео һәм фотофондларыбыз баетылды. Татарстанның Түбән Кама, Кайбыч, Питрәч районнарының керәшен авылларына оештырылган максатчан командировкалар нәтиҗәсендә керәшен костюмына караган бай фотоматериал кайтты.

Мирасханәбез фондларын тулыландыруда, баетуда кайбер фольклорчы галимнәребез, әдәбият һәм тел белгечләре һәм гомүмән үз халкын, аның тарихын һәм иҗатын сөюче шәхесләребезнең өлеше дә бик зур. Танылган галимәбез, этнограф Р.Г.Мөхәмәдова тапшырган фотоматериаллар бүгенге көндә фотофондыбызның төп һәм иң кыйммәтле өлешен тәшкил итә. Атаклы фольклорчы галимебез, филология фәннәре докторы М.Х. Бакиров мирасханәбез фондларын баетуда зур эш алып бара. Аның җитәкчелегендә КДУның татар филологиясе факультеты студентлары тарафыннан тупланган халык авыз иҗаты үрнәкләре, этнографиягә караган материаллар, сирәк китаплар һәм кулъязмалар мирасханәбезне баетуда мөһим роль уйный. Фольклор үзәге белән инде шактый еллар тыгыз элемтәдә эшләүче галимебез, диалектолог Ф.Ю. Юсупов та үзенең тәҗрибәсе һәм табышлары белән бик теләп уртаклаша. Күптән түгел аның тарафыннан Красноуфим татарлары тарихы һәм мәдәниятенә караган бай материал тупланмасы мирасханәбезгә керде. Шулай ук Үзәк мирасхәнәсен баетуга зур өлеш керткән галимнәребез, шәхесләребездән Харис Нигъмәтҗанов һәм Флора Әхмәтоваларны да атап үтәргә кирәк.

Халык мәдәниятен барлау, җыйнау һәм мөмкин юллар белән халыкның үзенә кире кайтару юлында көч куючы Үзәк район администрациясенең мәдәният бүлекләре, авыл мәдәният үзәкләре, мәктәпләре белән тыгыз элемтәдә эшли. Әлеге мәктәп укытучылары, мәдәният хезмәткәрләре дә үз табышлары белән бик теләп уртаклаша. Мирасханәбездә конкрет авыллардан, мәдәният бүлекләреннән килгән материаллар да бар. Шундыйлардан Мамадыш районы администрациясенең мәдәният бүлеге мөдире Спиридонов Степан Петровичны атап үтәргә мөмкиндер. Күптән түгел аның тарафыннан Мамадыш районы Җөри авылында язып алынган “Питрау бәйрәме”нең видеоязмасы мирасханәбезгә керде.

Мирасханәбездә саклана торган материалларның шактый өлеше инде эшкәртелеп төрле җыентыкларда, фотоальбомнарда, видеофильмнарда урын алды. Шундыйлар арасыннан Үзәк тарафыннан җыелып нәшер ителгән “Утлы еллар кайтавазы” җыентыгын, “Керәшен татарлары костюмы” альбомын, С.М. Гыйләҗетдинов һәм К.М. Хөснуллин тарафыннан әзерләнгән “Әсир китабы” исемле хезмәтне һ.б. атарга мөмкин. Шулай ук фонд материаллары нигезендә дистәләгән видеофильм (“Сабан туе”, “Зәрә боткасы”, “Исем кушу”, “Никах”, “Бирнә җыю”) әзерләнде. Мирасханәбездә саклануы гарәп, фарсы, төрки кулъязмалар һәм сирәк китаплар фәнни хезмәткәребез С.М. Гыйләҗетдинов тарафыннан тасвирланып аерым китап булып басмага әзерләнде.

Бүгенге көндә мирасханәбездә саклана торган барлык видео, аудио һәм фотоязмаларны цифрлы күчермәләргә төшереп компьютерга кертү буенча зур эш алып барыла. Алга таба мирасханәбездә сакланган барлык материалларны үз эченә алган электрон каталог булдыру күздә тотыла.

*З.М. Арикеева,*
ТФДҮнең кече фәнни хезмәткәре

# *Казан арты татарлары фольклорының бүгенге халәтен өйрәнү: проблемалар, тәҗрибә, перспективалар*

Гореф-гадәтләр һәм йолалар халыкның рухи дөньясында бик үзенчәлекле урын алып торалар, чөнки аларда бердән, әлеге халыкның иң тирәндә, иң үзәктә ята торган уй-ниятләре, өмет-ышанычлары чагылса, икенчедән, алар югары дәрәҗәдәге әхләклылыкка өнди, яшәүнең мәгънәсен тирән фәлсәфи нигездә аңлатуга корылган була. Йолалар гасырлар буе эшкәртелә киләләр, аларга көчле традициялелек хас. Аларның иң кирәкле, бары иң кадерле булган элементлары гына, ягъни этносның яшәешен, сакланышын һәм үсешен тәэмин итә торган билгеләре генә үстереләнығытыла килгән. Бу аеруча гаилә-көнкүреш йолаларында ачык күренә.

Татар халкының йола иҗатын өйрәнү буенча хезмәтләр, әлбәттә, юк түгел, алар бар. Бу нисбәттән без инде XIX гасырда һәм XX гасыр башында ук дөнья күргән Казан татарларының гореф-гадәтләрен, йола үзенчәлекләрен өйрәнүче хезмәтләрне[1], төрле мәкаләләрне[2] атап китә алабыз. Р.К. Уразманова[3], Н.Б. Бурганова[4] кебек галимнәрнең күп санлы хезмәтләре Казан арты татарларының йолаларын өйрәнүгә багышланган. Ләкин әлеге хезмәтләрдә татар халкының рухи дөньясы, көндәлек тормышы, көнкүреше этнография фәне материалы буларак яктыртыла һәм әлеге материал бары тик тасвирлама характерда бирелә. Аталып киткән хезмәтләрнең күпчелегендә галимнәребез игътибарны календарь йолаларын тасвирлауга юнәлткәннәр, ә гаилә-көнкүреш йолалары беркадәр читтәрәк кала биргән. Күренекле галимнәребез Ф.С. Баязитова[5], Д.Б. Рамазанова[6] хезмәтләрендә гаилә-көнкүреш йолалары рәтендә торучы туй йоласы тикшерелсә дә, алар аталып киткән йоланы диалектолог, этнолингвист буларак өйрәнәләр.

Казан арты татарлары фольклорын, этнографиясен өйрәнү һәм туплау максатыннан экспедицияләр соңгы тапкыр 1951-1952 елларда, фольклорчы галимнәребез Х. Ярми, Х. Гатина, С. Шамсутдинова, М. Богданов, Н. Гиззатуллин, С. Вахитова һ.б. торган төркем тарафыннан оештырылган булган.

2002 елдан башлап, Татар фольклоры дәүләт үзәге әлеге фольклор-этнографик экспедицияләрне Казан арты районнарына яңадан башлап

---

[1] *Фукс К.Ф.* Праздники казанских татар / К.Ф. Фукс // «Заволжский муравей». - 1814. - Т.3. - №19; *Он же.* Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. - Казань, 1844.

[2] Сабан и джиен – народные праздники // «Московитянин». – 1850. - Ч.3. - Кн. II. - С. 57 - 62; *Коблов Я.Д.* О татарских мусульманских праздниках / Я.Д. Коблов. - Казань, 1907. - С. 39 - 41; *Ахмаров Г.* Сабантуй / Г. Ахмаров // «Казан мөхбире». - 1906. - № 80.

[3] *Уразманова Р.К.* Обряды и праздники татар Поволжья и Урала / Р.К. Уразманова. - Казань, 2001.

[4] Бурганова Н.Б. Татар диалектологиясе буенча материаллар / Н.Б. Бурганова. - Казан, 1978.

[5] *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты / Ф.С. Баязитова. - Казан, 1997.

[6] *Рамазанова Д.Б.* Туйлар, туйлар.../ Д.Б. Рамазанова. - Казан, 1997.

җибәрде. Шушы максат белән Үзәктә 2002 елда җиде еллык махсус программа төзелде. Бу программа кысаларында Казан арты татарларының үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнү максаты куелды, шуңа мөнәсәбәтле рәвештә эзләнүләр башланды. Беренче экспедицияләр Кукмара, Балтач, Мамадыш, Балык Бистәсе районнарына оештырылган булса, соңгылары нәкъ Казан артына, элеккеге Казан ханлыгының һөнәрчеләре яшәгән, хәзерге Арча, Әтнә, Саба, Биектау (Дөбьяз төбәге), Теләче, Мари-Эл Республикасының Бәрәңге районнарында эшләде. Шушы экспедицияләр барышында йола комплексы белән беррәттән татарларның мифологик күзаллаулары, шуларга бәйле ышанулар, ырымнар җыелды.

"Казан арты татарлары фольклоры" программасы кысасында шәхсән минем үземнең эшләгән төп юнәлешләрнең берсе – йола фольклорын тулы комплекста, материалга комплекслы якын килеп, ягъни йола иҗатын тәшкил итүче барлык компонентларны да исәпкә алып өйрәнү. Ә бу, үз чиратында йоланы, аның эчендәге фольклор текстларын, мифик күзаллаулар - ышану-ырымнарны бербөтен итеп тикшерүне таләп итә. Атаклы рус фольклорчысы Н.И. Толстой "текст" төшенчәсенә аңлатма биргәндә традицион йоланың төрле яссылыкка караган – *акциональ, реаль, вербаль, персональ, локатив, темпораль, музыкаль, сурәтләнмә* тестлардан торуы турында әйтә[1]. Әлеге күзлектән чыгып, йоланы тикшергән вакытта игътибарны аталган элементларның һәммәсенә дә бертигез бирү сорала. Бу - эшләү принципларының берсе һәм иң нәтиҗәлесе.

Гаилә-көнкүреш йолаларын өйрәнү башлыча бала табу, туй, күмү һәм искә алу йолаларын игътибар үзәгенә ала. Әлеге йолалар кешенең бер яшәү статусыннан икенчесенә күчүнең төп этапларын билгели һәм кеше тормышының хронологиясен системалы рәвештә тикшерергә мөмкинлек бирә. Бала табу, бала тәрбияләү белән бәйле йолалар, яңа туган баланы гаилә, җәмгыятькә яраклаштыру актлары, туй, яңа гаилә төзүгә мөнәсәбәтле йолалар һәм кешене соңгы юлга озату, аны искә алу йолалары һәр халык мәдәниятенең үзенчәлеген билгеләп торучы традицияләр. Бүгенге көнгәчә татар халкының әлеге йолаларына багышланган, бигрәк тә комплекслы өйрәнүне күздә тотып башкарылган фәнни монографияләр һәм башка хезмәтләр юк.

Казан арты татарлары гаилә-көнкүреш йолаларын комплекслы өйрәнү дигәндә, без тикшерелүче йолаларның күп компонентлы, вакыты буенча беркадәр сузылган комплекслар булуын истә тотарга тиешбез. Шунлыктан безнең максатыбыз - йолаларның ничек, ни рәвешле башкарылуын, аларның кеше тормышында нинди урын алып торуларын гына ачыклау түгел, ә теге яисә бу йола белән бәйле барлык элементларга да (фольклор текстлары, ырым, ышану, аларның килеп чыгышы, кулланыш даирәсе, йола барышында төрле хәрәкәтләр башкару, музыкаль катламының урынын билгеләү, махсус кием кию, аерым йола ризыклары әзерләүгә) тиешенчә игътибар бирү.

Кеше гомеренең иң җитди вакыйгалары - бала табу, туй һәм үлгән кешене соңгы юлга озату йолаларын өч этапка бүлеп карарга була: йолага

[1] *Толстой Н.И.* Вторичная функция обрядового символа / Н.И. Толстой // Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. - М., 1995. - С. 167-184.

әзерлек, йоланың үзе һәм йола артыннан башкарыла торган эшләр. Без үзебезнең чыгышыбызда бала табу һәм туй йола комплексларына карата булган берничә фикеребезне әйтергә булдык.

Беренче карашка фольклор пласты әллә ни зур булмаган бала табуга бәйле йола гадәтләрен генә карап киткәндә дә, комплекслы тикшергән вакытта бик тирән катламнарны күзәтергә мөмкин. Әлбәттә, бала табуга кадәр әле аңа әзерлек чоры, ягъни никахка кадәрге чор, кыз баланың, ир баланың җенси үсеше вакытына ук игътибар ителергә тиеш. Шуңа күрә бала табу йола фольклорын җыйган вакытта без аны аңа әзерлек чорыннан ук башларга мәҗбүр икәнебезне дәлиллибез. Чөнки гаиләле булу, нәселне үрчетүгә әзерлек - ул кыз бала һәм ир баланың балигъ булу чорыннан ук башлана, ныграк тикшерсәк, бәлки аннан да алдарактыр. Бала табу йоласының башлангыч этабы итеп, без балага узуны һәм бала табуның үзен түгел, ә бәлки тагы да алдарак торган этап – гаилә коруга бер этәргеч булып торучы яшьләрнең аралашуын (кичке уеннар, аулак өйләр, “аулак чәйләр”, керәшен татарлары көнкүрешендә бүгенге көнгәчә сакланып калган “Нардуган” йоласына караган йөзек салыш уеннары), яшүсмер кызларның күпме һәм нинди җенестәге балалар табачакларын төрле юраулар ярдәмендә белергә омтылуларын (энә, җеп ярдәмендә[1]) атый алабыз. Шушы ук рәткә без кыз бала үскән вакытта ук аны гаиләсендә тәрбияләүне дә, мәсәлән, булачак ирләренең начар холыклы булуыннан (“Су алып кайтканда, суны чайпалдырмыйча алып кайтырга кирәк, юкса ирең эчкече була”), гаиләне ташлап китүеннән (“Ашаган вакытта ипи сыныгын калдырыга ярамый, алайса сөйгәнең ташлап китә”[2]) саклану чараларын кертә алабыз. Әлеге рәтне күп сандагы үзеңә карату чаралары белән дә дәвам итәргә мөмкин. Моның өчен Теләче районы Югары Кибә-Хуҗа авылында яшәүче Гатауллина Г.Р. “Ошаган егетне үзеңә карату өчен кызларга ул егет йөри торган юлга кайчы күмеп куярга киңәш ителә”[3] дип белдерде.

Яшьләрнең аралашуы, күңел ачу формалары үзеңә пар сайлау, гаилә кору йоласының да беренче адымнары булып тора. Һәр яшь егет һәм яшь кыз бер социумда, бер коллективта яши, һәм шушы социум әлеге егет белән кызга үзенең мөнәсәбәтен белдерә, алар пар килгәннәрме, юкмы икәнен сиздерә.

“Арчаларга барган чакта
Урман арасында гөл;
Сезнең кебек булса булыр
Меңнәр арасында бер”, - дигән сүзләр белән егет белән кызның пар килүләре турында әйтсә,

“Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Марфуга.
Ат тугарып, җигә белми,
Кызлар сайлаган була”, - дигән җыр сүзләре киресенчә, кайбер егетләрнең кызларга туры килмәвенә, лаеклы түгел икәненә ишарәли.

---

[1] ТРның Теләче р-ны Олы Нырсы авылында яшәүче Ф.Ф. Сафинадан (1960) 17.05.2006 язып алынды.
[2] ТРның Теләче р-ны Алан авылында яшәүче Г.Р. Гыйльмановадан (1974) 21.05.2006 язып алынды.
[3] ТРның Теләче р-ны Югары Кибә-Хуҗа авылында яшәүче Г.Р. Гатауллинадан (1974) 19.05.2006 язып алынды.

Шулай итеп, әлеге төртмәле җырлар аша ук социум яшь егет белән кызга бәя бирә башлый һәм социумның яхшы бәясен алган егеткә һәм кызга бер-берләрен сайлар өчен мөмкинлек бирә. Шуңа күрә без уен җырларын уен җырлары дип кенә түгел, ә шушы социумның гаилә корып, нәсел үрчетүенә мөнәсәбәтле дә бәяли алабыз. Һәм без аны шулай бәяләргә тиешбез дә.

Әлегәчә без шушы йолалар кысасында яшәп килүче музыкаль фольклорны бары тик яшьләрнең күңел ачу йолалары буларак кына карарга күнеккән, ләкин бүгенге фольклорчы, халык көнкүрешен саклау мәсьәләләрен күтәрүче фольклорчы аларны менә шушы башлангыч этапта, яшьләрнең аралашу вакытында ук гаилә коруга әзерлек процессы баруын күрә белергә һәм аны йоланың башлангыч этабы итеп ассызыклый алырга тиеш. Шушылай эшләгәндә генә без ул йолаларыбызны саклый алабыз, аларның чын мәгънәсендә халык көнкүрешендә яшәешен бирә алабыз.

Туй йоласы безнең этнографлар өчен, гадәттә, кызны ярәшү этабыннан башланып китә. Ә фольклорчы өчен, әлбәттә, ул әлеге этаптан гына түгел, югарыда аталып киткән әзерлек чорыннан, ягъни егет белән кызның үсмер вакытлары, хатын-кыз җенесе һәм ир-ат җенесе билгеләнү процессыннан ук башланып китәргә тиеш. Шушыларны без бербөтен итеп бәйләп, йола комплексы итеп карый алабыз.

Шулай итеп, биредә без бүгенге көндә татар халкы фольклорын җыйнау, туплау процессының комплекслы оештырылырга тиешле икәнен дәлилләргә тырыштык. Халык фольклорны музыкаль катламга да, ышану-ырымга да аермый, халык көнкүрешендә, халык акылында ул бербөтен булып саклана. Без, фольклорчылар, кайчандыр материалларны аерым жанрларга бүлеп, җыентыкларга туплап, бик дөрес эшләгәнбездер, ләкин ул җыентыклардан хәзер аларны халыкның үзендә ничек бар, шул кыяфәттә җыйнап, кире кайтару мәсьәләсе актуальрәк, чөнки алар халык көнкүрешендә тулы комплекстан башка яши алмый.

Татар фольклоры дәүләт үзәгендә бу эзләнү процессы, фольклор экспедицияләрендә эшләү системасы бүгенге көндә нәкъ менә шушы юнәлештә алып барыла. Әлеге эш нәтиҗәләрен без 2006 елда тупланып бетеп килүче җыентыкта да күрсәтергә тырышырбыз. Ә инде киләчәктә Казан арты татарлары фольклорының менә шушы өлешләре зур бер китап булып чыгар дигән өметтә торабыз.

*И.С. Гыйләҗетдинов,*
Г. Ибраһимов ис. ТӘһСИнең кулъязмалар һәм
текстология бүлеге аспиранты

## ***XIV гасыр татар әдибе Мәхмүд әл-Болгариның “Нәһҗел-Фәрадис” әсәрендә һәм татар мөнәҗәтләрендә гомумкешелек әхлак мәсьәләләре***

Татар халкы шигърияткә бай халык. Урта гасыр татар әдәбияты тарихына күз салсак, ул чордагы әдәбиятнең күпчелек өлешен шигъри әсәрләр тәшкил иткәнен күрербез. Болгар-татар әдәбиятына нигез салучы Кол Галинең үлемсез “Кыйссаи Йосыф”ы (1212), Алтын Урда чоры әдипләре Харәзминең “Мәхәббәтнамә”се (1342), Котбның “Хөсрәү вә Ширин”е (1342), Хөсам Кятибның “Җөмҗөмә Солтан”ы (1369) моңа ачык дәлил булып тора. Казан ханлыгы чорында бу традицияне Мөхәммәдйар (1542), Кол Шәриф (1552 дә вафат) үзләренең мәшһүр поэмалары, шигырьләре белән дәвам иткәннәр. XVII–XIX гасырларда татар шигъриятен үстерүдә Мәүлә Колый (XVII), Габдессәлам (1700-1776) Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834), Әбелмәних Каргалый (1782-1833), Һибәтулла Салихов (1794-1867), Габделҗаббар Кандалый (1797-1860), Акмулла (1831-1895) һәм башкалар үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Шулай да, Урта гасыр татар әдәбияты шигъри әсәрләрдән генә тора дип әйтү тарихи дөреслеккә туры килмәс иде. Алтын Урда чорында иҗат иткән Сәйфи Сараиның шигырь катнаш проза белән язылган “Гөлстан бит-төрки” (1391), Рабгузиның “Кыйссасел Әнбия” (1310) әсәрләре татар әдипләренең инде Урта гасырларда ук проза өлкәсендә дә зур әсәрләр иҗат иткәнен күрсәтә. Мәхмүд әл-Болгариның “Нәһҗел-Фәрадис”ы (1358) үзенең күләме, монументальлеге, күтәрелгән проблемаларының мөһимлеге белән татар әдәбияты тарихында аерым урын алып тора. “Нәһҗел-Фәрадис” – “Оҗмахларның ачык юлы” – зур күләмле, дини-дидактик характердагы чәчмә әсәр. Ул 1358 елда Сарай шәһәрендә тәмамлана һәм ул чактагы әдәби традицияләр нигезендә 3 өлештән төзелгән була: кереш, төп өлеш һәм йомгак. Төп өлеш исә үз чиратында 4 бабка-бүлеккә бүленгән: 1. Мөхәммәд пәйгамбәрнең изгелекләре. 2. Беренче дүрт хәлифә, кызы Фатыйма, оныклары Хәсән белән Хөсәен, ислам динендәге төп дүрт мәзһәбкә нигез салучы имамнар: Әбү Хәнифә, Шәфигый, Мәлик, Әхмәд ибн Ханбалның изгелекләре. 3. Аллаһы Тәгаләгә якынайта торган гамәлләр. 4. Аллаһы Тәгаләдән ераклата торган гамәлләр. Һәр баб исә 10 фасылдан-бүлекчәдән тора, җәмгысы 40 бүлекчә. Һәр бүлекчә Мөхәммәд пәйгамбәргә нисбәт ителгән хәдис белән башланып китә. Бу хәл Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисе белән аңлатыла: “Кем дә кем пәйгамбәрнең 40 хәдисен башкаларга өйрәтсә, ул кеше галимнәр җөмләсеннән санала, ә үлгәч шәһитләр хисабында булачак (3, 9). Әсәрдә китерелгән хәдисләр саны 40 кына түгел, әлбәттә. Һәрбер бүлекчәдәге хикәяләр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең яраннары-сәхәбәләр тапшырган хәдисләргә нигезләнгән, шулай итеп, китапта китерелгән хәдисләр саны 100 дән артып китә. Автор, үзенең фикерләрен, күтәрелгән проблемалары, мәсьәләләрне нигезләү өчен икенче бер мөһим чыганак – Коръән Кәрим аятьләренә дә мөрәҗәгать итә. Китапта, безнең исәпләвебез буенча, Коръәннән барлыгы 77 аять китерелә, аларның 75 гарәпчә оригиналда һәм тәфсир шәкелендәге татарча тәрҗемә белән, ике аять бары тик татарча тәрҗемәдә генә бирелә. Ул чордагы укучыларның Коръән белән якыннан таныш булуларын искә алып, автор, билгеле, аятьләрнең кайсы сүрәдән алынуын күрсәтеп тормый, бары тик “Каулүһү Тәгалә” – “Аның Аллаһы Тәгаләнең сүзе” дигән гыйбарә белән генә чикләнә. Чынлап та, без Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аңа кире әйләнеп кайтачакбыз дигән җөмләләр (3, 101) Коръән Кәримнең 50 нче “Каф” сүрәсенең 19 – аятенең башын һәм 2 нче

“Бәкара” сүрәсенең 156 – аятенең соңгы өлешен тәшкил итәләр. Китапта китерелгән аятьнең Коръән тексты белән тәңгәл килмәгән очрак та бар. Мәсәлән, 4 – бабның 4 фасылында китерелгән “Валлаһу ля йөхиббү-л-мөтәкәббирин” – “Ә Аллаһы Тәгалә тәкәбберләрне яратмый” дигән гыйбарә (3, 318) Коръәндә икенче төрлерәк яңгырый: “Иннәһү ля йөхиббүл-мөстәкбирин” – “Чынлап та Ул (Аллаһ) тәкәбберләрне яратмый. Бу очракта Коръән аятенең мәгънәсе үзгәрмәгән, әмма сүзләре икенче.

Эчтәлекләре буенча “Нәһҗел-Фәрадис”та китерелгән Коръән аятьләрен түбәндәге тематик бүлекләргә төркемләп була:

1. Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары.

2. Мөхәммәд турында. Бу бүлек үз чиратында түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

а) Мөхәммәдкә хәер-дога кылу важиблеге (салават).

б) Вәхи килү.

в) Үзе һәм сәхабәләр күргән авырлыклар. Дошманнары.

г) Могъҗизалары.

д) Күккә ашу (Мигъраҗ).

е) Оҗмахка сәяхәте.

и) Газа-изге сугышлары.

3. Коръәндә искә алынган башка пәйгамбәрләр турында.

4. Дөньяның фанилыгы.

5. Иманның төп нигезләре (намаз, зякать, руза, хаҗ).

6. Гомумкешелек әхлак мәсьәләләре.

7. Мөселманнарның тормышын тәртипкә салуга кагылышлы аятьләр (никах һ.б.).

“Нәһҗел-Фәрадис” эчтәлеге белән дини-дидактик әсәр дидек. Беренче ике бабта автор үзенең нәсихәтләрен Мөхәммәд пәйгамбәр, кызы Фатыйма, оныклары Хәсән, Хөсәен, беренче дүрт хәлифә – Әбү Бәкер, Гомәр Госман, Гали һәм дүрт мәзһәбкә нигез салган имамнар Әбү Хәнифә, Шәфигый, Мәлик, Әхмәд бине Ханбалның “изге” тормышлары, аларның гамәлләре үрнәге нигезендә үткәрә. Фикерләрен дәлилләгәндә, мөселманнар өчен иң могътәбәр иң абруйлы чыганаклар – Коръән Кәрим аятьләре һәм пәйгамбәр хәдисләренә таяна. Әхлак мәсьәләренә караган соңгы ике бабта исә, автор “новеллалар, кыска хикәяләр жанрындагы әсәрләргә күп урын бирә һәм әхлакый мәсьәләләрне образлы сөйләм һәм художество әдәбияты әсәре белән органик бәйләнештә уңышлы чишә” (4, 225). Шул ук вакытта Коръән Кәрим авторитетына да киң таяна. Һәрбер нәсихәтен Коръән аяте белән дәлилли, ныгыта.

Автор карашынча, бу гүзәл әхлакый сыйфатларның иң беренчесе һәм иң мөһиме ата-ананы хөрмәт итү. Моңа дәлил итеп ул, бүлекчә башында пәйгамбәр хәдисен китерә: “Ата-анага изгелек кылмакның савабы намаз кылмакның, руза тотмакның һәм хаҗ белән гомрә кылмак савабыннан артыграк торыр” (3, 236). Димәк, ата-ананы хөрмәт итү Ислам диненең терәге булган гамәлләрне үтәүгә караганда да савабрак икән. Коръәндә ата-ананы хөрмәт итү, аларны тәрбияләү мәсьәләсенә зур игътибар ителә, бу темага багышланган алты аять бар. Мәхмүд әл-Болгари шулар арасыннан иң матурын, иң тулысын сайлап алып укучыларга тәкъдим итә: “Синең Раббың сиңа Аннан башка бер затка да гыйбадәт кылмаска, ә ата-анагызга изгелек

кылырга кушты. Әгәр аларның берсе, яисә икесе дә синең янында картлык көннәренә ирешә икән, аларга “тфү” дип әйтмә, рәнҗетмә, бәлки матур сүзләр генә әйт. Һәм аларны икесе алдында да мәрхәмәт йөзеннән түбәнчелек канатын җәй. Һәм әйт: “Йа Раббым, аларны рәхмәтеңнән калдырма, чөнки алар мине кечкенәдән тәрбияләделәр” (1; 17, 23-24).

Ата-ананы хөрмәтләү мотивы татар мөнәҗәтләрендә дә киң чагылыш тапкан. Мәсьәлән, “Диде Муса” мөнәҗәтендә, Мусаның җәннәткә эләгүе-эләкмәве турыдан-туры әти-әнисенең ризалыгына бәйләнгән:

– Раббым Алла, - диде Муса, - җәннәт булыр микән миңа?

Сиңа җәннәт булыр, Муса, атаң-анаң разый булса (6,42).

Бу юллар Мөхәммәд пәйгамбәргә нисбәт ителгән “Җәннәт – аналарның аягы астында” дигән мәшһүр хәдис белән дә тәңгәл киләләр (7, № 377).

Гомүмкешелекнең гүзәл әхлак сыйфатларыннан иң кирәклеләреннән берсе итеп Мәхмүд әл-Болгари гаделлекне исәпли. Үз фикерен иллюстрацияләү өчен, Һарун әр-Рәшид һәм изге шәех-хатын турындагы хикәяне китергәннән соң, автор шәех исеменнән түбәндәге аятьне әйттерә: “Чынлап та Аллаһы Тәгалә гаделлек һәм яхшылык кылырга якыннарыгызга бүләк бирергә әмер итә, һәм Ул фәхишәлек, әшәкелек һәм җинаять кылудан тыя. Ул сезгә үгет-нәсихәт бирә, бәлки сез аңыгызга килерсез!”. (1; 16; 90).

Гаделлек идеясы татар мөнәҗәтләренең дә төп темаларының берсе булып тора. Мәсьәлән, “Бу дөньяда иң хөрмәтле адәм дигән” мөнәҗәттә бу мотив болай яңгырый:

Унөченче кирәк нәрсә – гадаләттер,

Гадаләт – тәкъвалыкка дәляләттер.

Гаделсезлек намуссызлык – яман фигыль,

Бәндә өчен гадел булу бик кирәктер. (6; 212).

Сабырлык, тыйнаклык – татар халкының төп сыйфатларыннан берсе. Бу сыйфатны тәрбияләүгә татар әдипләре дә зур өлеш керткәннәр. Мәхмүд әл-Болгари сабырлык сыйфатына зур игътибар биреп, 3 – бабның 10 фасылын “Сабыр һәм риза булу изгелекләре”нә багышлый. Бүлекчә башында пәйгамбәр хәдисен китергәннән соң, ул үз фикерен берничә Коръән аяте белән дә ныгыта: “Чынлап та сабырларга аларның бүләкләре хисабсыз бирелер” (1, 39, 10); “Сездә булган бетәчәк, ә Аллаһы Тәгаләнеке кала. Һәм Без сабырларга аларның гамәлләренә караганда да яхшырак бүләк бирербез” (1; 16; 96). Алга таба, үзенең фикерен иллюстрация өчен сабырлыгы белән танылган Әйүб пәйгамбәр турында шактый озын кыйссаны китерә һәм хикәясен “Чынлап та без аны сабыр дип таптык. Нинди яхшы кол, чынлап та, ул Раббына кайтачак,” - дигән аять белән төгәлли (1; 38, 41-44).

Сабырлык – татар халык иҗатының төп темаларының берсе. Сабырлыкны мактаган мәкальләр, әйтемнәр, мөнәҗәтләрнең саны бихисап: “Сабыр төбе сары алтын”; Сабырәр-Рахман, бис-сабыр-шайтан һ.б. Котдүс Хөснуллин төзегән күләмле “Мөнәҗәтләр һәм бәетләр” китабының “Сабырлык - фарыз сыйфат” дигән бүлеге тулаем сабырлык темасына багышланган. “Сабырлыктыр гамәл башы” дигән мөнәҗәттәге юллар югарыда әйтеп киткән мәкаль белән аваздаш яңгырый:

Сабырлыктыр – гамәл башы, сабырлыктыр – күңел хушы,

Сабырлыктыр – иман нуры, сабыр бирсен үзе Рахман!

Сабырлыкны Ходай сөйгән, сабырсызны ләгыйнь сөйгән;

Мәгыйнь ул – Ходайга дошман, сабыр бирсен үзе Рахман! (6, 262).

Әлбәттә, “Нәһҗел-Фәрадис”та әхлак мәсьәләсенә караган темалар без санап киткән сыйфатлар белән генә чикләнми. Китапның соңгы бүлегендә “кешеләрне Алладан ерагайта торган гамәлләр: хаксызга кеше үтерү, зина кылу, аракы эчү, тәкәбберлек, ялган һәм гайбәт сөйләү, дөнья байлыгы артыннан куу, комсызлык, ачу саклау, көнләшү, горурлык, гамьсезлек, зур өмитләр саклап яшәү хөкем итеlә” (3, 10). Әмма вакыт чикле булу сәбәпле кыска гына чыгышыбызда, безнең карашка мөһим булган мәсьәләләргә генә тукталырга булдык.

## Әдәбият


1. Коръән Кәрим. Сәгуд Гарәбстаны басмасы. Гарәп телендә.
2. Коран. Перевод и комен. И Ю.Крачковского. 2-изд. - М.: Наука. 1990.
3. Мәхмүд әл-Болгари. Нәһҗел-Фәрадис / Басмага әзерләүче Фәнүзә Нуриева. – Казан: Тат. кит. нәшр, 2002.
4. Борынгы татар әдәбияты. - Казан, 1963.
5. Мөхәммәдьяр. Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Тәнкыйди нөсхә. Китапны басмага әзерләүче Шакир Абилов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1997.
6. Хөснуллин Көтдүс. Мөнәҗәтләр, бәетләр/ Көтдүс Хөснуллин. – Казан: Раннур, 2001.
7. Гариф Бәк. Мең дә бер хәдис. Төрекчәдән Г.Ибраһимов тәрҗемәсе.

# II БҮЛЕК

*М.Х. Бакиров,*
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре,
КДУ профессоры, филол. фәннәре д-ры

## *Шигърияткнең чишмә башына сәяхәт*

Һәр фән өлкәсендә диярлек мөһим күзәтүләргә нигезләнгән, әмма күренешнең асылын тулысынча ачып бетерә алмаган карашлар була. Әгәр мондый карашлар күренекле галимнәр тарафыннан үткәрелсә, һәм күпмедер дәрәҗәдә фактик материал белән дә ныгытылса, алар бердәнбер дөрес һәм күренешне тулысынча иңли торган концепция төсен ала. Минем шигырь теориясендә ныклап урнашкан, әмма яңа, өстәмә фактик материалларга таянып үзем ясаган нәтиҗәләр таләп иткәнчә, төзәтмә кертүне, тулыландыруны сораган шундый ике карашка тукталасым килә.

Сүз иң архаик шигырь төзелешенең табигате, шул исәптән борынгы төрки шигырь корылышының нинди формалардан үсеп китүе турындагы карашлар турында бара. Аларның беренчесе – XX йөзнең егерменче елларында төрки шигырь төзелешенең башлангыч һәм милли ритмик үзенчәлекләре турында кызыклы күзәтүләр белән чыккан поляк тюркологы Г. Ковальскийныкы. Үзенә кадәрге ориенталист Б. Фабоның күзәтүләрен[1] дәвам итеп һәм үстереп, ул «икеюллык - төрки поэзиянең иң борынгы формасы булган» дип белдерде һәм лирик шигърияткә хас дүртьюллыклар белән эпик шигырьгә («эпик шигырь» дигәндә, вакыйгалылыкка, хикәяләүгә нигезләнгән эпос-дастан тексты күздә тотыла) хас күпъюллык тезмәләр шул «икеюллык тәңгәллек» тән үсеш алганнар дигән караш үткәрде[2].

Шигырь белгече В.М. Жирмунский үзенең тикшеренүләрендә Г. Ковальскийның «ике юллы строфа» төрен эпик шигырь төзелешенең дә сыйфаты һәм формасы итеп каравы белән килешмәвен әйтте һәм мондый нәтиҗәгә килде: «Изначальной структурной формой древнетюркского народного эпического стиха является не двучленная строфа, а то, что было мной названо эпической тирадой (или строфемой), т.е. цепочка стихов неопределенной длины, объединенная параллелизмом, (отсюда не обязательно двучленным, часто многочленным». «Такие цепочки стихов

---

[1] Fabo B. Rhytmos und Melodie der Tьrkischen Volkslieder / B. Fabo // Keleti Szemle. – Budapest, 1906. –VII. – S. 121-124.

[2] Kowalski T. Ze studiow nad forma poezji lodow turekich / T. Kowalski. – Krakow, 1921. –P. 129-181. Әлеге хезмәтнең русчага тәрҗемәсе: Линин Ан. К вопросам формального изучения поэзии турецких народов / Ан. Линин // Изв. восточного фак-та Азербайджанского гос. ун-та. – Баку, 1926. – I. – С. 139-158; 1928. – II . – С. 137-162.

соответствуют вообще поступательному движению эпического рассказа у многих народов»[1]. «Тирада» безнең әдәбият белемендә һәм фольклористикада кулланыла торган «сарын» дигән төшенчәгә туры килә һәм шигъри эпос-дастаннардагы бер-беренә сарылып-үрелеп килүче тезмәләрдән төзелгән күпъюллык строфаны белдерә.

Хәзерге вакытта шигырь белгечләре, кайбер искәрмәләр ясау исәбенә, бу карашларның икесен дә таныйлар, ачыклап әйткәндә, икеюллык тезмә лирик җыр-шигырьнең иң элгәрге төзелеш төре булган дип, эпос-дастаннарның строфа корылышы исә ритмик-синтиксик тәңгәллеккә нигезләнүче күпъюллык архаик формадан үсеп чыккан дип исәплиләр.

Без поэзиянең борынгы төрләрен өйрәнү барышында Г. Ковальский белән В. Жирмунский ачыклаган шигырь формаларыннан да архаиграк, хәтта күпмедер дәрәҗәдә аларның һәр икесе өчен дә өлге, иң беренче җирлек (архетип) хезмәтен үтәгән өченче форма да булган дигән фикергә килдек. Бу иң архаик шигырь төзелешенең нигезендә төрле борынгы язма ядкәрләрдә, шулай ук берничә буын сәясәтче-этнографларның хезмәтләрендә теркәлгән **беръюллык шигырь** формасы ята. Ачыклап әйткәндә, җыр-шигырьнең башлангыч төре бер генә тотрыклы гыйбарәдән тора торган, әмма, һичшиксез, кат-кат такмаклар яки көйләп башкаруга исәп ителгән беръюллык поэтик-эмоциональ сөйләм рәвешендә була, һәм нәкъ менә бер үк тәртиптә кабатлануы аркасында мондый микротекст, ритмик куәт алып, үзенә бер төрле шигъри-музыкаль иҗат башлангычының формалашуына китерә.

Без бер үк гыйбарәне кабатлау юлы белән җыр-шигырь иҗат итү алымы һәр борынгы халыкның башлангыч чор поэзиясенә хас уртак пракaнун булган дип исәплибез. Моннан тыш, әлеге иң архаик шигъри-музыкаль канун стадиаль яктан ярым кыргыйлык яки ыруглык чорында яшәгән һәм мәдәни үсеш ягыннан артта калган кабиләләрдә дә киң кулланылган. Узган гасырларда Европа сәяхәтчеләре һәм этнографлары тарафыннан Африкада, Төньяк Америкада, Океания утрауларында яшәүче төрле кабиләләр арасында язып алынган аерым иҗат үрнәкләре, безнеңчә, әнә шул турыда сөйли. Бауман исемле европа сәяхәтчесе, мәсәлән, Африканың көньягында яшәүче бубе исемле кабиләне өйрәнгәндә, шундый бер хәлгә тап була: диңгез төбеннән энҗе-кабырчыклар эзләү белән шөгыльләнүче әлеге кабиләнең бер әгъзасы, яр буенда ял итеп утырганда, кинәт «Акула бубенең кулын тешли» дип җырлап җибәрә, һәм, тукталмыйча, әлеге сүзләрне кызганыч тавыш белән ярым көйләп, ярым такмаклап үз телендә кабатлый башлый. Чумып диңгез төбеннән энҗе эзләүче бубе негрлары өчен акула, әлбәттә, хәтәр һәм фаҗигале хәлләр белән бәйле балык була. Шуңа күрә дә экспромт рәвештә туган һәм бер көйгә яңгырый башлаган әлеге җырны башкалар да күтәреп алалар, һәм шунда ук ул аларның уртак халәтен чагылдыручы күмәк җырга әверелеп китә.

Акула бубеның кулын тешли.
Акула бубеның кулын тешли.
Акула бубеның кулын тешли[2].

---

[1] Жирмунский В.М. О некоторых проблемах теории тюркского народного стиха / В.М. Жирмунский // Вопросы языкознания. – 1968. – N 1. – Б. 32.

[2] Шурц Генрих. История первобытной культуры / Генрих Шурц. – М., 1923. – Вып. II. – С. 585.

Көйләп һәм кат-кат кабатлап башкарылучы бер юлдан торган җыр-шигырь үрнәкләре көньяк Африкада яшәүче бушмен кабиләләреннән аеруча күп язып алынган. Алар арасында ырым яки ярым дога рәвешендәгеләре дә, теге яки бу йолага бәйләп, яисә сунар вакытында башкарылганнары да, шулай ук гамәли-практик ихтыяҗ белән турыдан-туры бәйләнмәгәннәре дә бар. Мәсәлән, кояш чакырганда, бушменнар тарафыннан күмәкләп башкарылган шигъри текст мондый:

The sun up there, up there[1].
Кояш биектә, биектә.

Ә монысы – бушмен сугышчыларының үз җәясенә атап һәм, әлбәттә, кабатлый-кабатлый көйләп башкарган җыры:

Әй син, каты агач, каты агач.
Әй син, каты агач, каты агач[2].

Бразилиянең тропик урманнарында яшәүче ботокуд исемле кабилә әгъзаларыннан язып алынган поэтик текст та бер юлдан, ягъни праканун таләбенә туры китереп чыгарылган бер юллык «строфа»дан тора. Ботокудлылар аны, дошманнарын җиңгәч, үзләренең хәрби башлыкларына атап җырлый торган булганнар һәм җиңү шатлыкларын да шул бер гыйбарәне кат-кат тәкърарлау аша белдергәннәр.

Наш начальник не знает страха[3].
Безнең башлыгыбыз курка белми.

Иң кызыгы шул: пратөрки бабаларыбыз иҗатына бәйләнешле борынгы материаллар арасында да бер гыйбарәдән – кабатланучы бер үк юлдан торган архаик шигъри-поэтик текст үрнәге сакланып калган икән. Борынгы кытай чыганакларында теркәлгән бер язмада мондый мәгълүмат бирелә: «По преданию, у Юсуна было две дочери. Обе сестры были очень красивы. Жили они в девятиярусной яшмовой башне. Однажды небесный правитель послал к ним ласточку. Ласточка пролетела над ними, кружилась и кричала «и-и-и». Сестры поймали понравившуюся им птичку и посадили в нефритовый ларец. Через некоторые время они открыли ларец, заглянули, а ласточки и след простыл. Она улетела на север и болыпе не возвращалась. А в ларчике остались два яичка. Сестры загрустили и стали петь:

Ласточка, ласточка, улетела!
Ласточка, ласточка улетела!

По преданию, это была самая ранняя северная песня»[4]. Шушы ук ярым легендар фактны чагылдыручы икенче бер язмада да соңгы җөмлә «Эта песня положила начало северным мелодиям»[5] дип тәмамлана.

Безнең эрага кадәр II йөздә Кытайның төньягында һәм көнбатышында яшәүче һуннар арасында булган һәм аларның күп җырларын, көйләрен алып кайткан атаклы сәяхәтче Чжан Цянь мәгълүматларына караганда, шулай ук

---

[1] Bowra C.M. Primitive song / C.M.Bowra. – London, 1962. – P. 63.
[2] Шунда ук. - Б. 68.
[3] Гроссе Эрнст. Происхождение искусства / Эрнст Гроссе. – М., 1899. – С. 218.
[4] Юань Кэ. Мифы древнего Китая / Кэ Юань. – М.: Главн. ред. вост. лит-ры, 1987. – С. 123-124.
[5] Шунда ук. - Б. 301.

кытайларның һун җырларын «төньяк җырлары» дип атап йөртүләрен исәпкә алганда[1], югарыдагы текстлардагы «северная песня», «северные мелодии» дигән гыйбарәләрнең һәм бер юллы җырның пратөрки бабаларыбызга караганлыгы, безнеңчә, шиксез. Янә шуны өстәргә кирәк: буй җиткән чибәр кызларны күккә – Тәңрегә багышлап манарада асырау традициясен без соңрак чор һуннарында, дөресрәге, уйгурларның борынгы бабалары булган гоагюйлар риваятендә дә очратабыз[2].

Аерым сәяхәтчеләрнең һәм этнографларның язмаларында берьюллык җыр-шигырьнең ритмик һәм музыкаль үзенчәлекләрен аңларга омтылу очраклары да юк түгел. XIX йөзнең икенче яртысында ике ел ярым Яңа Гвинея утравында яшәгән рус этнографы Миклухо Маклай, мәсәлән, җирле папуас җырларының гап-гади төзелешенә, кып-кыска текстка корылуларына һәм еш кына барабан тактына кушылып башкарыла торган үтә садә көйләренә игътибар итеп, мондый нәтиҗә ясаган: «Эти песни, которые поются соло или хором, состоят только из немногих слов, иногда даже одного слова, которое все время повторяется, причем мелодия мало варьирует»[3]. Бу кызыклы күзәтү музыка белгечләренең түбәндәге нәтиҗәсе белән дә туры килә: «Принцип остинантской повторности (итальянча остинато – үҗәтле рәвештә бертуктаусыз кабатлау) исторически был наиболее ранним способом организации музыкальной мысли»[4]. Архаик культуралардагы бу үзенчәлек, минем фикеремчә, тормыш күренешләренең һәм вакыйганың элек туктаусыз кабатланып, әйләнеп торучы цикл рәвешендә күзаллануы белән дә бәйләнгән булырга тиеш.

XX йөзнең 70 елларында Миклуха Маклай эзләре буйлап сәяхәттә булып кайткан фольклорчы Б.Путилов та папуаслар фольклорында сакланган кадими җыр-шигырь үрнәкләре белән кызыксына һәм, үзенә кадәрге атаклы тикшеренүченең күзәтүләрен дәвам итеп һәм яңа мәгълүматлар белән тулыландырып, болай яза: **Одностиховые песни** вовсе не редкость в новогвинейском фольклоре. Тексты папуасских песен предельно элементарны: **одна много раз повторяющаяся фраза.** Однообразный мотив выполняет функцию законченной мелодической формы. Это – так называемые **однострочные** мотивы»[5] (аерып язу безнеке. – М.Б). Әлеге өзектәге «одностиховые песни», «однострочные мелодии» – дигән гыйбарәләр яки төшенчәләр, безнеңчә, иң архаик җыр-шигырьнең табигатенә аеруча туры килеп тора. Чөнки аларның текстлары да, шулай ук башкарыла торган көйләре дә нәкъ менә кат-кат әйләнеп кайтуга, сүгмә-сүз яки аз гына

[1] Рифтин Б.Л. Из истории культурных связей Средней Азии и Китая (II в. до н.э.– V в. н.э.) / Б.Л.Рифтин // Проблемы Востоковедения. – М., 1960. – С. 96-127.

[2] Бичурин Н.Я. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена / Н.Я.Бичурин (Иакинф). – М.-Л.: Наука, 1950. – Т.1. – С. 214-215.

[3] Миклухо Маклай. Собрание сочинений / Миклухо Маклай. – М.-Л., 1950. – Т.1. – С. 116-117.

[4] Зубарева Н.Б. Об эволюции пространственно-временных представлений в художественной картине мира / Н.Б.Зубарева // Художественное творчество. – Л.: Наука, 1983 . – С. 27.

[5] Путилов Б.Н. Миф – обряд – песня Новой Гвинеи / Б.Н. Путилов. – М.: Наука, 1980. – С. 272. Янә аныкы: Песенно-музыкальный фольклор бонгуанцев // На берегу Маклая.– М.: Наука, 1971. – С. 227-253.

үзгәртеп кабатлауга нигезләнүче бер юллы гыйбарәдән һәм бер юллы музыкаль фразадан төзелгән.

Гвинея папуасларының крахмал ярмасы ясаганда башкарган хезмәт җыры моңа мисал була ала:

| | |
|---|---|
| Bom, bom marare | Саго, саго ясыйлар, |
| Marare, tamole, | Ясыйлар кешеләр, |
| Mara, marare, | Ясый, ясыйлар, |
| Bom, bom marare | Саго, саго ясыйлар. |
| Marare, marare, | Ясыйлар, ясыйлар, |
| Bom, bom marare[1] | Саго, саго ясыйлар. |

Шигырь теориясеннән чыгып, әлеге күзәтүләрне үстерү юнәлешендә тагын шуларны әйтергә мөмкин: сүз бара торган шигъри-музыкаль праформада берьюллыклар һәм строфа, һәм рифма вазыйфаларын да үз өсләренә алганнар. Ник дигәндә, нәкъ менә кабатлану аркасында берьюллык «строфа» үзенең киресенә – антистрофага әверелгән, шул ук юл белән ишәйгән тезмәләр исә охшаш яңгырашлы, ләкин һәркайсы аерымланып торучы «бер юллы строфа»лар исәбенә барлыкка килгән.

Янә бер әһәмиятле өстәмә: кабатлану исәбенә вертикаль юнәлештә ишәюче поэтик берьюллык эченә горизонталь юнәлештә үсү мөмкинлеге дә салынган булган. Бу очракта без җыр-шигырь юлының эмбриональ цезура ярдәмендә ике-өч өлешкә бүленүен яки иҗекләрнең якынча булса да тәртипкә салынуын күздә тотабыз. Австралия аборигеннарының җенси магиягә, ягъни ирлек куәте байлык, муллык китерә дип ышануга нигезләнгән эротик җыры, мәсәлән, кабатлау һәм антитеза алымы ярдәмендә өч буынга бүленә. Ачыклап әйткәндә, ир-атлар тарафыннан тирәсенә куаклар үскән чокырны әйләнә-әйләнә һәм сөңгеләр (сөңге – ирлек куәте символы) белән чәнчә-чәнчә төн буена башкарылган берьюллык җырның тексты түбәндәгечә:

Pulli nira, pulli nira, wataka[2]
(Бу) чокыр түгел, чокыр түгел, (бу) vulva!

Ә болары – борынгы төркиләрнең магик рухлы иҗатына һәм кабер ташъязма поэзиясенә караган шигъри текстлар. Аларның беренчесе, VII йөз ядкәре дип исәпләнгәне, Алма-Ата өлкәсенең Илий районы төбәгендәге каберлектән табылган бронза йөзеккә рун хәрефләре белән язылган.

Sцk, saө[3].
Чүк, куркак!

Төрки сугышчы йөзегенә уелган әлеге берьюллыкның тылсым көченә ия дип каралганлыгы, тәэсир итеп, дошман якны буйсындырырга тиешле ырым рәвешендә кулланылганлыгы, безнеңчә, шиксез. Нибары ике сүздән генә торган гыйбарәнең ритмы да бик үзенчәлекле: һәр сүз бер үк зурлыкта-озынлыкта килә һәм бер үк аваздан башланып китә. Димәк, әлеге шигъри-магик гыйбарә кайтулы тәңгәл бәйләнешкә һәм төрки поэзиядә акрынлап үсеш алган аллитерация (аллитерация – бер үк авазларның кабатлануы)

[1] Миклуха Маклай. Алда күрсәтелгән хезмәт / Миклуха Маклай. - Б. 110.
[2] Аничков Е.В. Весенняя обрядовая песня на западе и у славян / Е.В. Аничков. – СПб., 1903. – Ч. I. – С . 87.
[3] Аманжолов А.С. Руническая надпись на бронзовом кольце / А.С.Аманжолов // Вестник Академии наук Казахской ССР. – Алма-Ата: Гилым, 1971. – №1 (309). – С. 65-66.

алымына корылган. Бер үк юл эчендә бер-берсен кабатлаучы һәм куәтләп килүче ике буын хасил булуын әнә шуның белән аңлатырга кирәк.

Хакасия җирендә борынгы Енисей кыргызлары (дәүләтләренең яшәгән дәвере – VII – XIII йөзләр) калдырган шигъри сөйләмле кабер ташъязма үрнәгендә дә аллитерация алымы ярылып ята. Ритмик буыннар үзара тигез булмаганлыктан, әлеге берьюллыкның иреклелеккә тартым ритмы һәр ике буын башында бер үк авазларның һәм һәр буын ахырында бер үк сүзләрнең кабатлануы исәбенә барлыкка килә.

Эрддм болсар будуныг – эрк будуныг[1].
Шанлы булган халык – батыр халык.

Енисей кыргызларының Алтын күл төбәгендә куелган кабер ташы язмасында да (VIII йөз) аллитерация алымына корылган калыплашкан юл бар, ягъни ошбу текстта да төрле зурлыктагы ике ритмик буынны сүз башындагы бер үк авазлар бергә бәйли.

Altun suna juө kejiki, | artgyl, tog(g)ul
Алтын Суңа кош-корты, ишәй, үрче[2].

Түбәндәге мисал исә – күп төрки халыкларда уртак ышанулар җирлегендә барлыкка килгән борынгы йола иҗатыннан. Аерым алганда, әлеге магик шигъри юлны борынгылар язын җирләр кардан ачыла башлаган чорда, шул исәптән «Нәүрүз» бәйрәмендә ягылган учак аша кат-кат сикергән вакытта кабатлый торган булганнар.

Алас, Алас, | ар балээден калас[3].
Алас, Алас, һәр бәладән калдыр.

Варианты:

Алас, Алас, | кули балодан халяс[4].
Алас, Алас, бар бәладән коткар.

Монда инде сүзмә-сүз кабатлау һәм аллитерация алымнары гына кулланылып калмаган, ә рифмалар да барлыкка килгән һәм ритмик-интонацион тәңгәллек, кайтулы бәйләнеш исәбенә шигырь юлы ике, хәтта өч буынга яки мәгънәви кисәкләргә (ситагмаларга) бүленгән. Белүебезчә, борынгыдан килүче һәм шулар өлгесендә ясалып торучы берьюллык мәкальләр дә еш кына шушы ук алымнарга нигезләнгән була. Ахыр килеп, хәтта ике юллы мәкальләр дә күбрәк бер юл эчендә тернәкләнгән мәгънәви-семантик яки ритмик-интонацион тәңгәлләрдән һәм антиподлардан үсеп чыга. Бу, димәк, халык поэзиясенең «күзәнәкләре» һәм афористик иҗат төре булган мәкальләр формалашуда берьюллык праформа шулай ук зур роль уйнаган дигән сүз. Моны XI йөздә яшәгән атаклы тюрколог Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет төрк» сүзлегенә теркәлгән борынгы мәкаль үрнәкләреннән дә сиземләргә була.

Берьюллыклар:

Кош кылыч | кынка сыгмас.

---

[1] Древние письмена Хакасии. – Абакан, 1970. – С. 23.
[2] Кляшторный С.Г. Стелы Золотого озера / С.Г.Кляшторный // TURCOLOGICA. – Л.: Наука, 1976. – С. 261.
[3] Баялиева Т.Д. Доисламские верования и их пережитки у киргизов / Т.Д.Баялиева. - Фрунзе: Илим, 1972. – С. 48.
[4] Снесарев Г.П. Реликты домусульманских верований и обрядов у узбеков Хорезма / Г.П.Снесарев. – М.: Наука, 1969. – С. 41.

Куш кылыч кыныга сыймас.

Коркмыш кишигә | кой башы | кош көрүнир.
Сув бермәскә (бирмәгәнгә) сөт бер.

Алымчы арыслдан, биримче сычган.
Алачагы бар – арслан, бирәчәге бар – тычкан.

Икеюллыклар:

Бирин-бирин миң болур,
Тама-тама көл болур.

Алыплар бирле урушма,
Бегләр (бәкләр) бирлә турушма (тартышма)[1].

Берьюллыкның һәм горизонталь, һәм вертикаль юнәлештә үсүенә юл ачкан һәм тотрыклы формула-калыплар эшләнүгә этәргеч биргән иң төп ысулларның янә берсе, иң характерлысы өчлек алымы булган. Бу алымның нигезендә – бер үк юл эчендә бер үк сүзнең яки кып-кыска гыйбарәнең өч мәртәбә кабатлану күренеше ята. Әмма соңгы кабатлануында әлеге сүз, азмы-күпме үзгәреп яки өстәмә сүз белән бәйләнештә килеп, ритмик оппозиция дә тудыра. Өч тапкыр кабатлану, гомумән, борынгы сүз сәнгатенең аерылгысыз бер сыйфаты булып тора. Бигрәк тә ул магиягә һәм мифологиягә бәйләнешле күп текстларда тәртипләнеп, утырып җиткән һәм хәтта иң борынгы рефрен формалары барлыкка китергән. Грузин фольклорында, мәсәлән, борынгы җырларның тотрыклы кушымта-рефрены рәвешендә сакланып калган шундый берьюллыклар бар. Мәгънәләре хәзерге вакытта онытылган ул сүзләрдә Алгы Азия мифологиясендәге аерым аллаларның исемнәре яңгырашы калгандыр дип уйлыйлар.

а) Uав-нана, uав-нана, нана-uав.
б) Вардо-нана, вардо-нана, нана-вардо.
в) Дели-дела, дели-дела, дала-дели[2].

Мисаллардан күренгәнчә, соңгы буында кабатланучы сүзләрнең инверсиясе, урыннарының алмашынып килүе ритмга тәмамлану төсмере бирә. Иң мөһиме, шушылай тәртипләнү аркасында ритмның эмоциональ-эстетик тәэсирлелеге дә бермә-бер арта, һәм менә ни өчен бу алым бүгенге поэзиядә дә яратып кулланыла.

Ә сине, ә сине, ә сине, туган як,
Бар микән сагынмый торган чак[3].

Не надо, не надо, не надо, друзья,
Гренада, Гренада, Гренада моя[4].

Борынгыларның мондый өчле кабатлауда магик көч күрүләренең бер мөһим сәбәбе дә, безнеңчә, менә шунда: эмоциональ тәэсир көченең буыннан-буынга арта баруында. Нәкъ менә гади кабатлау булмаганга күрә дә, ул, буын саен яңа эстетик информация алып килеп, соңгысында иң югары ноктасына җитә.

[1] Махмуд Кошгари. Туркий сузлар девони («Девону луготит турк»)/ Махмуд Кошгари. – I, II, III том. - Ташкент, 1960 – 1963.
[2] Грузинские народные песни. Мифологические песни. – Тбилиси, 1972. – С. 38-40.
[3] Мазунов Мөнир. Туган як / Мөнир Мазунов // Җырлыйк әле. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. – Б. 21.
[4] Светлов М. Стихи и песни / М.Светлов. – М.: Художественная лит-ра, 1962. – С. 39.

Димәк, архаик форманың, ягъни берьюллык эчендәге өчлекнең даими рефреннар тудыруда да роле зур булган икән. Ләкин әлеге форманың шигъри-ритмик вазыйфасы моның белән генә дә чикләнмәгән. Ул, безнең күзәтүләребезгә караганда, шигырь үлчәмнәренең һәм ритмик принципларның башлангыч өлгесе дә булган. Чөнки шул бер юлда, горизонталь өчлек эчендә, вертикаль юнәлештә үсеп китәчәк ритм дулкыны да тернәкләнгән һәм гәүдәләнгән. Аерым алганда, ритмик буыннарның һәм цезураларның беренче яралгылары да, иҗекләрнең-сүзләрнең кайсы сыйфаты белән ритм тудыруда катнашуы да башлап шуның эчендә ачылган һәм ритмик сурәтләре эшләнгән. Без моның шулай булганлыгына борынгы җырлар һәм утырып җиткән соңрак чор эпослары мисалында да ышана алабыз. Менә карачайларда һәм әзербайҗаннарда сакланган магик характердагы борынгы хезмәт җырларыннан һәм казак эпосларыннан өзекләр.

Аскар, Аскар, Аскар тау,
Аскар таудың со бүркт.

Тогай, тогай, тогай су,
Тогай койдым өкінбен.

Алаң да алаң, алаң журт,
Ах, ала ордам конган журт.[1]

Булгыр, Булгыр, Булгыр тау,
Булдырып турган кургыр тау.

Долай, долай, дол гыбыт,
Сары майдан тол гыбыт[2].

Дутум, дутум, нәнәм дутум,
Сәни саган, дутум, дутум[3].

Югарыдагы мисаллардан өчлекнең 7-7 һәм 8-8 иҗекле силлабик үлчәмнәргә юл яруын һәм ритмга ачкыч ролен үтәвен күрү кыен түгел (текстларның калган өлешләрендә дә шул ук үлчәмнәр, нигездә, саклана). Билгеле, борынгы текстлар арасында иң беренче юлдагы өчлекнең озынлыгы (ягъни иҗекләр саны) белән аннан соңгы юлларның озынлыгы туры килмәгәннәре дә байтак. Алары инде башка характердагы ритмнар һәм башка үлчәмнәр өчен өлге булганнар.

Горизонталь яссылыктагы (аерым юлдагы) ритмның вертикаль юнәлешкә дә, ягъни башка юлларга да күчүе һәм дәвам итүе шигъри сөйләм эволюциясендә яңа һәм хәлиткеч баскыч булган, чөнки башлангыч үлчәм өлгеләренең ишәюе һәм строфа калыпларына үсеп әверелүе шушы баскычта башланган.

Шигырь – бердәй бердәмлекләрнең чиратлашуын гына түгел, капма-каршы башлангычларның, төрле антиподларның кабатлануын һәм үзара чәкешүен дә ярата торган сүз сәнгате. Архаик берьюллыклар һәм шуларга тәңгәл рәвештә туган күпьюллык шигъри текстлар арасында без шуларның да борынгы үрнәкләрен күрәбез. Мисырлыларның безнең эрага кадәр 800 нче елда папируска теркәлгән мифологик гимнында, мәсәлән, Кояш алласының (Ра) дошманнарыннан өстен чыгуы болай тасвирлана:

Силен Ра, слабы враги!
Высок Ра, низки враги!
Жив Ра, мертвы враги!

Напоен Ра, жаждут враги!
Вознесся Ра, пали враги!
Благ Ра, мерзки враги!

---

[1] Мухтар Магауин. Кобыз сарыны / Мухтар Магауин. – Алматы: «Жазушы» баспасы, 1968; Акындар жыры. – Алматы, 1963.
[2] Къарачай халкъ жырла. – М., 1962.– Б. 28.
[3] Азербајчан фольклору антолокијасы. – Бакы, 1968. – Б. 42.

Велик Ра, малы враги! Силен Ра, слабы враги!
Сыт Ра, голодны враги! Есть Ра, нет тебя, Апон[1].

Түбәндәге шигъри текст исә – шумерлар поэзиясеннән. Хикмәтле сүз, афоризм башлангычына охшаган бу текстта шактый кырыс һәм реаль оппозицион образ-гыйбарәләр аша ярлы кешенең мөшкел хәле сурәтләнә.

Бедняку лучше умереть, чем жить.
Если у него есть хлеб, то нет соли,
Если есть соль, то нет хлеба,
Если есть мясо, то нет ягненка,
Если есть ягненок, то нет мяса[2].

Ерак заманнардан ук килүче оппозиция алымына татарлардан да бер мисал китерик. Дүртөйле районының Шәехзадә Бабич туган Әсән авылында (Башкортстан) үзебез табып алып кайткан шәкерт дәфтәрендә шактый гына ырым текстлары бар. Борынгы магик фикерләү белән үрелгән бер бозым ырымы баштан алып ахырга кадәр ике кешенең арасын бозуга юнәлдерелгән капма-каршы янәшәлекләрдән тора.

Аю берлән бүре сәүешкәндә,
(Бу фәләннәр) шунда (ягъни шул чакта) сәүешсен.
Эт берлән мачы тату булганда,
(Бу фәләннәр) шунда тату булсын.
Адәм берлән шайтан сәүешкәндә,
(Бу фәләннәр) шунда сәүешсен.
Елан берлән бака тату булганда,
(Бу фәләннәр) шунда тату булсын.
Урман иясе берлән Шүрәле сәүешкәндә,
(Бу фәләннәр) шунда сәүешсен.
Мачы белән сычкан тату булганда,
(Бу фәләннәр) шунда тату булсын[3].

Мондый үрнәкләрнең чишмә башы, безнеңчә, беренче башлап борынгы фикерләү составында барлыкка килгән парлы оппозиция алымына, ягъни бинар (латинча binarus – икеле) системага корылган фикер сөрешенә барып тоташа. Тикшерүчеләр ачыклавынча, борынгылар мифларын һәм йолаларын да, табигатьтәге һәм тормыштагы төрле нәрсәләрне, күренешләрне дә бер-беренә капма-каршы торучы парларга берләштереп күзаллаганнар, ягъни тирә-яктагы бөтен нәрсәне «без»неке яки «алар»ныкына («читләр»некенә), «ир-ат »ныкы яки «хатын-кызлар »ныкына, гадәтигә яки изгегә, яхшыга яки начарга һәм башка төрле антиподларга бүлеп аңлаганнар[4]. Хәтта бүленмәс бер бөтенне дә икегә аерганнар һәм, киресенчә, үзара берләшми торган нәрсәләрдән дә пар ясаганнар. Мәсәлән, бүре белән төркиләр үзара кардәш

---

[1] Матье М.Э. Древнеегипетские мифы / М.Э.Матье. – М.-Л., 1956. – С. 41-42.
[2] Сэмюэл Н. Крамер. История начинается в Шумере / Сэмюэл Н. Крамер. – М.: Наука, 1963. – С. 145.
[3] Бакиров М.Х. Ырымнар / М.Х. Бакиров // Мирас. – Казан: 2003.– №1. – Б. 24.
[4] Иванов В.В. Двоичная символическая классификация в африканских и азиатских традициях / В.В. Иванов // Народы Азии и Африки. – М., 1969.– №5.– С. 206-236; Клод Леви-Стросс. Структура мифов / Клод Леви-Стросс // Вопросы философии. – М., 1970. №7. – С. 152-164; Поршнев Б.Ф. Социальная психология и истерия / Б.Ф. Поршнев. – М.: Наука, 1979. – С. 232.

дип уйлау, кояш белән айны ир белән хатын итеп күз алдына китерү, елан токымын изгеләштерелгән бер башлы ләү-сазаган һәм күп башлы дошман аждаһага аеру, бер-берләреннән кыз-кәләш алучы ике кабиләне бер дуаль (латинча duo – икеле) парга берләштерү һ.б.

Әмма матди һәм рухи дөньяны парлы оппозицияләрдә кабул итү логикасы акрынлап чынбарлыкка чыннан да хас булган бинар полюсларны, ягъни капма-каршы ике башлангычтан торучы күп санлы парлы объект-күренешләрне ачарга һәм ныграк танып белергә дә нык ярдәм иткән. Һәм нәкъ менә шуның җирлегендә телебездә төрле антонимнар (капма-каршы мәгънәле сүзләр) һәм объект-күренешләрне яки сыйфатларны парлы-парлы итеп төркемләү, барлыкка килгән: уң – сул, күк – җир, яшәү – үлем, кыш – җәй, изге – явыз һ.б.

Табигый инде, халык иҗатында, эпик һәм лирик шигърияттә дә парлы оппозицияләрнең күп төрле үрнәкләре формалашкан. Шулай ук һәр культуралы халыкның язма классик поэзиясендә дә фольклордан килүче капма-каршы башлангычлар һәм шагыйрьләр үзләре ачкан яки башлап кулланышка керткән төрле оппозицияләр кулланылган. Һәм басым ясап әйтергә кирәк: мондый парлы антиподлар бүгенге поэзиянең дә егәрлеген, форма–стиль төрлелеген билгелүче бер сыйфат булып кала һәм аерым шагыйрьләр тарафыннан шуңа нигезләнгән беръюллык шигырьләр дә, шулай ук ике, өч, дүрт юллы строфалар да иҗат ителә. Менә рус һәм татар шагыйрьләре Василий Субботиннан һәм Равил Фәйзуллиннан беръюллык парчалар.

Окоп копаю, может быть — могилу[1].

Көнемнең таҗы – Син китергән төн.
Тынычлык ул –- иң бөек илаһи музыка.
Шәфәкъләр алсу-алсу, дөньялар ямансу[2].

Әлеге мисаллар уңае белән шуны әйтергә кирәк: төрле халыкларның хәзерге заман поэзиясендә дә берьюллыкларның яшәве һәм үзенә бер строфа төре («моностих») тәшкил итүе шигырь теориясендә кануни күренеш буларак таныла.[3] Көйләп яки ярым такмаклап кат-кат кабатлауга исәп ителмәгәнлектән, бүгенге берьюллыкларда мәгънәви һәм ритмик гармония, билгеле, аеруча нык сизелеп торырга тиеш. Шулай булмаган тәкъдирдә алар шигырь буларак кабул ителмиләр.

Гаҗәеп көчле яңгырашлы, көтелмәгән башлангычларны үзара чәкештерүе һәм диалектик бер бөтен тәшкил итүе белән күңелне әсәрләндерүче ике һәм дүртьюллыкларга да мисаллар китерик.

Сергей Есенинннан:

Если крикнет рать святая:
«Кинь ты Русь, живи в раю!»
Я скажу: «Не надо рая,
Дайте родину мою».

---

[1] Субботин Василий. Строки / Василий Субботин. – М.: Советский писатель, 1972. – С. 45.

[2] Фәйзуллин Равил. Кыска шигырьләр / Равил Фәйзуллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – Б. 5-10.

[3] Шунаева С. Строфика современного русского стиха / С.Шунаева // Научные труды филологического факультета Киргизского ГУ. – Фрунзе, 1972. – Вып. XVIII. – С. 57-58.

Сердце остыло, и выцвели очи...
Синее счастье! Лунные ночи!

Габдулла Тукайдан:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшенең иң ачы һәм татлысы!

Дәрдмәнттән:

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туып-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

Сәгыйть Рәмиевтән:

Мине утка салган ул – син,
Мине суга салган да – син,
Утта янсам, суга батсам,
Тартып алган Аллам да – син.

Зөлфәттән:

Илне дөрләтерлек ялкын ята
Җил иркендә калган гомердә.

Илдә көчек булсаң да бик ярый,
Тик ил өчен кирәк өрергә!

Мин былбылдан сезне чактырырмын,
Тыңлатырмын елан сайравын.

Без алда кабатланучы берьюллык сөйләм лирик иҗатның гына түгел, ә эпик поэзиянең дә иң борынгы шигъри формасы булган дигән фикер әйттек. Болай дигәндә, без халык иҗатындагы вакыйгалылыкка нигезләнгән эпик шигырьнең яки эпос-дастан жанрының тернәкләнү чоры турында сүз алып барабыз. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, халык эпосы яралганда, жанрның урта гасырлардагы классик төренә (мәсәлән, угызларның «Коркыт дәдәм китабы», кыргызларның «Манас», үзбәкләрнең «Алпамыш», каракалпакларның «Кырык кыз», татарларның «Идегәй» кебек дастаннарына) хас күпъюллык строфа төре (тирада, сарын) әле формалашмаган була. Шуңа күрә дә безнең көннәргә килеп җиткән борынгы эпик җыр-шигырьләр арасында мондый ирекле һәм күптезмәле строфаларга корылмаган архаик текстлар очравы бер дә гаҗәп түгел.

Менә XX йөз башында Г. Ландман исемле европа галиме яңа Гвинеяда яшәүче киваи кабиләсеннән язып алган һәм соңыннан Б. Путилов игътибар иткән мифологик эчтәлекле эпик җыр яки эпос яралгысы. Ул нибары 16 юлдан тора һәм, җирле мифологик сюжетта тасвирланганча, папуаслар арасында иң беренче булып әҗәлне татыган культура герое Сидоның җир өстендәге тормышы (тулырак итеп әйткәндә, булачак хатыны Сагару белән ничек танышулары, катлаулы никах мөнәсәбәтләре һәм аның өчен көндәше Меури белән көрәшеп һәлак булуы) турында сөйли. Ахыр килеп, Сагаруның ире җеназасы өстендә йола сыктавы башкаруы, теге дөнья белән тоташтыручы елга буенда хушлашып, мәңгелеккә аннан аерылуы бәян ителә. Героик эпос жанрына хас булган каһарманнарча никахлашу, кәләш өчен батырларча алышу һәм көрәшеп корбан булу мотивларына нигезләнгән әлеге текстта вакыйгалар агышы җәенке һәм эзлекле сюжетка салып тасвирланмый, ә эчтәлекнең аерым өлешләрен өзек-өзек итеп гәүдәләндерүче һәм кайчакта

кинаяле яки «ачкыч» сүзләр ярдәмендә генә хикәяләүче мөстәкыйль шигъри юллар аша бирелә. (Кат-кат тәрҗемә итү аркасында мәгънә төсмерләре бозылмасын өчен, эпосның текстын чыганактагыча русча тәрҗемәдә калдырабыз.)

1. Я иду на хорошие танцы в Яса.
2. Он тронул юбку девушки в Яса.
3. О куруа, лестница Сидо, она возвращается назад в Уцо.
4. Сагару приходит рассерженная, располагается в Яса.
5.В Яса Сагару, хорошая женщина, влезает на вершину набеа.
6. Сидо подходит к набеа и думает: «С какой стороны мне рубить его».
7. Сидо выкликает западный ветер: «Приди свалить набеа».
8. Ветер сваливает набеа и мою жену.
9. Сидо посылает птичку Сараре к Сагару.
10. Сагару отсылает птичку гимае: «Возвращайся на то место, откуда ты пришла».
11. Сидо бьется с лесным человеком Меури каменной дубинкой, но не убивает его.
12. «Мой дорогой супруг, все время он со мной, он преследовал меня все время, теперь он мертв».
13. Маленький попугай, положи мертвого в каноэ.
14. Сагару кладет Сидо в каноэ Сибири, везет его на другую сторону.
15. Слабый юго-восточный ветер несет Сидо.
16. Сидо кричит у водной ямы возле Боигу[1].

Героик характердагы эпос яралгысының әнә шулай аз санлы юлларга гына нигезләнүенең сәбәбе, барыннан да элек, архаик традиция һәм күнегелгән иң элгәрге эпик канун белән бәйле. Ачыклап әйткәндә, эпос үзәгендәге мифик геройлар һәм аның нигезенә салынган мифологик сюжет кабилә әгъзаларына, аны башкаручыларга, һичшиксез, таныш булган һәм асылда шулар контекстында аңлап кабул ителгән. Әмма бу очракта безнең өчен иң кызыклысы – эпосның нәкъ менә нигездә берәр юлдан торучы һәм миф контекстында тулы мәгънә алучы микротекстларга бүленүе; димәк, иң архаик җыр-шигырь төзелешенә, дөресрәге – иң элгәрге строфа төренә нигезләнүе. Ландман язып алган әлеге эпик әсәрнең һәр юлы, башлап җырлаучы (соло) һәм бии-бии түгәрәк әйләнүче кабилә әгъзалары (хор) тарафыннан күп мәртәбәләр кабатлана-кабатлана, бер үк көйгә җырлап башкарылган. Шул рәвешле бер юл башкарылып туктагач, икенчесенә күчелгән, аннары – өченчесенә һәм калганнарына.

Димәк, мифологик эчтәлекле сюжетны өзек-өзек микротекстлар – кат-кат тәкърарлауга исәп ителгән мөстәкыйль берьюллыклар аша чагылдыру эпик поэзиянең иң борынгы героик төренә – архаик-мифологик эпос башлангычына да хас булган, һәм бу табигый да. Эпос белгече С.Ю. Неклюдов бик хаклы язганча, «Наиболее древние формы эпического

[1] Gunner Landman. The folk-tales of the kiwal papuas / Gunner Landman. – Helsingfors, 1917; Acta sosietatis scientiaris fenrikae. – T. XLVII. – P. 116–117; Путилов Б.Н. Алда күрсәтелгән хезмәт / Б.Н. Путилов. – Б. 64-67.

повествования, как правило, отличались сравнительно небольшим объемом и соответственно небольшим событийно-временным охватом»[1].

Классик эпоста кулланылучы күп юллы тирада-сарын формасына килгәндә исә, бу шәкел, безнең карашыбызча, шигырь төзелеше һәм строфика эволюциясенең, шулай ук эпос үсешенең икенче, хронологик яктан соңрак баскычында барлыкка килгән булырга тиеш. Алда искәртеп үткәнчә, шигырь төзелешенең вертикаль юнәлештәге эволюциясе бер үк юлны сүзгә-сүз кабатлаудан акрынлап шул ук тезмә өлгесендә башка тәңгәл юллар тудыруга күчү рәвешендә, ягъни бер үк типтагы, ләкин һәркайсы яңа, өстәмә мәгънә алып килүче тезмәләрне ишәйтү юнәлешендә барган.

Хотя ты уходил, да придешь ты!
Хотя ты спал, да проснешься ты!
Хотя ты умер, да оживешь ты!

Встань! Посмотри, что сделал тебе твой сын!
Проснись! Услышь, что сделал тебе Гор!
Он поразил для тебя поразившего тебя,
Он убил для тебя убившего тебя,
Он связал для тебя связавшего тебя.

Исиди тебя омывает,
Нефтида тебя очищает[2].

Образлы-синтаксик тәңгәллекнең бик борынгы классик үрнәге булган бу шигъри текст - «үлүче-терелүче» җир асты алласы Осириска (Осирис - Йосыфның ерак прототибы) багышланган мифологик эпостан бер өзек. Мисыр пирамидасының эчке стенасына язылган әлеге текст баштан алып ахырга кадәр төрле төзелешле һәм төрле эчтәлекле җөмләләрнең яки гыйбарәләрнең кат-кат кабатлануына нигезләнә. Ләкин һәр төр гыйбарәнең (юлның) тәңгәл ишләрендә җөмлә төзелеше һәм сүз тәртибе үзгәрмичә сакланганлыктан һәм текстта гыйбарәләр төзелеше төрләнеп, алышынып торганлыктан, төрле ритмик вариантлар чиратлашуына корылган гаҗәеп үзенчәлекле образлы-синтаксик тәңгәллек барлыкка килә. Аерым алганда, эпос өзеге тәңгәл җөмләләрнең яки юлларның төренә, составына бәйле рәвештә дүрт ритмик төркемгә бүленеп тора.

Шушындый ук характердагы мисаллар шумерларның, һинд-иранларның, алтай телләре семьялыгына керүче халыкларның борынгы эпик поэзиясендә дә шактый күп очрый. Бу инде, димәк, беренче булып В.М. Жирмунский тарафыннан ачыкланган эпоска хас күп буынлы яки күп юллы параллелизм күренеше[3], безнең карашыбызча, алда без тикшергән архетип берьюллыктан үсеп чыккан дигән сүз. Ягъни башка юлларны беренче яки үзеннән алдагы юлга тәңгәл итеп китерү һәм бер-беренә сара-сара ишәйтү җирлегендә барлыкка килгән дигән сүз.

---

[1] Неклюдов С.Ю. Закономерности стадиальной эволюции эпоса Центральной Азии и Южный Сибири / С.Ю.Неклюдов // MONGOLICA. Памяти акад. Б.Я.Владимирцова. – М.: Наука, 1986. – С. 76.

[2] Матье М.Э. Алда күрсәтелгән хезмәт / М.Э.Матье. – Б. 113.

[3] Жирмунский В.М. Ритмико-синтаксический параллелизм как основа древнетюркского народного эпического стиха / В.М.Жирмунский // Вопросы языкознания. – М.,1964. – №4. – С. 21-39.

Табигый ки, төрки телләргә хас сүз тәртибе буенча, ерак бабаларыбызның синтаксик тәңгәллеккә корылган борынгы эпик һәм лиро-эпик текстларында фигыль-хәбәрләр күпчелек очракта җөмлә яки шигырь юллары ахырына туры килә. Бу алым хәтта, өлешчә булса да, кече куләмле аерым жанрларга да үтеп кергән. Менә Алтай төбәгендәге бер тауның кыя ташына рун хәрефләре (төркиләрнең борынгы алфавиты) белән язылган келәү-алгыш үрнәге. Анда беренче юл төзелешен кабатлаучы күпьюллыкларда кабилә тавының иясеннән тормышны җитеш һәм мул итеп коруда ярдәм итүе сорала.

Agin toli, tuq qil,
Дn (=an) jagimi inč qil,
Өiq (=өok) inagi bar qil
Цlц (=ала) kьsagič өat qil,
Baj alip kej, al kej.

Барын җитеш, тук кыл,
Җәнлекле ягымны имин кыл,
Зур дуслыкны бар кыл,
Өмет-теләкләрне көткәнчә кыл,
Куәтле kej, бөек kej[1].
(«Kej» – муллык мәгънәсендә).

Сүз уңаенда синтаксик тәңгәллек җирлегендә формалашкан тагын бер кызыклы үзенчәлеккә тукталып китү сорала. Бу очракта без синтаксик яктан үзара тәңгәл юллар эчендә бер-берләренә саннары буенча да тәңгәл килүче сүз-буыннар барлыкка килүен күздә тотабыз. Мәкальләрдә бу күренеш ике яки, күп дигәндә, өч-дүрт юл эчендә генә гәүдәләнсә, алтай, хакас, тува һәм өлешчә казак, кыргыз кебек төрки халыкларның борынгы эposларында – күп юлларны үзенә буйсындыручы киң таралган система. Иҗекләр санын түгел, ә сүзләр санын саклауга нигезләнгән бу борынгы ритмик форма думбра чиртеп, яки сазда, лутняда уйнап шигырь әйтүче чичән-җыраулар өчен бик кулай алым булган һәм йөзләрчә юлларны импровизация юлы белән иҗат итәргә, туктаусыз башкарырга мөмкинлек биргән. Шуның белән бергә әлеге алым, текстның эчтәлегенә, образ-күренешнең хәрәкәтенә карап, юллардагы сүз-буыннар санының вакыт-вакыт икенче саннар белән алмашынуына, үзенчәлекле аралаш форма тууына да юл куйган. Менә казак җыраулары иҗатыннан бер мисал (җәя эчендә юллардагы сүзләр саны күрсәтелә):

Агасы бардың, жаксы болса жагасы бар, (6)
Жаман болса, інісіне жабар жаласы бар, (6)
Інісі бардың, жаксы болса тынысы бар. (6)
Жаман болса, агасына берер жумысы бар, (6)
Баласы бардың, жаксы болса панасы бар, (6)
Жаман болса, Кудайдың перген пелеси бар[2]. (6)

Күренүенчә, текстта сүзләр саны бар юлда да бертигез. Кыргызларның «Манас» эпос-дастаныннан алынган түбәндәге өзекләрдә исә сүзләр саны төрле вариацияләрдә килгән, һәм бу катнаш «үлчәм» тудырырга, шул юл белән бер ритмнан икенчесенә күчәргә мөмкинлек биргән.

Алтайга Манас жеткенде,(3)
Айдыны көпке кеткенде, (3)
Кыйры менеп чынданып, (3)
Кыргыз бүткен

Хан бабамын көјкүси! (3)
Гадын анамын севкиси! (3)
Атам, анам вердији, (3)
Көз ачыбан көрдүјүм (3)

---

[1] Убрятова Е.И. Древнетюркская руническая надпись из Бичикту–Бома / Е.И.Убрятова // Бронзовый и железный век Сибири. – Новосибирск: Наука, 1974. – С. 161-163.
[2] Шешендек сөздер. – Алма-Ата, 1967. – Б.138.

жыйналып,(3)
Улың жыйын топ булду, (4)
Укса камбас кеп булду, (4)
Кеп Манаска токтолду (3)

Көңүл вериб көрдүјүм, (3)
Көңүл вериб севдіјүм, (3)
Дирсә хан![1] (2)

Яки:

Бәри кәлкил . (2)
Башым бакты! (2)
Евим тахты! (2)

Кытайларның безнең эрага кадәр тотем хайваннарына багышлап иҗат ителгән «Сыңар мөгез» дигән түбәндәге келәү алгышы да бер типтагы җөмләләрне кабатлауга корылган. Әмма бу юлы билгеле бер аралыкта кабатланучы риторик эндәшләр һәм, бераз гына үзгәреп, билгеле бер тәртиптә килүче рефрен тезмәләр өч юллы строфалар тууына китергәннәр.

Единорог! Своим копытом
Ты наших сыновей сохрани!
О ты, Единорог!

Единорог! Своим челом
Семью ты нашу сохрани!
О ты, Единорог!

Единорог! Своим рогом
Ты наш род сохрани!
О ты, Единорог![2]

Америка индеецлары науаларның җирле аллалар анасына – Тетеоиннанга багышланган түбәндәге гимнында да билгеле бер тәртиптәге кабатлаулар өчәр юллы строфалар барлыкка китергән. Текстларның эчке төзелешендә һәм эчтәлегендә күпмедер аермалар булуга карамастан, «Сыңар мөгез» келәвендәге һәм әлеге гимндагы һәр ике төр строфа да асылда архаик характерда, ягъни бер һәм ике юллыктан үсеп чыккан тәңгәлләр, бер типтагы кабатлаулар җимеше булып торалар.

Ах, желтый цветок раскрыл лепестки,
То наша мать, лицо спрятав под маской,
Из Тамоанчана в край наш пришла.

Ах, белый цветок раскрыл лепестки.
То наша мать, лицо спрятав под маской,
Из Тамоанчана в край наш пришла[3].

Аерым халыклар иҗатында катлаулы бәйләнешкә корылган өчьюллык строфа калыплары акрынлап активлашып, нормалашып киткәннәр һәм классик поэзиягә дә үтеп кергәннәр. Моның төрле характердагы күп санлы үрнәкләрен без кытайларның иң борынгы лирика энциклопедиясе-тупланмасы саналган «Шицзин»да да, шулай ук японнарның язма шигъриятендә дә очратабыз. Катаута (5-7-7 иҗекле үлчәм) һәм хокку (5-7-5 иҗекле үлчәм) дип атала торган япон шигъри шәкел-формалары, мәсәлән, әнә шундыйлардан.

---

[1] Манас. Беренче бүлек. I китап. – Фрунзе, 1958. – Б. 124-241, 198.
[2] Позднева Л.Д. Литература древнего Китая / Л.Д. Позднеева // Литература древнего Востока. – М.: Изд-во МГУ, 1971. – С. 258.
[3] Кецаль и голубь. Поэзия науа, майя, кечуа. – М.: Художественная литература, 1983. – С. 42.

Янә килеп, борынгы традициягә нигезләнүче өчьюллык строфа төрләре теге яки бу дәрәҗәдә төрки халыкларда, шул исәптән татар сүз сәнгатендә дә урын алган. Түбәндәге мәкальләр һәм һәр юлы ике мисрагтан, ягъни ике ярты юллыктан торучы мөнәҗәтләр моңа ышандыргыч дәлил була ала.

Эт өреп картая,
Егет йөреп картая,
Кыз көлеп картая.

Кызыл төлке – җир күрке,
Матур егет – ил күрке,
Матур кызлар – өй күрке[1].

Алла сине бар итте, үзенә һәм яр итте,
Рәсүлләргә таҗ итте, йә Мөхәммәд Мостафа!
Саллалаһе галәйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!
(«Йә Мөхәммәд Мостафа»).

Исрафил сурын өргәй, йә Хәбибем, тор, дигәй.
Лә Иляһи, тормаймын өммәтләрем тормыйча,
Гөнаһлы өммәтләрем «ярлыкагыл» димичә.
(«Исрафил сурын өргәй»)[2].

Өчьюллыкка корылган шигырь текстларын язма поэзиябездән дә күпләп китереп булыр иде. Шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Шамил Әнәк халык иҗаты традицияләрен дәвам итеп һәм үстереп, әлеге тип строфаның төрле вариантларын тудырдылар, шул исәптән ак шигырь шәкелендәге рифмасыз үрнәкләрен дә иҗат иттеләр. Шул ук вакытта әлеге шагыйрьләр иҗатында беренче башлап эпос-дастан шигырендә, йола фольклорында һәм магик поэзиядә (ырымнарда) формалашкан катнаш үлчәмле шигырь үрнәкләре дә барлыкка килде.

Берьюллыкны кат-кат сүзгә-сүз кабатлау алымыннан кабатланмый торган текстлар иҗат итүгә күчүнең иң архаик бер ысулы ике юллык строфа төрен үзләштерү белән бәйләнгән. Монысы инде, алда әйтелгәнчә, строфаларга бүленешне яратучы лирик поэзиядә, шулай ук иң кечкенә һәм афористик жанр үрнәге булган мәкальләрдә тернәкләнгән. Берьюллыктан ике юлга күчү төрлечә гамәлдә ашырылган. Мәсәлән, шуның бер ысулы ике ритмик буынлы яки ике ярым (ярты) юллы (гарәп-фарсы термины белән әйткәндә, ике мисраглы) тезмәне цезура үтә торган җирдән ике юлга бүлүгә корылса, икенчесе – кабатлана торган юлга катализатор вазыйфасын, ягъни төрләндерү-үзгәртү ролен үтәүче өстәмә сүзләр кертеп җибәрү рәвешендә булган. Бу исә сүзмә-сүз кабатлаудан качарга, яңа төр кабатлаулар һәм яңа мәгънәви-ритмик вариацияләр тудырырга мөмкинлек биргән. Шул юл белән әлеге алым бер үк төрле кабатлау инерциясен җиңәргә һәм ритмик тәңгәллеккә, мәгънә үзгәрешенә корылган ике юллыклар иҗат итәргә юл ачкан. Мисал өчен дүрт мең ел чамасы элек шумерлар иҗат иткән иң борынгы мәхәббәт лирикасы үрнәгенә мөрәҗәгать итик. Җирле ышану һәм йола буенча, шумер патшасы, ел уңдырышлы килсен өчен, ел да бер кызга өйләнергә тиеш булган. Әлеге җыр-гимн менә шул «изге никах» вакытында башкарылган.

---

[1] Татар халык мәкальләре / Төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. – Т.1. – Б. 38, 45, 217.
[2] Мөнәҗәтләр һәм бәетләр / Төз. К.М. Хөснуллин. – Казан: Раннур, 2001. – Б.14, 43.

**Супруг,** дорогой моему сердцу,
Велика твоя красота, сладостная, точно мед.

**Лев,** дорогой, моему сердцу,
Велика твоя красота, сладостная, точно мед[1].

Ә монысы – Тын океандагы Мариан утаруларында ыруглык тормышы белән яшәүче кабиләдән язып алынган җыр. Аны хатын-кызлар күмәк рәвештә яр буенда башкарганнар. Кабат-кабат җырлаганда текстагы сан күрсәткече генә («алты», «җиде» һ.б.) үзгәреп, алышынып торган.

**Эзылог** о но лого дилдину.
**Оалог** о но лого дилдину[2].

Диңгездә алты мәртәбә чумыла,
Диңгездә алты мәртәбә өскә чыгыла.

Борынгы уйгурлар иҗатыннан да бер-ике мисал китерик. Таң алласына багышланган гимн, мәсәлән, мондый юл белән башлана һәм икенче юлда баштагы гыйбарәгә бер сүз өстәлә:

Таң teņri kelti,
Таң teņri цzi kelti.
Таң tenri kelti,
Таң tenri цzi kelti[3].

Шигъри сөйләмгә корылган юрау китабының (VIII йөз) түбәндәге юлларында төрләндерүче, өстәмә информация алып килүче сүзләр саны инде күбрәк. Шул ук вакытта, беренче юлдагы кебек үк, әлеге алмаш, катализатор сүзләр эчке, горизонталь аллитерация таләбен дә саклаганнар (чагыштырыгыз: б-б, к-к).

Buz bulut jцrьdь **budun** ьzд jagdu,
Qara bulut jцrьdь **qamug** ьzд jagdu[4].

Соры болыт гизде, халыкка яуды,
Кара болыт гизде, бөтен җиргә яуды.

Тагын бер җитди искәрмә: тикшереп үтелгән мисалларда алда сүз барган парлы оппозиция, контрастлык алымы да якыннан торып катнашкан. Ачыклап әйткәндә, әлеге алым аерым объект-күренешләрне яки гамәлләрне капма-каршы кую рәвешендә дә, шулай ук тәңгәл образларны яңа сыйфатлар өстәп баету, градацияләп үстерү төсендә дә гәүдәләнгән. Мондый шәкелләрне үзләштерүгә, һичшиксез, мәкальләрнең хөкем-фикерләү төзелеше дә ярдәм иткән, һәм хикмәтле сүз сәнгате белән шигърият асылда үзара «кан алмашып», бер-берсенең казанышларыннан файдаланып үскәннәр. Нәтиҗәдә

---

[1] Сэмюэл Н.Крамер. Алда күрсәтелгән хезмәт / Сэмюэл Н.Крамер. – Б. 243.
[2] Путешествие в Южный океан и Беренгов пролив для отыскания северо-восточного морского прохода. – Спб., 1823. – Ч. III. – С. 79-80.
[3] Тугушева Л.Ю. Поэтические памятники древних уйгуров / Л.Ю. Тугушева // Тюркологический сборник, 1972. – М.: Наука, 1973. – С. 239.
[4] Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности / С.Е.Малов. – М-Л.: Изд-во АН СССР, 1951. – С. 84.

кабатлаулардан башланган һәм яңа үзенчәлекләр белән баеган ике юллыкларның бик күп төрләре барлыкка килгән.

Хәзерге поэзиядә актив кулланыла торган дүртьюллыкларның «кендеге» дә, миңа калса, ике юллыкларга гына түгел, ә шуларга җирлек булган берюллыкларга да барып тоташа. Дүртьюллыклар туының бер борынгы чыганагы яки ысулы – берюллык өлгесендә тәңгәл юллар санын ишәйтү. Моның бик күптәнге яки архаизм рәвешендә дәвам иткән үрнәкләрен төрле халыкларда очратырга була. Менә Шу-Син исемле шумер патшасының әнисе Абисимтига багышланган гимнан бер строфа.

**Она** дала жизнь тому, кто чист.
**Это мать** дала жизнь тому, кто чист.
**Абисимти** дала жизнь тому, кто чист.
**Царица** дала жизнь тому, кто чист[1].

Ә монысы – безнең эрага кадәр ике меңенче еллар уртасында һинд-иран (ария) кабиләләре арасында иҗат ителә башлаган «Ригведа» җыентыгындагы гимннан. Аны патшаны беренче башлап тәхеткә утыртканда башкара торган булганнар.

dhruvā dyaъr dhruva prthivн
dhruvāsah pбrvata imй
dhruvām visvam idбm jadad
druvo rāja viśam ajam

Твердо небо, тверда **земля,**
Тверды **горы эти,**
Тверд **весь этот мир,**
Тверд **этот царь племен[2].**

Әлеге дүртьюллыкларның икесендә дә кабатланучы тезмәләр үсә баручы градация барлыкка китергәннәр, ягъни һәр юл үзеннән алдагы юлдан, борынгылар карашынча, куәтлерәк информация алып килүгә исәп ителгән һәм иң югары нокта йомгаклап куючы соңгы юлга туры килгән. Шушы ук архаик алымга корылган дүртьюллыкларны без төрки халыклар иҗатында да очратабыз. Түбәндәге караим җыры шуның бер дәлиле була ала.

Лапа-лап кар йава,
Эрби баба кой сойа,
Хазар оглу ат чаба,
Байларымыз той чала (уткәрә)[3].

Ләкин дүрт юлда да бер типтагы җөмләләр яки гыйбарәләр кабатлануы бер тонлы ритмик инерция дә тудырган. Шушы инерцияне текстның соңгы юлында туктату, дүртьюллык строфага тәмамланган төсмер бирү өчен, акрынлап яңа ритмик алым (катализатор) үзләштерелгән. Бу очракта без соңгы юлның капыл гына башка ритмга күчүен һәм башка типтагы гыйбарә белән дүртьюллыкны очлап, тәмамлап куюын күздә тотабыз. Менә борынгы

---

[1] Сэмюэл Н.Крамер. Алда күрсәтелгән хезмәт / Сэмюэл Н.Крамер. – Б. 245.
[2] Елизаренкова Т.Я. Древнейший памятник индийской культуры / Т.Я.Елизаренкова // Ригведа. – М.: Наука, 1972. – С. 76.
[3] Мусаев К.М. Грамматика караимского языка / К.М. Мусаев. – М.: Наука, 1964. – С. 78.

төрки поэзиядән Мәхмүд Кашгари җыентыгында (XI йөз) теркәлгән характерлы мисаллар.

Этил суы ака торур,
Кайа төпи какка торур,
Балык тәлим бака торур,
Көлүң такы күшәрүр.

Әрән алпы окуштылар,
Кыңыр көзин бакыштылар,
Камуг толмун токуштылар,
Кылыч кынка күчүн сыгды[1].

Безнең күзәтүләребезгә караганда, нәкъ шушы шигъри ритм-үлчәм (4+4=9) күп төрки халыкларда, атап әйткәндә, уйгыр, алтай, әзербайҗан, гагауз, төрек поэзияләрендә борынгыдан ук килүче бер традиция буларак сакланган, дәвам иткән. Бер үк вакытта бу ритм-строфа калыбы татар мөнәҗәтләренең дә яраткан бер үлчәменә әверелгән. (Тик әлеге үлчәмдәге текстларны озын үлчәмгә әверелдереп, бәет рәвешендә ике юл итеп язу гадәткә кергән. Без исә, борынгы ритм-метр калыбы башкаларга да аңлашылсын, күренеп торсын өчен, мисалларыбызны дүрт юл итеп бирәбез.)

Ата дисәм, авырый башым.
Ана дисәм, түглә яшем.
Чит илләрдә ялгыз башым.
Аерылдым туганнардан.

Йортың вәйран кала дими,
Хәләл әнкәң кала дими,
Авыр кайгы салам дими,
Бу ни гаҗәп үлемдер (бу)[2].

Әгәр югарыда анализланган мисалларда һәр дүрт тезмә яки баштагы өч юл бер үк типтагы, ягъни үзара тиңдәш җөмләләрдән торсалар, ике юллыклардан үсеп чыккан дүртьюллыкларда инде бик еш бер-берсенә тәңгәл яки капма-каршы торучы мәгънәви-семантик парлар барлыкка килә. Асылда тәүге ике юлы табигатьне тасвирлауга, соңгы ике юлы исә авторның яки лирик геройның хис-тойгыларын сурәтләүгә нигезләнгән образлы-психологик параллелизм алымы да парлы тәңгәллек яки парлы оппозиция мирасы булып тора. Мондый дүртьюллыклар арасында шулай ук табигать образлары белән психологик кичерешләр гаҗәеп дәрәҗәдә керешкән, бер бөтен булып үрелгән төрләре дә юк түгел. Ике юллыклар җирлегендә туган һәм ике башлангыч тәңгәллегенә корылган мондый дүртьюллыкларның иң борынгы классик үрнәкләре кытай поэзиясендә аеруча еш очрый. Безнең эрага кадәр XII-V йөзләрдә үк иҗат ителгән поэтик әсәрләр тупланмасы «Шицзин»ны тәрҗемә итүче А. Штукин «каждому синологу известен параллелизм как изощреный и любимейший художественный прием в Китае» дип юкка гына язмаган[3]. Менә шул җыентыктан аерым мисаллар:

Ветер с дождем холодны, словно лед...
Где-то петух непрерывно поет.
Толко, я вижу, супруг мой со мной –
Разве тревога в душе не замрет?

Вышла на небе луна и ярка, и светла...
Эта красивица так хороша и мила!
Горечь тоски моей ты бы утешить могла;

---

[1] Махмуд Кошгари. Алда күрсәтелгән хезмәт / Махмуд Кошгари. – I том. – Б. 103, 192.
[2] Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. – Б. 262, 286.
[3] Шицзин. Книга песен и гимнов / Шицзин. - М.: Художественная литература, 1987. - С. 11.

Сердце устало от думы, и скорбь тяжела.

Нет, я не орел и не коршун... Крыльями
Взмахнул бы я, к небу направив полет!
Нет, я не осетр и не малая стерлядь,
Сокрылся бы я в бездну глубокую вод![1]

Тарихи-чыгыштырма мәктәбе вәкиле, күп халыкларның фольклор һәм әдәбияты белгече, профессор А.Н. Веселовский образлы-психологик параллелизм күренешенең иң борынгы җирлеген табигать белән кешене тиңләштерүгә һәм шул мифологик фикерләү нигезендә ике буынлы тәңгәллек барлыкка килүгә бәйләп аңлата. Мифологик ышану юкка чыканнан соң исә, кешегә һәм аның рухи халәтенә, эш-гамәленә тиңләштерелгән табигать образлары чагыштыруларга һәм символларга әверелгәннәр, төрле троплар (троп – кинаяле, күчерелмә мәгънәле гыйбарә яки сурәтләү чарасы) тудыруда катнашканнар, һәм табигый ки, образлы-психологик тәңгәллек бер һәм ике юллыклар эчендә дә, шулай ук өч һәм дүртьюллыкларда да гәүдәләнә алган, һәм хәзер дә бу шулай.

Инде хәзер, берьюллыктан башланган сыйфат һәм сан үзгәрешләренең төрле типтагы ике юллыклар һәм дүртьюллыклар тууына китерүен күзәтеп чыкканнан соң, шәкел-строфика өлкәсендәге кайбер соңрак казанышларга да игътибар итү урынлы булыр дип уйлыйм. Әмма, сүзне озынга сузмас өчен, бу юлы гомумтөрки һәм татар шигъриятендәге аерым бер юнәлештәге мисаллар белән чикләнү дә җитәчәк. Шундый мисалларның иң характерлысы – беренче башлап казак шагыйре Абай Кунанбаев (1845–1904) иҗатында кулланылган «алты аяк» дип йөртелүче строфа. Мәгълүм булуынча, Абай – казак язма поэзиясенә нигез салган һәм традицион төрки строфалар төзелешенә үзенчәлекле реформа ясаган сүз остасы. Сүз бара торган «алты аяк», ягъни алты тезмәле, янәшә һәм юл аша рифмалы строфа калыбында иҗат ителгән «Бойы булгаң» шигыре моңа мисал була ала.

Бойы булгаң,
Сөзі жылмаң,
    Кімді көрсем, мен сонан;
Betti бастым,
Каtti састым,
    Тура каштым жалма-жан[2].

Абайның шактый шигырьләренә өлге булган әлеге строфа төре бик кызыктыргыч һәм йогынты ясаучан, таралучан булып чыга. Аның үрнәкләренең соңыннан казак шагыйрьләре Бешмбет Майлин, Сәкен Сейфуллин, Беркияз Кулеев, кыргыз шагыйре Аалы Токомбаев, каракалпак шагыйре Хожамет Ахметов, кумык шагыйрәсе Шейит-ханум Алишева, караим шагыйре Ш. Фирковичның иҗатында да урын алуы шуны раслап тора. Менә Фирковичның «Čуty erda» дигән шигыреннән бер строфа.

Bunda jaөlar,

[1] Шунда ук. – Б. 79, 111, 184.
[2] Кунанбаев Абай. Шыгармаларының толык җыйнагы / Абай Кунанбаев. – Алма-Ата, 1954. – Т.1. – Б.110.

Anda irlar,
    Kyzny erda beradlar,
Ana ajtty,
Ata kuөty,
    Kyzny juvdan suradlar[1].

Күренүенчә, әлеге текстта рифмалар юл башларына да күчкән. Борынгы хазар, бәҗәнәк һәм кыпчак кабиләләре катнашмасыннан торган караимнарның (XIV – XV йөзләрдә аларның күпчелек өлеше Кырымнан Литва, Польша һәм Көнбатыш Украина җирләренә күчереп утыртылалар) төрки төбәкләрдән шактый читтә яшәгәнлеген исәпкә алганда, 1935 елда латин шрифты белән Вильнюста басылган бу шигырьнең кайсы әдәбият йогынтысында Абай традициясенә нигезләнеп иҗат ителгәнлеген билгеләү кыен.

Әлеге традиция тәэсиреннән Көнчыгыш мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә торган татар классик язма поэзиясе дә читә калмаган. Дәрдмәнднең халкыбызның киләчәк язмышы турында борчылып иҗат иткән атаклы «Кораб» шигыре – шуның бер саллы үрнәге.

Чыкты җилләр,
Купты тулкын –
    Ил корабын җил сөрә!
Кайсы юлар,
Нинди упкын
    Тарта безне җан сорап?![2]

Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, алты юллы строфаның, «алты аяк»ның килеп чыгышы да, минем инануымча, берьюллыклардан башлангыч алучы ике юллыкларга барып тоташа. Моңа ышану өчен Мәхмүд Кашгари сүзлегендәге аерым мисалларга игътибар итү дә җитә.

Kцŋli kьjьb | qany quryb | agzu ačyb qatgurar,
Syzgurgalar | ьziklдri | assiz jьzi burqurar.

Его сгоревшим сердцем, высохшей кровью, открыв рот,
                                        он скорбит.
Страсти иссушают, лицо глупца сморщивается[3].

Шигъри ритм тойгысы булган кеше килешер: югарыдагы текстларның төзелешенә «алты аяк» калыбына үсеп әверелү мөмкинлеге салынган. Әмма моның өчен шагыйрь ритмик буыннарны (аларның бүленеш чикләре текстта цезура сызыклары белән күрсәтелде) мөстәкыйль юлларга әверелдерә һәм үзара рифмалаштыру югарылыгына күтәрелергә тиеш. Абай һәм аның яңалыгын беренче булып эләктереп алган яки дәвам иткән башка шагыйрьләр нәкъ шулай эшләгәннәр дә инде.

Татар классикларыннан Һади Такташ та – шушындый күренеш белән аваздаш казанышка ирешеп, татар шигыренә үзенчәлекле реформа ясаган шагыйрь. Аның интонацион-сөйләм шигыренә юл ярган әсәрләренең нигезендә халык җырларыннан килә торган 10-9 иҗекле үлчәм ята. Ритмик буыннарны горизонталь сызыклар һәм күпме иҗектән торуларын саннар

---

[1] Kowalski T. Karaimische texte im dialekt von troki / T. Kowalski. – Krakowie, 1929. – S. 37.
[2] Дәрдмәнд. Сайланма әсәрләр / Дщрдманд. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. – Б. 33.
[3] Стеблева И.В. Развитие тюрских поэтических форм в XI веке / И.В. Стеблева. – М.: Наука, 1971. – С. 151, 163, 254, 257.

белдән күрсәткәндә, ә цезураларны «+» белән билгеләгәндә, әлеге үлчәмнең һәм шуңа нигезләнгән строфа калыбының схемасы түбәндәгечә күрсәтелергә мөмкин:

**___4___ ___2___ ___4**
**(10)** **4+2+4=10** } **ике тапкыр**
**______ _____ ___3** **4+2+3+=9**
**(9)**
**___4___ ___2___ ___4**
**(10)**
**______ _____ ___3**
**(9)**

Такташ бу ритмик төзелешнең традицион табигатен үзгәртте: буыннарны «башка чыгарып», мөстәкыйль юлларга, цезураларны (буын араларындагы ярым тынышларны) исә тулы паузаларга әверелдерде. Нәтиҗәдә теләсә кайсы ритмик буынны аерып чыгарырга, шигырь юллары санын төрлечә үзгәртергә мөмкинлек бирә торган хәрәкәтчән ритмлы шигырь төзелеше туды. Бер үк вакытта шагыйрь, төп үлчәм кысасын саклаган хәлдә, аерым ритмик буыннарны төшереп калдыру, йә булмаса, яңа буын өстәү һәм яңа ритмик юл кертеп җибәрү алымнарын да кулланды.

Салкын карга басып Алсу килә, (10)
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле; } (9)
Үзе усал,
Үзе болай бер дә } (10)
Усал түгел кебек шикелле. (9)

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә... } (10)
**Ул тын гына**
Айга карап килеп утырды, (9)
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен (10)
Канлы яшьләр белән тутырды[1]. (9)

Белүебезчә, дөнья халыклары сүз сәнгатендә һәм татар поэзиясендә ирекле шигырь дә бар. Йола поэзиясеннән һәм шаман дога-чакыруларыннан ук башлангыч ала торган һәм шактый төрләргә-төсмерләргә тармакланган бу шигырь төзелеше хәзерге вакытта шактый актив. Ләкин темабыздан читкә чыкканлыктан, бу очракта ирекле шигырьгә бәйләнешле нибары бер үзенчәлекне генә сиздереп үтәсе килә. Силлабик, силлабо-тоник, гаруз шигырь төзелешләрендә иң кечкенә ритмик берәмлек иҗек булса, һәм ритмның нинди булуы иҗекнең табигате (басымлы һәм басымсыз, озын һәм кыска, ачык һәм ябык булып килүе) яки саны белән билгеләнсә, монда, әлеге шигырьдә, андый берәмлек – шигырь юлы (гыйбарә-синтагма яки җөмлә). Бу үзенчәлек үзе үк берьюллыкка иҗекләре төрле сыйфатлы тезмәләр ялгануга юл куя. Ләкин ирекле шигырьдә сүзләр тәртибе һәм җөмлә төзелеше дә төрле булганлыктан, әлеге төр шигырь тууын, һичшиксез, синтаксик тәңгәллеккә

[1] Һади Такташ. Сайланма әсәрләр / Һади Такташ . – Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. – Б. 162, 195.

һәм сүз-стопаларның билгеле бер санда килүләренә корылган шигырь төрләреннән соңрак дәвергә бәйләп карарга кирәктер.

Инде кабат шигырь һәм строфа төзелешенең башлангычы булган берьюллыкка әйләнеп кайтыйк. Берьюллык һәм, гомумән, берлек борынгыларның дөньяга карашына һәм мифологик күзаллауларына да гаҗәеп дәрәҗәдә туры килеп торучы үлчәм-бизмән булган. Ыруглык дәверендә яшәгән кешеләр бер санын һәр нәрсәнең башы, нигезе итеп санаганнар. Безнең эрага кадәр өч меңенче елларда Мисырда кояш алласы Ра, мәсәлән, бөтен нәрсәне яратучы, барлыкка китерүче итеп каралган һәм хәтта кайбер мифларда үзен-үзе яраткан итеп күз алдына китерелгән. Бу хакта аңа багышланган бер гимнда болай диелә:

Хвала тебе, Великий, родивший богов,
Создавший один себя самого.
Сотворивший обе земли,
Создавший себя силой плоти своей,
Сделал он тело свое сам:
Нет отца, зачавшего образ его,
Нет матери, родившей его,
Нет места, из которого он вышел[1].

Борынгы культураларда һәм мифологик системаларда шулай ук, хаостан космос тудыручы җенессез алла образларыннан тыш, бар дөньяны һәм тереклекне яратучы итеп фараз ителгән «дөнья анасы» образы да бар. Ассириялеләрнең Аруру, эламлыларның Киририша, кытайларның Нюй-ва, бурятларның Төөдәй (яки икенче версия буенча – Эхе-бурхан), чувашларның Ама исемле алиһә-аналары, мәсәлән, шундыйлардан. Моннан тыш, аерым диннәрдә һәм архаик мифологиядә дөньядагы иң беренче адәми зат яки аерым халыкларның нәсел башлыгы, беренче бабасы да ялгыз кеше итеп күз алдына китерелгән. Христиан һәм Ислам диннәре буенча, дөньядагы иң беренче кеше – Адәм, Хава (Ева) исә икенче итеп аның сул кабыргасыннан яратылган. Якут мифологик эпосында беренче кеше итеп тасвирланган Эр Согатах Эллэй – ялгыз ирнең, әтисе дә, әнисе дә юк; бурят эпос-улигерындагы Аламжи Мэрген «үзе үзеннән яралган» һәм беренче булып торак төзегән, терлекчелеккә өйрәнгән культура каһарманы.

Кыскасы, борынгы культуралар мисалыннан аңлашылганча, бер саны тәүге чорда, тәртип саны булудан бигрәк, бербөтенне, бердәмлекне белдерүче күрсәткеч булган һәм, «алла», «космос» төшенчәләре кебек үк, бар нәрсәләрнең башлангычы итеп кабул ителгән[2]. Димәк, бер бөтенне тәшкил иткән бер санының поэзия яралганда җыр-шигырьнең дә «нигез ташы», беренче кирпече булганлыгы һәм архаик күренеш буларак сакланып калуы, хәтта яңа шартларга ярашып дәвам итүе бик табигый. (Хәзерге вакытта берьюллык кушымта өлеше күп мәртәбәләр кабатланып башкарыла торган җырлар иҗат ителүен исегезгә төшерегез: «Подари мне любовь, подари мне Любовь...», яки: «Голубая луна, голубая луна...» һ.б.) Атаклы инглиз шагыйре, Нобель премиясе лауреаты Томас Стернз Элиот болай дигән: «Рискну утверждать, что поэзия начинается с дикаря, бьющего в барабан в джунглях и

---

[1] Матье М.Э. Алда күрсәтелгән хезмәт / М.Э.Матье. – Б. 85.
[2] Мифология народов мира. Энциклопедия. – М.: Советская энциклопедия, 1988. – Т.2. – С. 630.

в дальнейшем она сохраняет эту основу – ударность и ритм; метафорически можно сказать, что поэт старше, чем другие люди»[1]. Ә джунглида яңгыраган барабан тавышы нигезендә кат-кат кабатланучы ритм ятканлыгы һәм сүз сәнгатенең башлангыч дәверендә, шулай ук архаик поэзиядә шул ритмның кабатланучы берьюллык шигырь белән бергә үрелеп гәүдәләнгәнлеге безгә инде билгеле.

*Ф.И. Урманче,*
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре,
Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең халык иҗаты бүлеге мөдире,
филол. фәннәре д-ры, профессор

## *Борынгы төрки-татарларда Тәңре*

Төрки-татар мифологиясенең борынгы аллалары һәм алиһәләре турындагы мәгълүматлар бик аз сакланган. Алары да өзек-өзек кенә. Безгә — татарларга да исеме (генә!) яхшы таныш булган илаһи затлардан төрки-татар мифологиясенең “иң карт” һәм киң таралганнарыннан беренче урынны, һичшиксез, **Тәңре** алып тора. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” бу исемгә бик кыска аңлатма бирә: “Тәңре, исем. Алла, күк алласы”. Әмма шул ук исемнең бездә киң таралган булуын һәм төрле мәгънәләрдә кулланылуын ачыкларга да мөмкин, әйтик, халык телендәге кайбер гыйбарәләр нигезендә: “Тәңре хакы өчен”, “Тәңре ярдәм итсен”, “Тәңре үзе генә белсен” һ.б. Тик биредә шуны да махсус искәртеп үтү зарур: әлеге идиомаларда сүз Ислам тәгълиматы белән бәйле Алла, Аллаһы Тәгалә хакында бара, әлбәттә.

Төрки халыклардагы Тәңре — Күк алласы турындагы мәгълүматларның күпчелеге соңгы мең ярым елга, VI–XX гасырларга карый. Һәрхәлдә, кайбер галимнәр Тәңре исеменең беренче кулланылышын Урхун-Енисей язмалары, VI–VIII гасырлар белән бәйлиләр. Бу — ялгыш караш булса кирәк. Һәрхәлдә, ул Тәңре исеменең кулланылышын берничә мең елга “яшәртә”. Чынлыкта исә мәсьәлә бөтенләй башкача тора. Тәңренең төрки халыкларның иң югары дәрәҗәдәге һәм иң борынгы Күк алласы булуын башка чыганаклар нигезендә дәлилләп була. Күпаллалык чоры өчен хас булган кайбер үзенчәлекләрне истә тотып, түбәндәгеләрне әйтергә кирәк: Күк алласы Тәңренең исеме беренче тапкыр, күрәсең, язма рәвештә безнең эрага кадәрге IV–III меңеллыкларда **Борынгы Шумер пантеонында** Диңгир формасында телгә алына. Бик борынгы чорлар карашлары буенча, Диңгир бер генә алланың исеме булмаган. Бу дөньядагы тәртипне, кешеләр вә табигать күренешләре арасындагы гармонияне күп санлы **диңгирләр** тәэмин итә дип уйланылган. Уңайдан, биредә ассызыклап шуны да әйтик: төрки һәм төрки-монгол халыкларында да Тәңре бердәнбер алла исеме түгел. Тәңреләр гадәттә күп

[1] Элиот Томас Стернз. Назначение поэзии / Томас Стернз Элиот. Перевод с англ. – Киев: Airland; М.: ЗАО «Совершенство», 1997. – С. 147-148.

була һәм алар табигать, җәмгыять һәм кеше тормышының төрле өлкәләренә кагылалар. Төрле тәңреләрнең, мәсәлән, бурятларда кешегә ярдәм күрсәтүчеләре дә, явызлык кылучылары да бар дип санала.

Борынгы Шумер мәдәнияте сүнгәч, алар пантеонында киң таралган Диңгир һ.б. аллаларның исемнәре онытыла. Борынгы шумерлар яшәгән җирләрдә башка димиләр, башлыча **Зәрдөштлек–Зороастризм** һәм **Манихейлык** хөкем сөрә башлый. Шул ук вакыт телләре вә мифлары белән борынгы төркиләргә якын торган шумерларның алла-алиһәләренең исемнәре дә тулысынча юкка чыга икән дип уйлау тарихи дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. Язма чыганакларда чагылмасалар да, алар, күрәсең, еллар-гасырлар буе халык күңелендә һәм телендә саклаңалар. Шумер цивилизациясе сүнеп, ике мең ел чамасы вакыт узгач, әлеге традицияләр яңадан язма чыганакларга үтеп керәләр һәм, ярыйсы ук киң таралып, халык, ил вә дәүләт тормышында җитди роль уйналарын дәвам итәләр. Бу очракта сүз борынгы төрки дәүләтләр һәм аларның җитәкчеләре, хөкемдарлары һәм халык абруен казанган яугирләре хакында бара.

Борынгы Шумер ташъязма чыганакларда Тәңре-Диңгир исеме никадәр киң һәм төрле мәгънәләргә ия булган булса, VI–XI йөзләргә караган төрки язмаларда да шулай ук төрле мәгънәләргә ия булып ярыйсы ук киң кулланыла. Әнә шул күзлектән борынгы төрки чыганаклардан **Тәңре** исеме дә кулланылган мисалларны алып, мәсьәләнең асылын ачыкларга тырышып карыйк.

Көнчыгыш Төрки каганлыгында 716–734 елларда хөкемдарлык иткән Билге-каганның кече улы, яу башчысы, берүзе 969 дошманны юк иткән Күлтәгингә (?–731-дә вафат) багышланган Кече язма, Борынгы Шәрекътән килгән традиция буенча, төркиләр өчен Җиһандагы иң бөек һәм иң изге зат исеме — Тәңредән башлана. Ташъязманың беренче сүзе булган **Тәңрене** урысчага нигәдер **Небо** дип тәрҗемә итәләр. Нәтиҗәдә түбәндәгечә тәрҗемә килеп чыга: “Небоподобный, неборожденный тюркский мудрый каган...” Хәлбүки, биредә, дөресен әйткәндә, Күк (небо) турында бер сүз дә юк. Сүз Борынгы Шумердан башланган Диңгир-Тәңре хакында гына бара. Урысча бихисап энциклопедияләрдә, сүзлекләрдә, фәнни хезмәтләрдә күп тапкырлар кулланылган һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан тулысынча танылган һәм берсүзсез кабул ителгән **Тенгри** сүзе, төрки язмаларда шул ук формада һәм шул ук мәгънәдә **Тәңре** дип кулланыла. **Тәңре — ялгызлык исем. Димәк, аны башка бернинди телгә дә тәрҗемә итеп булмый.** Һәм моның кирәге дә юк... Югарыда борынгы төркичәдән урысчага ялгыш тәрҗемә ителгән сүзләрне хәзерге татар теленә тәрҗемә итсәк, ул түбәндәгечә, һәм, безнеңчә, дөресрәк булыр иде: “Тәңрегә охшаган, Тәңре тарафыннан дөньяга китерелгән (яратылган, бар ителгән) акыллы каган, мин хәзер тәхеткә утырдым...”. Тәңре кебек кодрәтле зат тарафыннан тәхеткә утыртылган каганның сүзе, боерыклары берсүзсез үтәлергә тиеш!.. Алга табан язмада төрки каганның иле, җире, халкы, аның даны, байлыгы, кылган эшләре турында тәфсилләп сөйләнә. Төркиләргә табгачлар (кытайлар) белән дуслашуның шикле, куркыныч булуын кисәтеп үткәч, язма төркиләрнең ялгышлыклары, сәяси хаталары турында сөйли. Халыкны бу ялгыш юлдан коткару өчен яңа каган кирәк булып чыга. Язмада сүз Билге-каган исеменнән алып барыла. Димәк, аның ничек тәхеткә утыруы турында да сүз булырга

тиеш, һәм бу чыннан да шулай. Язманың VII бүлеге шуннан башлана да: “Тәңре ярлыкаганга һәм мин үзем дә теләгәнгә күрә хәзер мин каганлыкка утырдым”. Шуннан соң инде Билге-каган үзенең иң зур, иң җитди эшләре турында сөйли: “Каган булып утыргач та, мин ярлы халыкның барысын да үз тирәмә җыйдым. Ярлы халыктан мин бай халык ясадым. Аз гына халыкны мин күп халык иттем...” Күренүенчә, Күлтәгиннең Кече язмасында әйтелгәнчә, ил башында торган каганның үз халкы өчен эшләгән изгелекләренең барысы да тик бөек Тәңре кодрәте белән генә тормышка ашырыла: ил, кабилә, халык һәм аның юлбашчысы булган каганның һәрбер эше, адымы Тәңре кодрәте белән генә бәйләнгән. Бу яктан борынгы төрки язмалар шул ук Борынгы Шәрекъ ташъязма әдәбияты традицияләренә тулысынча тугърылыклы булып калалар.

Шул ук Күлтәгингә багышланган һәм 428 шигъри юлдан торган **Зур язмада** Тәңре турында күп тапкыр җитдирәк сөйләнә. Борынгы Шәрекътән килгән традицияләр буенча, бу язма да Җиһанның яратылуы кебек глобаль проблемадан башлана: “Тәңре кодрәте белән югарыда зәңгәр күк, түбәндә соры җир барлыкка килгәч, алар арасында кешеләр яратылалар”. Гадәттәгечә, бу текст та борынгы төрки текстны урысчага “Когда вверху голубое небо, [а] внизу бурая земля возникли...” дип тәрҗемә ителә. Бу очракта **Тәңре** исемен куллануның бернинди мәгънәсе калмый. Ул тик “Күк— небо” дип кенә бирелә. “Күк” (небо) һәм “Тәңре” (Тэнгре) сүзләре асылда бер-берсен юкка чыгаралар. Шуның белән бергә Тәңре сүзенең дә беренчел мәгънәсе булган “алла” шулай ук инкарь ителә. Безнеңчә, биредә, борынгы төрки текстта **Тәңре исеменең** мәгънәсе тик Күк сүзенең лексик мәгънәсе белән генә чикләнми. Төрки язмаларның һәммәсендә дә әлеге сүз барыннан да элек һәм һәрвакыт **Иң югары дәрәҗәле Күк Алласы** дигәнне аңлата. Европоцентризм һәм беркадәр ясалма индоевропеистика шаукымына “эләккән” урыс галимнәре борынгы төркиләрнең үз алла-алиһәләре булган дигән фикер белән һич тә килешәсе килми. Нәтиҗәдә әле генә китерелгән мәгънәсез тәрҗемә пәйда була...

Билгеле булганча, күзәтелә торган язмада сүз Көнчыгыш Төрки каганатына нигез салучы Котлык (?–691 дә вафат) (каганлык исеме: **Илтериш-каган**), аның хатыны, Билге-каганның һәм Күлтәгиннең әнисе — Илбилге-хатын турында бара. Табигый, язмада илбиләүче һәм аның гаиләсе хакында язылган икән, биредә дә Тәңре исеме тик күрсәтелгән мәгънәдә генә кулланыла: «Төркиләрнең Күктәге Тәңресе, төркиләрнең Изге Җир-Сулары болай диделәр: “Төрки халык биркайчан да юкка чыкмасын! — диделәр алар. — Ул һәрвакыт халык булып яшәсен!” — диделәр алар. Үзенең югарылыгыннан хуплап, минем әтием Илтериш-каганны, минем әнием Илбилге-хатынны Тәңре бик югары күтәрде».

Биредә инде Тәңре исеме үзенең асыл мәгънәсендә кулланыла: төркиләрнең кабилә яки халык булып оешуы тик шул Тәңре кодрәтеннән генә тора. Ягъни, бу очракта Тәңренең кодрәте җирдә яшәүче кабиләләрнең вә халыкларның **язмышын билгели**.

Тик Тәңре кодрәте күрсәтелгәннәр белән генә чикләнми: каган һәм аның иле, халкы, гаскәренең киләчәге дә тулысынча Тәңре кулында. “Күктәге Тәңре көч-куәт биргәнгә күрә, минем әтием — каганның гаскәрләре бүреләр кебек иде, аның дошманнары сарыклар кебек иде”.

Күзәтелә торган Зур язманың эчтәлегеннән күренгәнчә, тирә-яктагы күп санлы халыкларның барысы да төркиләрнең дошманнары булган булса кирәк: табгачлар (кытайлар), тугыз-угызлар, кыргызлар, курыканнар (якутларның ата-бабалары), утыз-татарлар, киданьнар, татабыйлар. Илтериш-каган аларга каршы кырык җиде тапкыр яу чаба, егерме тапкыр сугыша: “Күктәге Тәңре ярлыкаганга күрә, дәүләтләре булганнарны ул дәүләтсез калдырды, каганлыларны кагансыз калдырды, дошманнарын буйсындырды”.

Әмма алга таба язмада сүз төркиләрнең мәгънәсез эшләре, шуның нәтиҗәсендә илнең хәлсезләнүе, җимерелүе, юкка чыгуы турында бара. Бу очракта инде әлеге Зур язма Тәңрене дә, Изге Җир-Су ананы да гаепләми: төркиләрнең көчсезләнеп, дәүләтләре юкка чыгуда барыннан да элек алар үзләре — төркиләр гаепле. Һәм эш монда гына да түгел әле. Мәгълүм ки, Илтериш-каганның энесе һәм варисы, Билге-каган белән Күлтәгиннең агасы (дядя), борынгы төркиләр тарихында зур роль уйнаган, 691–716 елларда, ягъни чирек гасыр буена каганлыкта хөкемдарлык иткән (мәшһүр Идегәй белән чагыштырырга мөмкин!) Мочжо үзенә **Капаган-каган** дигән икенче каганлык исеме кабул итә. Әлеге күзәтелә торган язмада ачыктан-ачык әйтелгәнчә, шул данлыклы тарихи шәхеснең үлеме дә төркиләрнең үз-үзләрен акылсыз тотуыннан килә.

Алга таба Зур язмада Илтериш-каганның олы улы, 716–734 елларда каганлык иткәндә Билге-каган (Акыллы каган) дигән исем алган Могиләннең эшчәнлеге яктыртыла. Бу очракта да каганның һәрбер җитди адымы, әһәмиятле эше тик Тәңре кодрәте белән генә башкарыла: “Төрки халыкның исеме вә даны юкка чыкмасын! — дип (әйтеп), минем әтием-каганны, минем әнием — хатынны күтәргән Тәңре... мине (Билге-каганны — *Ф.У.*) каганлыкка утыртты”. Икенче төрле итеп әйткәндә, көчсезләнеп, юкка чыгу юлына баскан төрки халыкны Тәңре тагын да үз канаты астына ала һәм тәхеткә яңа ил башы — Билге-каганны утырта. Әле генә Тәңре кодрәте белән тәхеткә күтәрелгән Билге-каганның эшләре дә шул ук Тәңре кодрәте белән башкарыла: “Шуннан соң шул ук Тәңре кодрәте белән һәм минем бәхетем вә уңышлы юлым булганга күрә, юкка чыгарга торган халыкны мин яңадан тормышка күтәрдем...” Алга табан каганның бу ялангач халыкны киендерүе, үрчетүе, үстерүе һ.б. турында сөйләнә. Шул рәвешчә, каганлыкта булган һәрбер җитди эш тик Тәңре кодрәте белән генә эшләнә. Әйтик, тугыз-угыз халкы турында анда мондый сүзләр әйтелә: “Тугыз-угыз халкы минем үз халкым иде. Тик Тәңре Җир белән Күкне бутагач (тәртипсезлек урнашкач), ул халык минем дошманыма әверелде”. Нәтиҗәдә төркиләр белән угызлар арасында каты бәрелешләр, сугышлар булып, угызлар җиңеләләр.

Соңгы тапкыр Тәңре исеме Зур язмада гаять киң гомумиләштерүгә нигезләнгән һәм Тәңренең көч-куәтен, кодрәтен кирәк дәрәҗәдә төгәл билгеләгән җөмләдә кулланыла: “Вакытны (язмышны) Тәңре билгели: адәм балалары бу дөньяга (киләчәктә) үлү өчен туалар”.

Китерелгән мисаллардан күренүенчә, Тәңре биредә барыннан да элек бердәнбер һәм иң югары дәрәҗәдәге Күк алласы буларак гәүдәләнә. Кешенең (каганның) бу дөньяга килүе, аның кылган яисә кыласы эшләре, батырлыклары, аның үлеме — һәммәсе дә тик Тәңре кодрәтемнән генә килә. Шул ук вакыт барлык халыкларның ил вә халык буларак оешуы яисә

таркалуы, юкка чыгуы, гомумән **бөтен язмышы** шул ук Тәңре кодрәте белән бәйләнгән.

Өч төрки каганның: Илтериш-каганның (691-дә вафат), Капаган-каганның (691–716 елларда хөкемдарлык итә), Билге-каганның (716–734 елларда хөкемдарлык итә) киңәшчесе (вәзире?), каганат хөкемдарының беренче ышанычлы кешесе; яу башчысы буларак, төркиләрнең аерым яулары-сугышлары белән җитәкчелек иткән Таньюкукка багышланган язмада да Тәңре нигездә шул ук функцияләрне башкара, һәм аның исеме дә охшаш вакыйгалар, хәлләр уңаеннан кулланыла. Язманың баш өлешендә сүз төркиләрнең табгачларга (кытайларга) буйсынуы, гомумән илнең ярыйсы ук катлаулы чоры турында бара: «Мин үзем, акыллы Таньюкук, табгач дәүләте рухында тәрбияләнгән идем. Төрки халык табгачларга буйсынды. Үзенең хакы булмаган төрки халык табгачлардан аерылып чыкты һәм үзенең ханын булдырды. Үзенең ханын калдырып, ул тагын да табгачларга буйсынды. (Шул вакытта) Тәңре әйтте: “Мин сезгә хан биргән идем! Үз халкыңны калдырып (ташлап китеп), син тагын да буйсындың!” Әнә шул буйсынуың өчен Тәңре сине харап итте дә. Төрки халык харап булды, юкка чыкты».

Әнә шулай пыран-заран ителгән төркиләрнең исән калганнары берегеп, бер дәүләт төзиләр. Һәм, борынгы эпоста һәм ташъязма әдәбиятта гадәти булганча, Таньюкук, аның үз сүзләренчә, Тәңрене аны каган итеп сайлап куерга мәҗбүр итә: “Мин уйландым. Шуннан соң, Тәңре миңа акыл биргәнгә күрә, мин үзем аны мине каган итеп куярга мәҗбүр иттем”. Күренүенчә, бу очракта Таньюкукның мактануы шул дәрәҗәгә барып җитә ки, хәтта ул үзе Тәңрене аны — Таньюкукны каган итеп куерга мәҗбүр итә.

Бик күптәннән килгән, төрле халыклар дастаннары һәм Борынгы Шәрекънең ташъязма әдәбияты традицияләре таләп иткәнчә, Таньюкукның алдагы сүзләре дә нигездә **мактану рухында яңгырый**, хәтта сүз төрле тарихи вакыйгаларга Тәңренең катнашы турында барса да! Мәсәлән, Таньюкукның угызлар белән сугышын тасвирлаганда: “Аларның (угызларның) гаскәре өч мең иде. Безнеке — ике мең. Без сугыштык. Тәңре безгә яхшылык күрсәтте — без аларны таркаттык”. ... Җөмләдән, төрле халыклар эпосында шундый бер күренеш киң таралган: гадәттә эпик батыр хәлиткеч орыш алдыннан үз-үзен күкләргә чөеп мактый; дошманын исә — чиксез хурлый, тирги, мыскыллый. Шуның белән ул үзен дә, дошманын да алдагы орышка әзерли; ул әйткән сүзләр арбау, ырым функциясен башкара: эпик батырның көч-куәтен арттырып, дошманын хәлсезләндерә, дип ышанганнар борынгылар. Мондый күренешләр халык эпосына Борынгы Шәрекъ һәм урта гасырлар төрки-татар ташъязма әдәбиятыннан килеп кергән булса кирәк... Ә бәлки киресенчә, әлеге традицияләр язма әдәбиятка борынгы миф һәм мифологик хикәятләрдән үтеп кергәндер...

Ниндидер гөнаһ кылган өчен Тәңре гаеплеләрне җәзага тартырга да мөмкин. Бу хакта Таньюкук язмасында бу ачыктан-ачык әйтелә: «Мин болай дим, мин акыллы Таньюкук: “Без Алтын тайгасын үтеп килдек! Без Иртеш елгасын үтеп килдек! Килүчеләр — батырлар, — дидем мин. Алар (дошманнар) абайламыйлар да (бу хакта). Тәңре, Умай, Изге Җир-Су җәзага тартачак (сүзгә сүз: изеп ташлаячак) бит (безне)!”»

Тәңре тарафыннан җәзага тартылу борынгы төркиләр өчен бик тә куркыныч хәл булган булса кирәк. Һәрхәлдә, әлеге язманың алдагы өлеше

нәкъ әнә шул турыда сөйли: «”Нишләп (безгә) качарга, күп (алар) дип? Нишләп (безгә) куркырга, аз (без) дип? Нишләп безгә җиңелүчеләр булырга? Һөҗүм итик (аларга)!” — дидем мин. Без аларга ташландык (һәм) таркаттык (дошманнарны). Икенче көнне алар килделәр, ялкынланып, ут кебек килделәр алар. Без сугыштык. Безнеке белән чагыштырганда алар (гаскәренең) ике канаты бер ярымга артыграк иде. Шулай итеп, Тәңре мәрхәмәтлелек күрсәтте, алар күп булуга карамастан, без курыкмадык (һәм) сугыштык. Тардуш ханзадәсе сугышка катнаша башлады. Без (дошманнарны) таркаттык, аларның каганнарын кулга алдык, аларның яу башын (һәм) аларның ханзадәсен (шад) шунда үтерделәр».

Кыскача күзәтелгән язмалар күрсәтүенчә, борынгы төркиләрнең күк алласы түбәндәге функцияләргә ия:

1. Төрле кабилә-халыкларның, мәсьәләгә киңрәк яссылыктан килсәк — һәркемнең дөньяга килүе. Гомумән алганда, борынгы төркиләр Тәңресен аерым шәхес язмышы кызыксындырмый; чөнки ул — аерым шәхес анда тулы бер кабилә яисә халык вәкиле буларак кына хәрәкәт итә: борынгы ыруглык җәмгыяте белән бәйле мәҗүси традицияләр биредә дә җитәрлек дәрәҗәдә яхшы саклана.

2. Төрле кабиләләрнең халык булып оешуы шулай ук Тәңре кодрәтеннән генә була ала.

3. Каганның тәхеткә күтәрелүе. Икенче төрле итеп әйткәндә, һәрбер кешенең бу дөньядагы җитди адымнарының, эшләренең барысы да тик Тәңре ихтыяры белән генә башкарыла.

4. Берәр каган кул астында гомер иткән кабилә-халыкның, киңрәк һәм конкретрак мәгънәдә алганда — бу фани дөньядагы һәркемнең көндәлек язмышы.

5. Каган гаскәренең көч-куәте, җиңү яисә җиңелүе. Юкка чыга башлаган ил вә халыкны яңадан күтәреп, ил башына яңа каган утырту.

6. Төрле гаепләре өчен аерым кешеләрне, каганны, ил вә халыкларны җәзага тарту.

Китерелгән мәгълүмутларның барысын да бер ноктага җыеп, йомгаклап әйткәндә: һәрбер кешенең бу дөньяга килүе, аның бәхете яисә бәхетсезлеге, ахыр чиктә — бу дөньядан китүе — барысы да Тәңре ихтыяры белән генә хәл ителә.

* * *

III гасырда Иранда **манихейлык** дип аталган яңа бер дин барлыкка килеп, чак кына соңрак ул Италиядән башлап Кытайга кадәр киң таралыш таба. Аңа нигез салучы Мани (216–277 еллар) — ярым-легендар шәхес. Зороастризмның һәм Христианлыкның кайбер уңай, халык арасында абруй казанган үзенчәлекләрен үз эченә алган манихейлык, күрәсең, VIII–X йөзләрдә борынгы төркиләр арасында да тарала башлый. Аларның борынгыдан килгән Тәңре, Умай, Изге Җир-Су алла-алиһәләре белән бәйләнгән дигән карашларына да билгеле бер йогынты ясый. Нәтиҗәдә төрки язмалар арасында манихейлык карашларының да аерым үзенчәлекләрен чагылдырган китаплар барлыкка килә. Әнә шундый чыганаклар рәтенә якынча IX йөз башына караган “Юраулар китабы” (Ырк битиг) тә керә. Борынгы төрки әдәбиятның танылган белгече И.В. Стеблева язганча, әлеге

чыганакта төрки Тәңренең үзе дә "җитди үзгәрешләр кичереп", аның функцияләре дә нык кына катлаулана һәм аерым тармакларга, юнәлешләргә бүленә башлый. Биредә инде Тәңре бер һәм бердәнбер Күк алласы түгел. Ул чорлар төрки мифологиясенә караганда, Тәңреләр анда берничә һәм аларның һәркайсы тормышның билгеле бер өлкәненә генә карый. Ягъни Тәңренең кайчандыр Борынгы Шумерда билгеле булган сыйфатлары яңадан калкып чыгадыр шикелле: тормышның һәр өлкәсенең үз Тәңресе бар. Мисал өчен әлеге китаптан түбәндәге юлларны алыйк: "Мин — ала атлы язмышлар (сүзмә-сүз: юллар) Тәңресемен. Иртән һәм кичен мин чабам (юлда булам)". Тиз йөрүчән ат төрки шигърияттә, гадәттә, вакытның тиз узучан булуын белдерә. Гыйбарәдәге "ала" сүзен исә "яла, ала-кола, алмачуар" дип тәрҗемә итәргә мөмкин. Күрсәтелгән Тәңрегә түбәндәге атрибутлар хас: а) ул — ала атның хуҗасы; б) һәрвакыт юлда, хәрәкәттә; в) кеше белән турыдан-туры билгеле бер мөнәсәбәтләргә керә ала; г) иң җитдие — ала атлы Тәңре адәм балаларына һәрвакыт яхшы мөнәсәбәттә тора. Ә инде бу атның төсенә килсәк, аның ала, алмачуар, аклы-каралы булуы көн белән төн, тәүлекнең якты вә караңгы вакытларын билгеләү белән бәйләнгән булырга мөмкин.

"Юраулар китабы"ндагы Тәңре белән бәйле тагы бер гыйбарә аеруча игътибарга лаек: «Мин — язмышның кара юлымын. Синең берәр нәрсәң сынган булса, мин аларны кушам (савыкландырам), синең берәр нәрсәң ертылган (аерылган) булса, мин аны бәйлим (бер-берсенә кушам, төзәтәм). Мин халыкны (илне) барлыкка китерүчемен. Рәхәттә яшәсен ул!" — диләр. Димәк, белегез: [бу яхшы]».

Кара язмыш (юл) Тәңресенә түбәндәге атрибутлар хас: а) кара төс, ягъни, бу Тәңре — кара язмыш иясе; б) кара язмыш адәм баласын төрле бәхетсезлекләргә (әйтик, сугышта яралануга), авыру-сырхауларга да китерергә мөмкин. Хәтерләвебез буенча, төрки Тәңресенең төп вазыйфаларыннан берсе — адәм баласына һәрвакытта да мәрхәмәтле булу. Бу сыйфат кара язмыш тәңресенә дә хас булырга тиеш. Шулай булгач, ул, гадәттә, кешене төрле бәхетсезлекләрдән, яралардан коткарып калучы табип ролен дә үти; г) Тәңренең юктан булдыру вазыйфасы. Гадәттә, Тәңренең бу сыйфатын алтайлыларның Эрлик алласы белән чагыштыралар. Ә бәлки биредә Ислам мифологиясе йогынтысы да бардыр? Һәрхәлдә, Исламдагы Аллаһы Тәгаләнең дә төп вазыйфасы — юктан бар итү.

Күрсәтелгән чыганактан ачыкланганча, Тәңре, борыңгы төрки Урхун-Енисей язмаларындагы кебек үк, — иң югары дәрәҗәдәге Күк алласы. Китапның түбәндәге юллары нәкъ әнә шул хакта сөйли: "Кам үз үтенече белән бәккә мөрәҗәгать итә, козгын үз үтенече белән Тәңрегә мөрәҗәгать итә. Югарыда Тәңре ишетте, түбәндә кеше белде". Димәк, кешеләрнең дә, бу дөньядагы башка затларның да язмышы тулысынча Тәңре ихтыярында.

"Юраулар китабы"нда чагылыш тапкан мифологик карашларның тагын бер үзенчәлеге — аларда борынгы дуалистик күзаллауларның да йогынтысы сизелә: һәрбер нәрсә, зат, язмыш һ.б. анда, гадәттә, икенче бер күренешкә каршы куела. Ала атлы юл Тәңресе һәм кара язмыш Тәңресе; Күк һәм Җир; яхшылык-явызлык; мәхәббәт-нәфрәт һ.б. Ә мондый карашлар, билгеле булганча, барыннан да элек Манихейлык концепциясе белән бәйләнгән.

Китерелгән мисаллардан күренүенчә, борынгы төркиләрдә Тәңре белән бәйле ышанулар чыннан да киң таралган була. Урхун-Енисей язмаларыннан

һәм “төрле диннәр арасында торган” “Юраулар китабы”ннан соң ул Мәхмүд Кашгариның якынча 1078–1082 елларда төзелгән сүзлегендә берничә тапкыр телгә алына: “Тәңре каргышы аның үзә” — “Тәңре каргышы төшсен”; “Сүсәгән удка Тәңри мүңүз бермәс” — “Сөзгәк сыерга Тәңре мөгез бирми”.

Тәңрегә гомуми характеристика бирү бурычы куелса, барыннан да элек: кем, нинди зат соң ул Тәңре? — дигән сорау калкып чыга. Барыннан да элек шуны ассызыклап әйтик: Тәңре — беренче нәүбәттә Күк алласы. Ул илаһи Күктә яши һәм Җиһандагы барлык җан ияләре, җансыз затлар, тарихи һәм тормыш-көнкүреш вакыйгалары, хәлләре, төрле күренешләр белән шуннан тарып идарә итә. Аның илаһи бер абруе вә изгелеге дә әнә шул Күктә яшәве белән бәйләнгән.

* * *

Әмма гасырлар үтү белән, бигрәк тә төрле илләрдә бераллалык карашлары тарала башлагач, Тәңрегә дә шундый ук караш барлыкка килә булса кирәк. Һәрхәлдә, Идел буена Ислам үтеп кергәннән соң, күрәсең, мөселман Аллаһы Тәгаләсе белән борынгырак чорлардан калган Тәңре исемнәре бер үк булмаса да, бик якын мәгънәдә кулланыла башлыйлар. Кайвакыт хәтта Аллаһы Тәгалә һәм Тәңре исемнәре синонимнар булып йөриләр... VII–VIII йөзләрдә, бигрәк тә тагы бер-ике гасыр узгач, югары күк, язмыш алласы дип уйланылган Тәңре дә төрле илләрдә, бигрәк тә нигездә төрки-монгол халыклары яшәгән Үзәк, Урта һәм Кече Азиядә, хәзерге Казакъстанда, Көньяк Себер далаларында, Идел-Җаек урталыгында, Урта Идел һәм Урал буе тирәләрендә киң тарала. Бәлки бу якларда Ислам тәгълиматының чагыштырмача җиңел һәм тиз таралып, нык тамыр җәюе биредә борынгыдан килгән Тәңрегә табыну белән бәйләнгәндер. Ислам — монотеизмның, бераллалыкның классик һәм халыкара үрнәге булса, Тәңрегә ышануда әнә шул бераллалыкка омтылу тенденциясе ярыйсы ук ачык сизелә...

Билгеле булганча, Ислам дине VII гасыр башында Гарәбстанда барлыкка килеп, тиз арада бик күп илләргә таралып өлгерә. Әгәр хәзерге Урта Азия, Казакъстан, Кавказ якларында яшәүче халыкларга Ислам нигездә хәрби көч, яулап алу юлы белән иңдерелгән булса, Урта Иделдәге Борынгы Болгарга ул тик X гасырның беренче яртысында, гарәп хәлифәсе Әл-Моктадир илчелегенең сәяхәте нәтиҗәсендә үтеп керә. Дөрес, күп кенә чыганаклар күрсәтүенчә, әлеге сәяхәтчелек килгәнче дә, биредә Ислам дине инде берникадәр таралган була. Бу хакта күрсәтелгән илчелекнең сәркәтибе булган ибне-Фазлан китабыннан да укырга мөмкин. Шул ук вакытта Урта Идел тирәләрендә Ислам диненең таралуы ике идеологиянең, Исламның һәм Тәңречелекнең бер-берсенә каршы торуы шартларында барырга тиеш була. Чөнки Ислам кануннары берникадәр мәҗүсилек рухы белән дә сугарылган Тәңрегә табынуны кысрыклап чыгарырга омтыла. Дөрес, биредә нindидер мөһим конфликт, җитди көрәш булгандыр дип берничек тә әйтеп булмый. Хикмәт тә шунда ки: биредә Урта Идел тирәләрендә, шул ук Тәңрегә буйсынуга берникадәр якын торган мәҗүсилек, шулай ук Тәңрегә гыйбадәт кылуның Исламның төп кануннарына туры килүе бу диннәрнең баштан ук, әйтик, IX–X йөзләрдә үк үзара укмашып, бер-берсенә терәк булып яшәвеннән килә.

Алла, Аллаһ, Аллаһы Тәгалә — гарәп телендә Илаһи зат, Тәңре, Ходай дигәнне аңлата. Хода, Ходай исә фарсы телендә югары көч, хуҗа мәгънәсендә йөри. Ислам белгечләре язуынча, «Тәңре — төрки телләрдә **Аллаһ** сүзе белән бер үк мәгънәдә кулланыла. **Тәңре** сүзе әдәбиятта гомумән табигатьтән өстен көч мәгънәсендә дә очрый». Төрки Тәңренең дә, ислами Аллаһы Тәгаләнең дә төп функциясе — бөтен дөнья белән идарә итү. Димәк, бу ике илаһи исемнең еш кына бер үк, һич югы — бик якын мәгънәдә кулланылуы табигый хәл. Исламга багышланган махсус сүзлекләрдә бу исемгә түбәндәгечә аңлатма бирелә: Алла, Аллаһ — Ислам дине буенча күкне, җирне, кешене — бөтен нәрсәне бар итүче, бөтен дөнья белән идарә итүче. Ислам дине кануннарыннан Алланың барлыгына һәм берлегенә ышану — төп таләпләрдән. Дөрес, Гарәбстанның төньягында яшәгән гарәпләрдә мәҗүсилек чорында ук төрле аллаларга ышану булган. Ул чорларда Әл-илаһ исеме белән мәгълүм булган алла бердәнбер илаһи зат булмыйча, иң югары дәрәҗәле алла дип уйланылган. Икенче төрле итеп әйткәндә, гарәпләрнең Исламга кадәрге иң югары дәрәҗәле алласында кайчандыр, әйтик — Борынгы Шумерда, аннан шактый соң да Тәңрегә, Тәңреләргә хас сыйфатлар да булган.

Ислам динендәге Алланың төп үзенчәлекләре, сыйфатлары һәм вазыйфалары түбәндәгеләр: Алла, Аллаһы Тәгалә — ул бердәнбер, тере, мәңгелек, ачык күренүче һәм яшерен һәр нәрсәне белүче; ул — һичшиксез, “абсолют хакыйкать”; көчле, кодрәтле, “теләгән кешесен (төрле гөнаһлары өчен? — *Ф.У.*) юлдан яздыра, теләгән кешесен туры юлдан алып бара (13, 27); шул ук вакытта ул рәхимле, шәфкатьле, ярлыкаучы (7, 154), юмарт бүләкләүче, туендыручы, якын итүче (11, 92; 85, 14). Коръәннән күренгәнчә, Аллаһы Тәгаләдә, бигрәк тә аның тышкы күренешен истә тотканда, кешеләргә хас сыйфатлар да бар; ул тәхеттә утыра (20, 4); аның куллары (5, 69), күзләре (54, 14), йөзе-бите бар (2, 109)... Нигездә исә Алла, күрәсең, саф рух рәвешендә күз алдына килә.

В татарском музыковедении гусли также причислены к разряду общетатарских национальных инструментов, но татарские гусли тихо умирают на глазах современной общественности. Проблема возрождения татарских гуслей является и парадоксальной. Живые традиции игры на гуслях в сельском быту сохранились до сего времени только у татар (в Арском и Балтасинском районах). У чувашей, мари, мордвы их давно нет. Но, тем не менее, все вышеперечисленные народы, кроме татар, уже возродили этот древний инструмент, обучают игре на нем в музыкальных школах, СУЗах, ВУЗах. Имеется инициатива по обучению на татарских гуслях. Со спецификой игры на татарских гуслях знакомятся студенты кафедры татарской музыки КГУКИ, а также учащиеся ДМШ №7 «Идель» Вахитовского района.

Проделана определенная работа и по написанию пособия по обучению игры на думбре. Это можно судить по выступлениям детского фольклорного ансамбля «Ак калфак», ставшего лауреатом республиканских и международных фестивалей. Однако здесь имеется и своя специфика. Ввиду того, что этот старотрадиционный татарский инструмент имеет свои особенности приемов звукоизвлечения, характерной терминологии, репертуара, то крайне желательным становится подготовка пособий на татарском языке, на том первичном языке, на котором формировался

терминологический аппарат, названия частей и деталей инструмента. А в связи с этим возникают свои трудности. Думбра - характерный инструмент большинства тюркских народов, исполнительское искусство на котором начало формироваться в древности и средневековье. Поэтому при написании пособий по татарской думбре необходимо учитывать научные и учебно-методические материалы по думбре и других родственных народов, где более полно сохранились думбровые традиции. Допускать же внутритюркский разнобой и разночтения в думбровом искусстве нежелательно. При подготовке своего пособия я пользовался материалами по русским балалайкам, так как материалы по думбре ногайцев, казахов, башкир нам недоступны. В результате работа застопорилась. Поехать в Казахстан для ознакомления с аналогичными пособиями по думбре, для сбора звучащих материалов и обмена опытом по методике обучения, можно лишь в случае покрытия командировочных расходов заинтересованными учреждениями.

**IV**. Вопрос о внедрении возрождаемых инструментов в образовательное пространство ДМШ, СУЗов, ВУЗов, ИДПО можно будет ставить на повестку дня лишь в случаях наличия инструментов, учебных пособий и обученных, прошедших специальные курсы обучения педагогов. Очевидно, что наиболее приемлемым путем подготовки педагогов по возрождаемым традиционным инструментам должна стать образовательная площадка Института дополнительного профессионального образования (повышения квалификации) специалистов СКС и искусства.

В случае положительного решения об организации в ИДПО специализированных курсов по подготовке (переподготовке) руководителей фольклорных инструментальных ансамблей и исполнителей на татарских традиционных инструментах, можно было бы запланировать проведение следующих курсов: «Руководитель ансамбля татарских гуслей», «Руководитель ансамбля татарских думбр», «Руководитель ансамбля кураистов», «Руководитель ансамбля старотатарских инструментов».

Очевидно, что основой предварительной работы по организации подобных курсов должны стать: подготовка учебных программ, подготовка традиционных музыкальных инструментов для каждого курсанта во время учебы, предварительная подготовка опубликованных пособий с нотами и методикой игры. Однако эти курсы, занятия по практическому освоению инструментов должны предваряться достаточно сложной и трудоемкой работой по подготовке учебно-тематического плана с включением в него лекций по истории и теории музыкального исполнительства на этих возрождаемых инструментах, разработкой репертуарного содержания в виде нот, пособий по методике игры.

Желательно проведение специализированных курсов по обучению изготовлению традиционных инструментов, что способствовало бы организации музыкальных мастерских в различных районах проживания татарского населения, в центрах декоративно-прикладного искусства самими исполнителями или мастерами-любителями.

Слушателями курсов могли бы стать руководители фольклорных вокально-инструментальных ансамблей художественной самодеятельности, педагоги ДМШ, СУЗов и ВУЗов культуры и искусства. Очевидно, что, создав реальную основу для организации подобных курсов, можно будет более

качественно и целенаправленно готовить специалистов по фольклору, знатоков традиционной культуры, которые могли бы в дальнейшем содержательно и плодотворно работать.

V. Проведение учебно-практических семинаров, фестивалей и конкурсов исполнителей на этнических музыкальных инструментах татар в Татарстане, а также достойное участие татарстанских этноинструментальных коллективов на татарстанских, региональных, всероссийских и международных конкурсах, фестивалях, концертах исполнителей на традиционных инструментах должно стать реальным показателем работы по возрождению татарских этноинструментальных традиций.

Возрождение традиционных инструментов татар является задачей государственного значения, решение которой необходимо начать с составления тщательно спланированного проекта, который должен быть разработан комитетом (рабочей группой) по возрождению татарских традиционных музыкальных инструментов из ученых и педагогов-исследователей, изготовителей, исполнителей, представителей заинтересованных учреждений при Министерстве культуры Республики Татарстан.

*Ф.С. Баязитова,*
Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең
әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

## ***Чәч ти очларыңда көмеш тәңкә***

Ап-ак ефәк күлмәктән, ак челтәрле бөркәнчек ябынып килен төшә. Аны ак мендәрләргә бастырып, ак бәхетләр теләп каршы алалар. Ә элекке вакытларда яшь киленнәр ничек киенгән соң? Бераз тарихка күз салыйк әле. *Никах күлмәге, кәбен күлмәге* дип кызга күлмәкне туйга кадәр үк егет ягыннан китергәннәр. *Кием белән килү, кием илтү* дигән туй йолаларын әле дә өлкән кешеләр хәтерлиләр. Кызга шулай ук камзул, аяк киемнәре, шәл һ.б. киемнәрне дә егет ягы әзерләгән. Кыз да егеткә үзе тегеп яки чигеп күлмәк, түбәтәй һ.б. әзерләгән. Никах, кәбен мунчасыннан соң кыз егет ягыннан китерелгән киемнәрне, егет исә кыз ягыннан килгән киемнәрне кигәннәр. Бу ике якның туганлашу, якынаю билгесе булган. Туй күлмәге ак яки чәчәкле тукымадан, бала итәкләр салып, озын җиңле итеп тегелгән.

Туйларда бигрәк тә яшь киленнәрнең баш киемнәренә зур игътибар иткәннәр. Кыз кеше килен булып кияү йортына төшкәч, аның инде кыз чакта киеп йөргән баш киемнәрен салдырып, хатыннар кия торган баш киемнәре белән алмаштырганнар. Ул йоланы мишәрләрдә һәм керәшеннәрдә әле дә хәтерлиләр. Мишәрләрдә ул *тастар сару*, керәшеннәрдә — *баш бәйләү* дип атала. *Тастар* — мишәр хатын-кызлары бәйли торган озынча яулык яки сөлгесыман ак тукыма, аның баш-башлары чигүле була. *Тастарны* кыз кеше әле кияүгә бармас борын ук үзе чигеп әзерләп куя һәм, егет йорты белән ике арада башкодалар йөреп, үзара килешенгәч, вәгъдә бүләге итеп,

ышанмаклыкка егет ягына биреп җибәрә. *“Тастар алырга килү, тастар алу”* дигән йолалар һәм йола сүзләре дә шуннан калган. *“Тастар алу — кызны бөтенләйгә килешү була инде ул. Сүз өзелмәскә, ышанычлы булсын дип тастар бирәләр”.* Кияү йортына килен булып төшкәннән соң, ул тастарны яшь киленнең башына чорнап куялар. Аның инде килен кеше икәнлеге, тормышның яңа баскычына атлаган хатын-кыз икәнлеге күренеп тора.

Ак юкәгач суйдыгыз,
Кабыгын кая куйдыгыз?
Ап-ак тастар сардыгыз,
Яулыгым кая куйдыгыз? — дип җырлаганнар яшь киленнәр.

Керәшеннәрдә кияүгә китә торган кызга *“баш бәйләтү”* йоласын кыяматлык әни итеп билгеләп куелган хатын-кыз башкара. Ул кызлар кия торган баш киемнәре - *калфак-чачак, маңгай ука, кашбауларны* салдырып, чәчләрен икегә аерып үрә һәм хатын-кызлар кия торган баш киемнәре - *мәләнчек, сүрәкә, чигәчә* киертә, өстән *түгәрәк яулык* дип аталган, уртасы эре бизәкләр белән күпертеп чигелгән, дүрт кырые чачаклы калын яулык ябындыра. *Мәләнчек* белән башны кысып бәйләп куялар, чәчләр күренеп торырга тиеш түгел. Ука җепләр белән чигелеп эшләнгән *сүрәкәләр* дә бик затлы:

Сүрәкәләр чиктем киргесез,
Киереп чиккәннәргә биргесез.
Сайлап ярны мин сөймәдем,
Сайлап сөйгәннәргә биргесез.
Сүрәкәләр чиктем исәпләп,
Дүртти почмакайын пичәтләп,
Әйтәсе сүземне әйтми калдым,
Алдагы көнемне исәпләп, — дип җырлый-җырлый чиккәннәр сүрәкәләрне. *Сүрәкә* һәм *түгәрәк яулык* чигүчеләр авылларда бик кадерле, билгеле кешеләр генә булган, аларның осталыгы буыннан-буынга тапшырылып килгән.

*Баш бәйләнгән, тастар сарынган* яшь киленнәргә йөзен бер кем дә күрмәсен өчен иң өстән *бөркәнчек бөркәндерәләр*,. Бөркәнчекне, кыз алырга килгәндә, егет ягыннан китергәннәр:

Имәннәр сайгак имерек,
Юкәләр сайгак җимерек.
Атлар җигеп, *бөркәнчек* салып,
Кыз алырга килдек, җилдереп.

Туй кунаклары алдында яшь киленнең *бөркәнчеген ачып*, йөзен халыкка күрсәтү йоласы башкарыла. Керәшеннәрдә, туй кунаклары табынга утырганнан соң, кызның әти-әниләре шундый җыр әйтәләр:

Биеккәй тауларның башында
Яшь үләннәр ята яшәреп.
Безнең бәбекәйләр сезләрнең кулда,
Кайда тотасыз аны, яшереп.

Яшь киленнәр киеменә киенгәч, баш бәйләнгән кызны бөркәнчек бөркәнгән көенчә кунаклар алдына чыгаралар. Ике яктан ике малай килеп уклау белән кызның бөркәнчеген ачалар. Бу вакытта кияү егете йөгән чылтыратып торырга тиеш. Кыз бөркәнчек ачучыларга *янчык* бүләк итә.

Мишәрләрдә яшь киленнең *йөзен ачу, күрендерү* йоласы шулай ук туй кунаклары алдында башкарыла:

Тыпыр-тыпыр биергә
Идәнеңнең уе бар.
Чыгарыгыз яшь киленне,
Ничә каре[1] буе бар.

Әстерхан һәм себер татарларында туйдан соң берничә көн үткәч *битачар, бит күрем* дигән йола башкарыла. Башына *тастар, саравыч сарган, бөркәнчек бөркәнгән* яшь килен шушы йола башкарылганга кадәр чит кешеләр күзенә күренергә тиеш түгел. Суга барса да иртәрәк бара. *"Биткүрем"*гә кардәшләр, дус-ишләр, күршеләр чакырыла, төрле бәлешләр, пылаулар пешә. Яшь киленне бөркәнчектә килеш чыгаралар, аны бер җиңги килеп, әкрен генә ача. Яшь килен тезен бөгеп кунакларны сәламли. Битен ачкан җиңги яшь киленгә акыл биреп, түбәндәге сүзләрне әйтеп утыра:

Яхшы бул, кайнанаңны тыңла,
Аңар сәлам әйтеп тор.
Айагың бөгеп сәлам әйт,
Кайнатаңа каршы сөйләмә.
Кайнанаңның телең ал (ягъни аның белән бер сүздә бул),
Кайнанаңның кулын ал (ягъни аның кебек эшләргә өйрән).
Каты сөйләмә, телен каерма,
Суын биреп, ашын биреп тор. (Әстерхан)

Себер татарларының *бөркәнчек ачу* йоласын шулай ук олы яшьтәге хатын-кыз башкара. Йола буенча ул шырпы сызып, ут яндырып (җен-пәриләрне куркытып) ала, түбәндәге сүзләрне әйтә:

Көнеңне күр,
Утыңны як,
Безнең яшебезгә чык,
Балалы-чагалы бул,
Озын гомерләр, киң дәүләтләр бирсен,
Тиң яшәп, тиң картаегыз.
Куш аягыгыз белән (ягъни парлы булып) гомер итегез.

Яшь киленнең бөркәнчеген ачу йоласы башкарылса да, ул олы кешеләр, каенаталары алдында *шәльяулык* яки *кушъяулык* (Минзәлә якларында) бөркәнеп, *озын күлмәк, камзул* яки *аркалык* киеп йөргән. Хәтта, урак урганда да, шул киемнәрне салмаганнар. Киров өлкәсе Нократ авылында Бибиямал апа сөйләгән бер истәлек гыйбрәтле. Бер килен, урак урганда эссегә түзмәгәч, камзулын салып куйган икән, аны каенанасына чакканнар. "Ник салдың? Кешедән оят", — дигәннәр кайнаналары.

Г. Ибраһимовның "Татар хатыны ниләр күрми" дигән әсәрендә яшь киленнең бөркәнчек ябынып килен хезмәте итүе турында мондый юллар бар: *... Яшь килен кушъяулыкны ипләбрәк ябынды да, каушабрак ак өйгә керде, каенатага бер сүз дә әйтмичә, йөзен йартылаш каплабрак, сәкегә, киез өстенә ашаулык җыеп, чәй әзерләде, шаулап кайнаган самавырны кертеп куйды.*

---

[1] К а р е — борынгы үлчәү берәмлеге, терсәктән алып бармакларга кадәр булган озынлык.

Гомумән яшь киленнәр матур итеп киенеп, төрле бизәнү әйберләре тагып йөрергә тырышканнар. Мәсәлән, чәч толымнарына көмеш тәңкәләр яки чулпылар такканнар.

Чәчти очларында көмеш тәңкә,
Тагып кына чыксаң салмаклы.
Кыз ди чакларыңда шунысы рәхәт,
Башкайларың була ардаклы.

*“Чылтырап торган чулпылар атлаган саен бас, бас, атла, атла дип торырлар ые, дәртләндереп торыр ые”*, — дип сөйлиләр әбиләр. Әмма яшь киленнәр, өлкән кешеләр яныннан узганда, яки каенана-каената янына кергәндә, чәч чулпыларын, “чылтырамасын” дип, кулларына учлап тотып кергәннәр.

**Әдәбият**

1. Баязитова Ф.С. Әстерхан татарлары рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор / Ф.С. Баязитова. - Казан, 2002.

3. Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты / Ф.С. Баязитова. - Казан, 1997.

4. Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы / Ф.С. Баязитова. - Саранск, 2004.

4. Баязитова Ф.С. Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор / Ф.С. Баязитова. - Казан, 2001.

*Ф.С. Баязитова,*
Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең
әйдәп баручы фәнни хезмәткәре;
*Г.Ф. Мөхәмәтова,*
Г. Ибраһимов ис. ТӘҺСИнең аспиранты

## *Татарстанның Кама аръягы сөйләшләрендә кышкы йолалар лексикасы һәм фольклор үрнәкләре*

Башка бик күп халыклардагы кебек, татар халкында да кышның яңа ел көннәре төрле тылсымлы йолалар, күрәзәлек итү уеннары белән билгеле. Нардуган йолалары шулар арасында иң кызыклылардан санала. Урта Идел буенда яши торган күршеләребез чуашлар, удмуртлар, марилар, мордвалар да аны бәйрәм иткәннәр. Татар халкы яшәгән төрле төбәкләрдә, җирле сөйләшләрдә яңа ел, нардуган йолаларының бик күп борынгы үрнәкләре һәм аларга караган сүзләр сакланып килә. Нардуган йолаларының лексикасына һәм фольклор үрнәкләренә Ф.С. Баязитова хезмәтләрендә шактый зур урын бирелгән (1997, Б. 144–149; 2003, Б. 173–179 һ.б.).

Биредә исә Татарстанның Әлмәт һәм Зәй төбәгендәге керәшен авылларында һәм мишәр диалекты сөйләшенә карый торган Елхово авылында язып алынган йола үрнәкләре, лексика һәм фольклор материаллары тәкъдим ителә.

Керәшеннәр сөйләшеннән язып алынган нардуган йолалары.

**Нардуган көннәре.**

— Йамбарның җидесендә аwыз ачалар да шуннан нардуган башлана унтугызына хәтле.

**Кийенеп чыгу** — маскарад ясап өйдән-өйгә кереп йөрү.

**Ат булып килү.**

— Атлар булып киләләр, тәрәзәгә килеп шап-шап бәрәләр иде, өйгә керерлек түгел инде алар. Бер кеше җайдак атланган, өстән карап тора дип сөйлидер ийе әби шулай. Ике кешене дүрт айаклатып куйалар, өстән бөркәп куйалар торопша, тегене атландырып куйалар. — Нардуганда әллә кемнәр булып кийенеп, өй борончы кереп йөриләр.

**Айу булып килү.**

— Айулар булалар тунны әйләндереп. Шулай кергәннәр төрлечә кийенеп, тунын әйләндергән, бүреген коләндергән битлек куйып битенә. Ул бит таныpлык та түгел, танымыйча каласың кайсысын-берсен. “Кунарга кертмисезме сез, караңгыга калдык”, — дип шайарышалар.

**Нардуган өйе.**

Нардуган көннәрендә җыелып утыру, йөзек салу һәм башка уеннар өчен дип, бер хуҗа хатын белән килешеп “сатып алынган” өй. Өй хуҗасына күпмедер бүләкләр яки ашамлыклар китерәләр.

Искә төште әле дуслар,
Кич утыру, йураулар.
Бер кичкә өй сатыгызчы,
Йук монда безнең ырулар.
Әргәннәрдә без уйнарбыз,
Бийербез дә җырларбыз.
Җөзек салып уйнарбыз,
Йазмышларны сынарбыз.

Хуҗабикә:
Аулак булыр өйебез,
Ойалмагыз, үтегез.
Җөзек салгачын, болай җырлап рәхмәт әйтәләр:
Рәхмәт өйнең хуҗасына
Күңел ачтырган өчен.
Алдагы тормышыбызда
Күзне ачтырган өчен.
Изге сулар сибәбез дә,
Өйгә кайтып китәбез.
Киләсе раштуwада да
Без килербез, көтегез.

**Җөзек салу** — нардуган йолаларының иң көтеп алып, күмәклән җыелып башкарыла торганнардан берсе.

— Нардуганда әниләрдән качып кына җөзөк саладыр ыйык, җегетләр шунда керергә ойалалар ыйы элек, тыңнап кына торалар ыйы мунча кырында.

Әрле дә бирле борыла-сарыла,
Кызлар җөри килән сарырга.
Кызлар җөри килән сарырга,
Җегетләр җөри җөзөк салырга.

**Җөзөк салу өчен су алып кайту.**

— Җөзөк салырга, су алып кайтырга өч кеше бара. Иң башта туган бала, урта туган бала, иң соңгы туган бала барырга тийешләр. Су алырга төшкәндә, тимер әйбер тотып төшәләр. Ттимердән җен-пәриләр курка, имеш.

— Кисәү агасына атланып төшәләр ийе.

— Кулына балта тотып төшә.

— Кусыр [<рус. кесарь] пычагы (ягъни чыра пычагы) тотып төшәләр икән.

— Кисәү агачына атланып бәкене әйләнәләр.

— Бер дә эндәшмичә төшәргә, эндәшмичә менәргә.

— Суга кач кылып ала балта белән (ягъни кач сурәте ясап суга сызып ала).

— Суны түбән таба каратып ала, агымга каршы алмыйлар.

**Җөзөкләрне сулы чиләккә салалар.**

— Шул җөзөкләрне сулы чиләккә салалр да берәү бутап тора, чылдыратып утыра берәү.

**Җыру әйтү, нардуган такмагы әйтү.**

— Җөзөк салганда, һәрбер кешегә җыру чыга. Кемдә җыру? Берәү җыруны әйтә. Җөзөкне ала да, бу кемнеке? дип бирә. — Җәшләр инде кийәүгә китәрем микән, картлар инде үләрем микән дип салалар. Сугыш багытында тол хатыннар да җөзөк салырлар ыйы.

**Җөзек салу җырулары.**

Басу капкасын чыкканда,
Карадым кайырылып.
Илем, суым, дус-ишләрем
Калды миннән айырылып.

Нугайдан (елга исеме) су алып кайтып йөзек салганнар, бутаучы булган йөзекне. "Кемнеке бу йөзек?" дип ала. "Минеке, җыр миндә", ди. Сугыш ԝакытларында ирем кайтыр микән, малайым кайтыр микән дип салалар.

Тубал гына тубал он утыра
Барысы да бодай оннары.
Тугайланып кына сызылып киткән
Туганайның кайтыр җуллары, — дип чыга теге кешегә.
"Кайта, малайың кайта", — дип, җакшыга җурыйлар шуны.
И син үзең, син үзең,
Кашыңнан кара күзең.
Пар сандугач сайраган күк
Синең сөйләгән сүзең.
Алларын да алырсың,
Гөлләрен дә алырсың.
Кодай сиңа шулай җазган —
Йегетеңә барырсың.

— И, җегетең җарата икән сине диләр ийе, шундый җакшы җырулар чыгар ыйы.

И илдегез, илдегез
Исәнләшә белдегез.
Мәкнең ал чәчәге кебек
Күземә күрендегез.
Матур гына чәчәк ата
Өй алдындагы гөлләр.
Чәчәк аткан гөлләр кебек
Булсын алдагы көннәр.

— Бу кем йөзеге?

— Ә, синеке, йегетең килә икән бүген, диләр.

Күл өстендә ата үрдәк,
Ата булса, ат инде.
Сиңә йәрләр бетте инде,
Пич башында йат инде.
Иске мунча почмагы,
Ана кусыр пычагы, ди.

— Шундый усал җырулар да чыккалады усал кызларга, үзенә күрә инде җыруwы да туры килә.

Сандугачым, былбылым,
Кичә кайларда булдың?
Дөнҗә бәйләрен биреп
Сатып алырдай булдым.

— Җакшыга җурыйлар, җегетең сине көтә, диләр.

Чүлмәк-чүлмәк сары бал,
Ашыйсыңнар килсә, wатып ал.
Кайчаннар да булса мин синеке,
Ашыкмыйча гына көтеп ал.

— Китап ачкандай, туры киләләр шул җырулар. Ул шул нардуган эчендә генә, унике көн була ул.

**Тын тыннау, тынга чыгу** — нардуган көннәрендә тыңлап йөреп күрәзәлек итү, юраулар. Тынга чыкканда, *кисәү агачы, балта, пычак* алганнар, ягъни җен-пәриләрне куркыту өчен тимер әйберләрен алып чыкканнар.

— *Кисәү агачларына* атланып утыралар да, нардуган эчләрендә тынга баралар.

— *Күзне йомып утырырга* икән, өч кеше барса.

**Беленү -** тынга баргач нинди дә булса тавыш килеп хәбәр бирү.

— *Беленгән* инде, нәрсә дә булса таwыш килгән.

“Ачмагыз күзегезне, алдамагыз, берең ачса да, дөрес беленми”, — дигәннәр.

**Балта белән кырие** [<рус. прееей] **сызып** тын тыннау.

— Үземнең әби сөйлидериде. Шулай кисәү агачына атланып утырып, өч кеше киттек тыннарга, ди. Үзе, ике энесе. Балта алганнар, кисәү агачлары, пычаклар булган кулларында. Шулай *балталар белән кырие* сызып, кисәү агачына атланып утырабыз, ди. Менә бер беленде бер таwыш, тагын бер беленде ди, сикереп тордом ди. Бер эт тора ди. И курыктык, чыр-чу килеп,

басу киртәсенә килеп җыгылдык ди. Элек бит басулар киртә белән тотылган булган.

**Өй турысына килеп тын тыннау.**

— Өй турына киләләр ийе. Менә мин нәстә сөйләнеп утырам, тынныйлар ыйы да җурыйлар ыйы.

**Аwыл башына чыгып, җиргә йатып тын тыннау.**

— Нардуганда аwыл башына чыгабыз да җатабыз җиргә. Икмәк уңарлык булса, *әйбер тийәгән таwыш* киләдер ийе. Икмәк буласы җыл булмаса, *коры арба таwышы* киләдер ийе.

**Баш очына койы йасап куйу.**

— Нардуган көннәрендә баш очыбызга шырпыдан койолар йасап куйадыр ыйык. Менә шул шырпы койоны баш астына куйып, мендәр астына инде, таралмаслык итеп куйып җөкларга җатасың.

“Су килсен дә,

Шул килсен”, — дисең.

Бер кеше атын тотып су эчертергә килә. Шул кеше әбизәтелни синең җегетең була. Нардуган эчендә генә бу. Җырлый-җырлый килә бу кеше, атын эчертә.

**Көзгегә карап күрәзәлек итү.**

— Көзге утыртып, ике җагына шәм җага. Шул көзгедән күренә имеш. Ул куркыныч та булган. Җанына ук килсә, шайтан булып баса ди. Җә күз алмашкандыр инде. Көзгедә күренсә дә, ул кешене килеп үтерә алмый бит инде, ә чир тийәргә мужыт.

— Көзгедән карау бар, ну анысы куркыныч. Сугыштагы кешеләрне исән-сау гына кайтырмы дип карыйлар. Тик бер җиреңдә бер *төтен булмасын, чәчең сүтелгән булсын*. Өстәлгә куйалар көзге, шул көзгегә карап торалар. Бер дә дәшми, арты белән чыга. Утырган кеше аны чакыра, ул әйләнә. Әйләнсә, ул исән була.

— Көзгегә карый да утыра төнге сәгать уникедә. Чәче сүткән, бер кат күлмәктән. Колагында алка булмасын, беләзек-йөзек булмасын, тәне чичта булсын.

— Ә инде берсендә гыруп күренде, бер күрдем мин. Теге кеше үлгән булды, кайтмады.

**Сарык тотып күрәзәлек итү.**

— Җөзәк салу беткәчен, сарыклар почакларга чыгадыр ыйык. Ак сарыкмы эләгә, кара сарыкмы, йәш сарык эләгәме, карт сарык эләгәме. Карт сарык эләксә, картка китә, йәш сарык эләксә, йәшкә китә имеш. — Ә без таwыклар тотадыр ыйык, ак таwык эләгәме, кара таwыкмы.

**Раштуwа** [<рус. рождество].

— Раштуwа бәйрәмендә нардуган башлана, кийенеп чыгалар. Әллә нәстәләр кийенеп чыгалар ыйы. Алама-салама кийәләр. Тунны әйләндереп айу булып, шайтан булып чыгалар ыйы. Кайсы чиган катыны булып йөри, күрәзәлек итә. Дәмәклек (кызыклык) өчен шулай йөриләр ийе.

Раштуwаның бураны, бураны,

Туңа микән бәкесе, бәкесе.

Аулагига барган ыйым, барган ыйым.

Шыгырдады сәкесе, сәкесе

**Раштуwада шишәрә** (бавырсак) **пешерәләр.**

— “Менә раштуwа җитте, шишәрә пешериг әле, бәрәннәр күп булыр”, — диләр ийе. Элек менә сарыкны күп асырыйлар ыйы.

Чистай сөйләшеннән (Әлмәт районы Елхово авылында) язып алынган **раштуwа йолалары** һәм йола сүзләре дә борынгылыкның чагылышы буларак кызыклы.

**Раштуwа көннәре** килеп җиткәндә, кешенең эрләнгән, әзерләнгән җебе булырга тиеш дигәннәр.

— Раштуwа кергәндә, киләп йасарга кушалар, ницек булса да, бер киләп йебең булсын. Йәтрәк киләп йаса диләр.

**Раштуwа булып керү** — төрлечә киенеп, маскарад ясап керү.

— Раштуwа булып кереп йөриләр ийе, кемнең кергесе кели. “Кайа киләбең? — диләр. Йәше дә, карты да була. Сәләмәрәк кийемнәргә кийенәләр. “Йебең бармы, киләбең бармы?” — ди, булмаса суктыра. “Ник йерләмәдең, ник әзерләмәдең? — дип.

**Раштуwада йуwаца (баwырсак) пешерәләр.**

— Раштуwада пицтә йуwаца пешерә. Йуwацаны баwырсак кебек кисә. “Сарыклар күп бәрән бәрәнләсен”, — дип пешерә.

— Йуwача пешертәләр ийе раштуwада, сарыклар күп булсын дип. Иләккә сыдырасың да, шыны пицкә тәгәрәтәсең, сарыкларга ашатасың. Йәнәсе, ырыштуwа бәрәннәр күп була дигәннәр.

— Раштуwада малларга йуwаца ашатканнар, куш-куш йуwаца (пар-пар йуwача) ашатканнар. Йарма иләккә салып йуwацаны тәгәрәтеп, цокырлы цумар кебек йасап салганнар.

— Куш йуwаца ашатсаң, сарык ике теше (ана) бәрән бәрәнли ди, сыйыр теше бозау (тана бозау) бозаулый ди.

**Керәшеннәрдәге кач ману йоласы.** Кач ману — 19 январьда була, ул христиан дине буенча крещение көненә туры килә. **Кач > хач** фарсы теленнән кергән сүз. *Кач ману* (‘крещение’) йолалары төрле ырымнар һәм ышанулар белән үрелеп барган.

— Элек шулай Нугай (елга исеме) суына төшеп, бозны кисеп, кач сурәте йасаганнар. Шул качны тотып, су буйларын әйләнгәннәр, иманнаштырганнар. Качны суга манып, шул суны алып кайтабыз да җыябыз, ул тәмсезләнми. Эч пошканда, йә аwырып китсәң, шул суны эчеп куйасың.

— Сәгәт уникедә төшәбез без кийәнтә-чиләкләр белән шул суны алып кайтырга.

— “Алла бабай мангандыр инде качны бездән дә алда”, — дийешә-дийешә алабыз суны.

— Безнең артта гына чишмә, шуңа төшәбез кач маныргa. Шунда барып, чукынып, җуынып, шунда битләр җуып кайтып китәбез. Шул су җыл буйы тора, мал чирләсә дә, үзебез чирләсәк тә кирәк була.

— Нардуганда җөргән кешеләр, кач манганда, чыгып чишенеп, өсләренә су койалар.

**Кач манган су — изге су дип имгә** тоталар.

— Пуминкыда иң алдан, ипи капканчы, шул кач манган суны кабабыз, ике кашыкмы, өч кашыкмы. Шул суны өшкереп эчәбез.

— Унтугызында кач ману була, анда инде иман укучылар бәкегә барып кач манып кайталар. Ул суны алып кайтып, өйдәге тәреләрне, качларны

йуwалар. Шул су белән чәй куйып чәй эчәләр. Кач ману суы белән күз тигәннән йуwалар. Кач манган суны кабып пуминкыда тәберсе итәләр.

Биредә авыл халкының үзеннән сөйләтеп язып алынган материаллар җирле сөйләш үзенчәлекләрен саклап, гадиләштерелгән транскрипция белән бирелде. Әлеге йолалар һәм аларга караган сүзләрнең күпчелеге өлкән буын кешеләренең хәтер сандыгында гына саклана. Шуның өчен алар халык традицияләрен һәм телнең сүзлек байлыгын, фольклорын өйрәнү юлында рухи-мәдәни мирас буларак теркәп калдырылырга хаклы дип уйлыйбыз.

*Д.И. Умеров,*
ведущ. науч. сотр. ГЦТФ

## *Фольклорные пляски астраханских татар: проблемы исследования, сбора и сохранения*

Хореографическое искусство астраханских татар обладает богатой историей и культурой. В Астраханской области несколько этнических групп астраханских татар: юртовские татары (раньше их называли кара ойле, т.е. живущие в чёрных домах), кундровские татары, карагаши ногайцы (кара агаш переводится как чёрное дерево),[1] средне-волжские татары-мишари и казанские татары-переселенцы, живущие в селе Линейное с начала XIX века.

Одни из самых древних и самобытных этнических групп астраханских татар – это юртовские, кундровские татары и карагаши ногайцы.[2] Истоки их восходят к группе ногайцев золотоордынского происхождения, к периоду возникновения Астраханского ханства. Кочевой образ жизни способствовал взаимовлиянию и взаимообогащению с культурами тех народов, с которыми имелись контакты, т.е. народами Северного Кавказа, Калмыкии, средне-волжскими татарами-переселенцами. В отличие от кундровцев и карагашей, юртовские татары, приняли осёдлый образ жизни много раньше. Впервые термин «jurt» упомянут в записях путешественника Христофера Берроу в XVI веке в связи с пожаром, возникшим в поселении ногайцев, расположенном неподалёку от Астраханского кремля.[3] Это первое свидетельство об осёдлом образе жизни юртовцев, а кундровцы и карагаши в то время ещё были кочевниками. В 1745 году губернатор и исследователь В.И. Татищев писал: «По взятии Астрахани царь Иван Васильевич повелел оставшихся и ушедших от хана мурз и чёрных татар сесть при Астрахани в службу и сим назвать юртовые».[4] Юртовские татары, кундровцы и карагаши хоть и имеют один корень происхождения, существенно различаются не только по укладу

[1] Арсланов Л.Ш. Язык карагашей-ногайцев Астраханской области / Л.Ш. Арсланов. - Набережные Челны, 1991. (по последним исследованиям Л.Ш. Арсланова, кундровские татары и карагаши - это разные этнические группы).
[2] Гмелин С.Г. Путешествия по России / С.Г. Гмелин. - Ч.2. - СПб., 1777.
[3] Небольсин П.И. Очерки Волжского Понизовья / П.И.Небольсин. - СПб., 1852.
[4] Татищев В.И. Научное наследство. Записи. Письма / В.И.Татищев. - М., 1980.

жизни, быту, но и по языковым диалектам и традиционной одежде. «Без нугай татарлар» - «Мы ногайские татары», - говорят они о себе.

Данные этнические группы уже привлекали к себе внимание исследователей, этнографов, историков, филологов и фольклористов. Особо выделяются в этом аспекте труды астраханского историка и этнографа В.М. Викторина,[1] С.Т. Рахимова, филологов Л.Ш. Арсланова,[2] Ф.С. Баязитовой,[3] Ф.Х. Завгаровой,[4] музыковедов М.Н. Нигмедзянова, А.Р. Усмановой.[5] Однако наиболее неисследованной на карте культурогенеза Астраханской области была и остаётся традиционная хореография и, чтобы восполнить этот пробел, в Казани был выпущен сборник «Танцы Астраханских татар».[6] Это результат научно-полевых экспедиций 1995-1998 гг. по сбору песенно-плясового и игрового фольклора астраханских татар. Исследования проводились автором этих строк совместно с музыковедом и ведущим методистом ОМЦ НК А.Р. Усмановой. В ходе экспедиции выявлено 20 видов обрядовых, свадебных, необрядовых, игровых танцев и музыкального сопровождения к ним. Цель нашей экспедиции заключалась в записи и сохранении исчезающих плясок и игр.

Народная пляска астраханских татар, как и искусство любого другого народа, уходит корнями в глубокую древность. Характер исполнения во многом определяет уклад жизни и быта. Вот как в XVI веке описывает пляску астраханских татар историк и этнограф П.И. Небольсин: «… Вообще юртовские татары очень любят музыку и игры. Напевы их чрезвычайно приятны и гармоничны. Песни у них и богатырские, и эротические. Музыкальные орудия у мужчин – скрипки и балалайки, у женщин – варган и гармоники. Пляской занимаются только одни молоденькие девушки, и то не при посторонних мужчинах. Игры мужчин состоят из борьбы на кушаках, из поединков или ротоборства один на один, что называется быргебыр».[7] «Пляску карагашей нельзя назвать грациозной и увлекательной. Танцовщица, например, потупив глаза в землю, стоит на одном месте, потопывает ножками, поводит на стороны головкой и выделывает движения, которых тайного смысла решительно нет возможности доискаться; характер этих телодвижений есть кажется извращённость того, что в русской пляске носит характер приманивания. Мужская пляска состоит в тяжёлых скачках, в необходимом притом вскидывании руками, в отдувании щёк, в прикрякивании языком довольно неприятных звуков».[8] Здесь историк

---

[1] Викторин В.М. Кто мы, Астраханцы? У этнической карты области / В.М. Викторин // «Астраханские известия». -1994. - №10.

[2] Арсланов Л.Ш. Татары Нижнего Поволжья и Ставрополья / Л.Ш. Арсланов. - Набережные Челны, 1995.

[3] Баязитова Ф.С. Астраханские татары / Ф.С. Баязитова. - Казань: «Фикер», 2002.

[4] Завгарова Ф.Х. Татарская литература Астраханского региона в историко-культурном контексте XIX – начала XX вв. / Ф.Х. Завгарова. - Казань: «Магариф», 2003.

[5] Усманова А.Р. Сборник песен и наигрышей юртовских татар Астраханской области / А.Р. Усманова. - Астрахань, 1997.

[6] Умеров Д.И. Танцы Астраханских татар / Д.И. Умеров. - Казань, 2003.

[7] Небольсин П.И. Очерки Волжского Понизовья / П.И. Небольсин. - СПб., 1852.

[8] Небольсин П.И. Очерки Волжского Понизовья / П.И. Небольсин. - СПб., 1852.

[8] Усманова А.Р. Сборник песен и наигрышей юртовских татар Астраханской области /А.Р.Усманова. – Астрахань, 1997.

подчёркивает раздельность плясок между мужчинами и женщинами. В танцах астраханских татар, как и в любых фольклорных плясках, наиболее распространённые мизансцены - это круг и линии. В плясовых играх «Түгәрәк уен» - «Круговая игра», «Кичке уен» - «Вечерние игры» присутствуют сольное и парное исполнение, причём «эстафетной палочкой» для передачи соло другому исполнителю служат два платочка. Каждое соло сопровождается, тут же сочинёнными речитативными репликами – такмаками.

Ана шулай бер бэлай, биеп торы бер нугай.

Перевод:

Вон как кое-как, пляшет стоя один нугай.

Такмаки – речитативные реплики произносятся как распевно, на определённый мотив, так и речитативным выкриком. Громкое произнесение такмаков приводило к определённому интонированию в объёме малой терции.[1]

В парных танцах между мужчиной и женщиной, стоя лицом к лицу или обходя её сзади, мужчина не мог коснуться женщины, развернув руки в стороны, как и в кавказских танцах.

Как известно из истории, по территории Астраханской области пролегал "шёлковый путь" и, безусловно, это взаимодействие разных народов наложило свой отпечаток на фольклор астраханского народа. Многие пляски, игровые сюжеты в фольклоре астраханских татар имеют аналоги в хореографическом фольклоре других народов: танец казанских татар "Атна", дагестанская "Тамара", кавказская "Лезгинка", калмыцкая "Шарка-барка", "Калмык бию". Причём заимствованные танцы совсем не похожи на оригиналы и исполняются в манере присущей астраханским татарам под звуки зажигательной саратовской гармошки, бубна (Кабал), иногда скрипки.

Доктор педагогических наук А.С. Каргин пишет: «В фольклоре профессиональные мастера черпают не только вдохновение, но и богатство выразительных средств, под влиянием фольклора формируется национально-художественный менталитет композитора, художника, поэта… Профессиональная сцена заимствует представления народных гуляний, потешек, оформительские штампы, клише из ярмарочных представлений, народные костюмы, обувь, одежду. Эти элементы проникают и в «серьёзные жанры»: оперу, симфонические пьесы, балет. Вероятно, способы заимствования фольклора будут и далее трансформироваться, видоизменяться, идти как по линии открытого, прямого использования, так и переосмысления общеэстетических принципов и художественных средств. Этот процесс разнообразен и таит в себе множество творческих открытий и находок».[2] В подтверждение слов Анатолия Степановича, композитор, лауреат государственной премии Республики Татарстан Ш.К. Шарифуллин, написал прекрасную музыку на основе фольклорных записей. А в репертуаре Государственного ансамбля песни и танца есть «Танец с пиалами» на фольклорном материале астраханских татар. В фондах Государственного центра татарского фольклора РТ хранится богатейший фольклорный

---

[2] Каргин А.С. Народная художественная культура / А.С. Каргин. - Москва, 1997. - С.274.

материал, которым пользуется для своих постановок фольклорный ансамбль Государственной филармонии. Я надеюсь, что и мои записи помогут балетмейстерам, композиторам для сценического воплощения этих танцев.

Обо всех видах плясок астраханских татар рассказать сразу будет трудно, поэтому приведу пример наиболее интересных, на мой взгляд, плясок астраханских татар.

*ОБРЯДОВЫЕ ПЛЯСКИ*

*(свадебные)*

Танец «Кияусый» или «Кияу сылы» означает чествование жениха, исполняется исключительно на свадьбах. Обряд сохранён до сегодняшних дней. За неделю до свадьбы у дома жениха родители невесты ставили шатёр, приглашая чествовать родственников жениха. До этого жених уже должен быть отдать калым по обоюдному согласию и два раза послать поднос с конфетами. Жениху нельзя было участвовать в строительстве шатра, «дамсез булады» говорит информатор Н. Мухтаров, что означает «будет не сладок для родителей невесты». В назначенный вечер свадебный поезд жениха продвигается к праздничному шатру. Несмотря на сильный мороз или жару, жених, заставляя себя ждать, шел медленно «акрен гена басып киля», - говорит информатор. Неизменный атрибут жениха – подарки для родителей невесты, обвязанные красной лентой. У шатра невеста подхватывала жениха под руки и заводила в шатёр. Жених, делая вид, что не хочет, сопротивлялся, и тогда его заносили на руках под наигрыш «Кияусый». Все гости проходили в шатер, где исполнялся одноименный танец. Кияусый относится к сольному танцу. Темп танца быстрый. Танец могут исполнять как мужчины, так и женщины. У других народов такой наигрыш не встречается и отсюда следует, что этот танец принадлежит юртовским татарам.

Музыкальное сопровождение, как и во всех танцевальных наигрышах астраханских татар, саратовская гармошка (саз), бубен (кабал), иногда скрипка. Музыкальный размер 4/4. Образуя большой круг, каждый по очереди, передавая платочки как эстафетную палочку, выходят в центр круга и пляшут «Кияусый». Все остальные, подбадривая, хлопают в ладоши в такт ритма музыки и выкрикивают такмак. Такмаки – речитативные реплики, в них отражается юмор, народная мудрость и игровой характер. Например, «узен гена биисен безга яулык бирмисен» - «сам пляшешь, а мне платок не передаёшь». Как правило, все обрядовые танцы танцуют с широко раскрытыми руками, особенно в мужских танцах. Высмеивались те, кто танцевал с опущенными руками, «сынган канатлы каз кебек булып бииде» - «пляшешь, словно гусь со сломанными крыльями», - говорит информатор З. Махмудова. Существовала определённая этика плясок. Нельзя было долго плясать, не передавая никому платок. Танец начинал и заканчивал, как правило, тамада праздничного вечера, выбранный хозяевами. Чтобы закончить танец, тамада обходил круг и отдавал платочки гармонисту.

Ике кул яулыгына – башынын саулыгына,
Эна шулай катырак, берда торма аптырап.
Бас иданнен уртасына – дошманнан куркасынма?

Перевод:

Два платочка в руках, повернись на каблуках,
В круг смелее поспеши, недругов перепляши.*

Следующий свадебный танец «Ак Шатыр» в переводе означает Белый Шатёр или Белая Юрта. Есть такое выражение АК ТУЙ в переводе Белая Свадьба, то есть чистая свадьба или свадьба молодоженов. Для проведения свадеб у астраханских татар ставили и поныне ставят в некоторых сёлах большой шатёр. Его помогают строить друзья и родственники жениха. «Ак Шатыр» как наигрыш встречается и у кундровских татар, и у карагашей. Музыкальный размер меняется от 4/4 до 3/4. У М.Н. Нигмедзянова зафиксирован вариант в размере 12/8. Нами записаны несколько вариантов этой пляски. У некоторых исполнителей была манера танцевать, положив один из платочков на плечо: «жилькасена яулык салып торып бииде», – говорит информатор М. Умерова. В танце «Ак Шатыр» руки широко разведены в стороны, спина неизменно прямая как у наездника. Руки попеременно сгибаются в локтях, но не опускаются вниз, размахивая платочками из стороны в сторону, в зависимости от темпа и ритма музыки, которую задаёт сам танцор. Главная особенность состоит в том, что все движения при стремительном ходе вперёд, назад, в сторону исполняются без прыжков и подскоков. «Это сейчас, – говорит информатор Сайфулла бабай, молодёжь танцует вприпрыжку, подражая казанским татарам, а раньше тяжёлый костюм не позволял прыгающих движений».

Тамада – тархан определял место и время для плясок, выходил на середину шатра, поднимал руку вверх, держа красные платочки и выкрикивая «Ак Шатыр», звучали заразительные звуки саза. Тархан обходит по кругу шатёр и приглашает 3 или 4, 6, 8 девушек в зависимости от размера шатра. Те девушки, у которых оказывались красные платочки, выходили на середину шатра, и кружились в танце вокруг тархана. Затем по знаку тархана девушки расходились по разным углам и приглашали сидящих мужчин на танец. Тархан, наблюдающий за исполнением танца, взмахом платка давал знак гармонисту, и танец прекращался.

Сез икегез, икегез, икегезнен битегез,
Сез икегез пар кильгәнсез, тигез гомер итегез.

Перевод:

Вместе целое одно, словно чарка и вино,
Жениху и невесте – пусть пройти по жизни вместе.*

*ОБРЯДОВЫЕ ПЛЯСКИ*

*(календарные)*

Праздник «Джиен» в переводе означает сборы и проводится между несколькими соседними сёлами, где завязываются знакомства, возникают симпатии, устанавливается дружба между юношами и девушками. По рассказам информаторов, особая роль на Джиенах отводилась Джиен агасы, что в переводе означает глава сбора, ведущий, известный также под названием «Тархан». Тарханом выбирали только особо почитаемого и уважаемого молодого человека – жителя одного из сёл, в обязанности которого входило открытие и закрытие вечера, контроль за поведением джигитов и девушек. Родители доверяли девушек тархану, за которыми он приходил с группой юношей. С ним девушек отпускали и на другие праздники. А если впоследствии девушка выходила замуж в другое село, жених дарил подарки родителям невесты и тархану в благодарность за его сельчанку. Возможно, отсюда и пошёл ритуал из свадебного цикла. Тархан

открывал вечер танцем, осуществлял выбор танцующих пар. Вечер закрывался лишь после выкрика тархана – «таркау».

Әйлән, түгәрәк, син буларсын күбәләк.

Әйләнеп, әйләнеп, йөрмәсеннәр бәйләнеп.

Йөрсәләр бәйләнеп, син карама әйләнеп.

Перевод:

В хороводе мотыльком кружись-

Парни льнут кругом.

Даже не взгляни на них-

У тебя, ведь, есть жених.

Танец «Рекрутов» также можно отнести к обрядовой пляске, исполняемой на проводах в рекруты. По своему происхождению он столь же древний, как и пляски «Ак шатыр» и «Кияусый». Характер носит тип прощального танца с молодецкой и беззаботной жизнью. Юртовские татары селились вокруг астраханского кремля и должны были служить в рекрутах. Юноша опоясывался зелёным кушаком и выходил в центр круга, акцент на главном участнике - рекруте. Девушка, которой нравился рекрут, бросала в него монеты. Затем юноша изображал, как он отважно сражается и скачет на лошади. Вообще у юртовских татар обряд бросание мелких монет существует до сих пор, в основном на свадьбах. Этот обряд означает плодородие и богатство. Детям разрешают собирать монеты, приговаривая «сезга да ющь булсын» - «пусть и у вас будет так же». У карагашей бросают пшено или другие зёрна.

*НЕОБРЯДОВЫЕ ПЛЯСКИ*

У юртовских татар «Куалашпак», у карагашей «Куаласып бию», в Наримановском районе говорят «Куалашып бию». Название танца произошло от слияния двух слов ногайского диалекта астраханских татар «куалап» – прогонять, «кашеп» - убегать, дословно – гнаться за убегающей или соревнование. Аналогов подобного танца нигде нет, и поэтому можно считать, что пляска «куалашпак» астраханского происхождения.

Танец предполагает двух участников – юношу и девушку. Догонять может не только юноша, но и девушка, если она чуть расторопнее и хитрее своего партнёра. По виду пляска относится к молодёжным играм и исполняется на посиделках и молодёжных играх. Смысл танца сводится к следующему: девушка танцевальными движениями завлекает парня, заставляя тем самым его гоняться за ней по кругу. Причём молодой человек должен проявить в пляске всю свою удаль и мастерство. Только таким образом, настигнув партнёршу по танцу, он получал от неё платочек. Далее молодые люди менялись ролями. Затем «эстафету» принимала другая пара. Положения в паре, можно сказать лицом к лицу с раскрытыми руками в стороны, как бы не пуская друг друга. Причём руки, исполняли роль, как бы шлагбаума, под которым пытались проскользнуть. «Куалашпак» могли танцевать как на праздниках Майдан, Амиль, так и на играх «Кичке уен», «Тугәрәк уен» и т. д.

Танец «ЩУГАЛЯП». Информаторы рассказывали, что в старину на свадьбы приглашали танцоров, которые владели всеми плясками и вели развлекательную программу вечера. Среди таких танцоров был мой дед Мухарям-ата. Он танцевал с пиалой на голове, предварительно налив в неё жидкость. Мастерство состояло в том, чтобы в процессе исполнения не

проливалось ни капельки, при стремительном движении по кругу, вперёд, назад и, даже вращаясь на месте. Затем содержимое пиалушки выпивалось. Танец требовал прямой непременной осанки, как при посадке на лошади. Танец исполняется на мелодию «Щибаля» или «Щуранге». Подобный танец встречается у калмыков и называется «Шаазнта би».[1]

Музыкальный размер 6\8.
Кызлар:
Айлан тугарак, син буларсын кубаляк.
Айлянеп, айлянеп, йормасеннар байлянеп.
Йорсаляр, байлянеп, син карама айлянеп.
Матур итеп биисен, куз тияр, дип бельмисен.
Матур итеп биюче – биючена сиюче.
Сикереп, сикереп ерактагы иптащене
Куз алдына кильтереп.
Вагдале буена чакырырсын туена,
Чакырмасан туена – бурыч булар муена.
Якын дустым булсын гына, вагданда торсан гына.
Матур, матур чачак атсын синен баскан эзлярена
Бас, дустым, эзена, куз тимасен узена.
Егетляр:
Ике кул яулыгына - башыннын саулыгына.

В конце исследования я сделал вывод, что при своевременном и более тщательном сборе можно было бы с лёгкостью выявить намного больше фольклорных танцев астраханских татар. При записи и сборе мы испытывали некоторые сложности, заключавшиеся в том, что многие информаторы и гармонисты не помнили названия некоторых мелодий, плясок и игр, а старожилов, которые могли бы рассказать и показать не было в живых. Огромную помощь оказывали директора школ и домов культуры, которые бережно хранили в стенах учреждения старые бабушкины тетради, записи аудиокассет 70-х годов, старинные вышивки, костюмы и бытовую утварь. Большой вклад при сборе фольклорных игр и танцев внесла астраханская поэтесса М.Х Умерова.

*Н.Д. Мусина,*
доцент кафедры хореографии КГУКИ

## *Хореографический фольклор татарского народа – наиболее приоритетное направление образовательного и научного комплекса в области культуры и искусства Республики Татарстан*

[1] Бадмаева Т.Б. Калмыцкие танцы и их терминология / Т.Б. Бадмаева. – Элиста, 1992.

Хореографический фольклор татарского народа – одна из ярких составляющих его культуры, искусства и творчества. В нём языком татарского танца запечатлён характер и темперамент этноса, его этические и эстетические взгляды, художественное, творческое мышление, особенности традиций и обычаев. Как национальный танцевально-пластический язык, татарский танец, также важен и значим для народа, его истории, культуры, искусства, национального самосознания, как родной разговорный, вокальный, музыкально-инструментальный языки. На языке татарского танца «говорит» многочисленный народ, проживающий на огромной территории России, СНГ, дальнего Зарубежья, т.е. далеко за пределами административных границ РТ, обозначающей центр тюркских этнических групп под наименованием – татарский народ. Несомненно, у каждой их этих групп своё «наречие» - особые краски, которые создают удивительную мозаику татарского танца, выделяя татарский народ своеобразием, неповторимостью среди других народов. Однако изучение, сохранение, развитие хореографического фольклора – одна из наиболее актуальных, нерешённых и не решаемых проблем в Республике Татарстан.

Хореографический фольклор татар, он же танцевальный фольклор или традиционный татарский танец является основным предметом такого научного направления как хореографическая фольклористика. В Республике Татарстан данное направление исследований отсутствует, танцевальный фольклор татарского народа не изучается ни в Институте языка, литературы и искусств им. Г.Ибрагимова, ни в Институте истории, ни в Республиканском научно-методическом центре, ни в Академии наук Татарстана. Возможно, его изучение начнёт Государственный центр татарского фольклора РТ. Сложившееся положение позволяет предполагать, что руководство республики и руководители данных научных учреждений не знают или не понимают, игнорируют или пренебрегают развитием хореографической фольклористики. Отсутствие научной лаборатории коллектива учёных – этнохореографов по исследованию танцевального фольклора, действующей на постоянной основе, лишает будущие поколения не только информации о танцевальном языке народа, но способствует уничтожению его историко-художественной памяти и кризису в профессиональном искусстве татарского танца и национального балета.

Необходимо подчеркнуть, что именно на основе хореографического фольклора создавался репертуар Государственного ансамбля песни и танца РТ, знатоками танцевального языка татарского народа, балетмейстерами, сочинявшими авторские хореографические произведения, многие из которых стали классикой татарского сценического искусства, а традиционный танец народа получил достойное развитие на профессиональной сцене.

Обращаясь к истории вопроса, нужно отметить, что начало изучению фольклора татарского народа было положено 75 лет назад в бывшем Советском Союзе. По инициативе Совнаркома ТАССР в 1931 году была организована первая комплексная фольклорная экспедиция в районы Татарии. В составе шести человек, представителей основных видов искусств был и хореограф, впоследствии, первый татарский балетмейстер Гай Тагиров, столетие которого мы отмечаем в нынешнем 2006 году. Он, как и весь состав экспедиции, не был профессиональным учёным, но вклад его в

хореографическую фольклористику татарского народа значителен. Монография «100 татарских фольклорных танцев» (1), подготовленная Г.Х. Тагировым - результат многолетней кропотливой работы по расшифровке и записи материалов этнографических экспедиций XX столетия, первый опыт фиксации традиционного татарского танца. Представленные в ней образцы дают возможность прикоснуться к традиционному танцу татар не только Татарстана, но и Пермской, Оренбургской областей, Урала и Сибири. Не смотря на то, что записанный в ней фольклор является только верхним, поверхностным слоем, представляет небольшое число примеров, относительно масштабов необходимых ежегодных исследований, не сопровождается научным анализом, он незаменим в настоящее время другими источниками. Данная монография является раритетом, её нет на прилавках магазинов, ею не могут воспользоваться специалисты хореографии в республике и других регионах.

Первые шаги, положительные для науки о хореографическом фольклоре татар, были предприняты в 80-е годы К.М. Бикбулатовым (2). Они отражены в научных статьях по материалам фольклорных экспедиций в Приуралье, Татарстан, Мордовию и Марий-Эл.

Сегодня, как это ни печально, можно констатировать, что Республика Татарстан по отношению к хореографическому фольклору татарского народа, проживающего в самой республике и татарских диаспорах, отстаёт на десятилетия от Белоруссии, Турции, на сто лет от Венгрии. В этой стране, как ни в какой другой, серьёзно относятся к хореографическому фольклору, удивительно продуманно выстроив систему обеспеченности изучения, сохранения, развития, бытования в народе национального танца. Все, необходимые для её работы структуры, начиная с административного аппарата страны, работают согласованно, с пониманием значимости танцевального языка народа для новых поколений, для памяти о творчестве венгров, для информации, обращённой к жителям вселенной. Ориентируясь на достижения Венгрии в хореографической фольклористике, понимая проблемы данного научного направления в нашей многонациональной Республике Татарстан, необходимо принимать экстренные меры для изменения сложившейся ситуации.

<u>Поднять на должный уровень наиболее запущенную и наиболее сложную научную сферу в области культуры и искусства, обеспечить масштабы предстоящей работы можно, на наш взгляд, объединив усилия профильных образовательных и научных учреждений республики, при полноценном их финансировании, при контроле администрации и президента РТ.</u>

Важнейшими задачами для развития научного направления «хореографическая фольклористика» и обеспечения его специалистами, имеющими навыки и знания ведения научной работы, и применения их на практике являются следующие:

- разработка взаимосвязанных учебных планов и программ по татарскому танцу для всех уровней хореографического образования: а) детская школа искусств (ДШИ), б) училище культуры и искусств, в) университет культуры и искусств, д) институт дополнительного

профессионального образования (ИДПО) - институт повышения квалификации;

- установление тесных взаимосвязей вуза и научного учреждения, при котором работает или должна работать Отраслевая научно-исследовательская лаборатория татарского танцевального творчества.

Полный спектр учебных заведений с хореографическими отделениями обозначен нами не случайно. Он объясняется сложностью задач, стоящих перед поколением, которое будет обеспечивать собирание, изучение, сохранение, развитие, бытование традиционного татарского танца – национального языка народа. Чтобы подготовить необходимые условия для выполнения этих задач нужно, прежде всего, разработать программы по курсу «Татарский танец» для многоуровневого хореографического образования, ввести его, в качестве обязательной дисциплины, в учебный процесс. Содержание программ должно позволить учащимся: поэтапно овладевать языком татарского танца, от фольклорного до сложного сценического; ознакомиться с особенностями танца различных этнических групп; освоить систему записи и постановку танца по записи; получить опыт учебной научной работы и практической – экспедиционной, а также навыки обработки танцевального фольклора и сочинения на его основе авторских произведений.

Необходимость работы коллектива учёных-этнохореографов и Отраслевой лаборатории продиктована огромным объёмом работы для этнохореографов и многокомпонентностью танца, который уже на первом этапе сбора и его фиксации, наряду с кропотливой работой специалистов танца, нуждается в работе музыковеда, этнографа, исследователя устного фольклора и других учёных. Хореографический фольклор, несомненно, требует комплексного подхода к научной работе о нём, поскольку бытование танца в народной среде неразрывно связано с музыкальным сопровождением, песней, инструментальной музыкой, с национальной одеждой, с праздниками, обрядами.

Анализ роли и места татарского танца в образовательных учреждениях РТ свидетельствует о том, что в настоящее время, ни фольклорный танец, бытующий в республике и татарских диаспорах, ни сценический татарский танец, ни история хореографического искусства Татарстана:

- не обеспечены интегрированными программами для всех уровней образования;
- не изучаются или изучаются крайне мало в качестве обязательных учебных дисциплин;
- не осваиваются как национальный язык на должном уровне для исполнительского искусства, для сочинения авторских произведений;
- не являются предметом научной работы.

Изменить существующее положение в образовании Республики Татарстан, можно, на наш взгляд, обеспечив разработку интегрированных программ по курсу «Татарский танец» для всех уровней образования. Первым шагом в этом направлении должна быть программа для хореографических отделений детских школ искусств, которая послужит базовой основой при

подготовке программ для средне-специального, высшего образования, для ИДПО. Она может использоваться в национальных гимназиях, лицеях, диаспорах народа, проживающих вне административных границ региона, обеспечить работающих педагогов-хореографов и учебный процесс необходимым документом.

Основная часть содержания курса «Татарский танец» должна включать два раздела: фольклорный танец и народно-сценический танец. В качестве учебного материала их можно сопроводить литературными источниками, подготовленными татарским балетмейстером Г.Х. Тагировым. Первая книга «100 татарских фольклорных танцев» содержит примеры традиционного народного танца, они доступны уровню подготовки учащихся младших классов, их запись достаточно легко может «читаться» преподавателями. Вторая - «Татарские танцы» (3) представляет авторские работы Тагирова Г.Х., которые являются универсальной основой для постижения профессиональных требований к исполнению сценического татарского танца, для понимания принципов сочинения форм народной хореографии.

Обращение к данным литературным источникам необходимо для знакомства со стилистикой, тематикой танца прошлой эпохи, для изучения творчества народа и сочинений балетмейстеров – композиторов танца, для наиболее эффективного использования минимума, имеющейся литературы, для обеспечения труда преподавателей основным материалом, для получения знаний, которые должны пополняться на следующих уровнях хореографического образования.

Программа для ДШИ, т.е. нормативный документ для первого уровня образования, должен рассматриваться в качестве основной системной структуры для следующих - трёх ступеней хореографического образования. Если Министерство культуры или Министерство науки и образования РТ, обеспечит разработку, издание данного документа, оснастит им все районные центры и города, это позволит начать полноценную одновременную работу по курсу «Татарский танец» в школах республики.

Для продуктивного решения вопроса о подготовке специалистов по изучению и развитию танцевально-пластической речи татарского народа необходим следующий шаг - основание кафедры татарского танца – новой структуры в высшем образовании РТ. Основная её задача - готовить специалистов для всех уровней образования, способствовать постепенному накоплению знаний и навыков ведения научно-исследовательской работы и применения их на практике. Учитывая, что Республика Татарстан является историческим центром Среднего Поволжья и Приуралья, её административные границы, кроме татарского народа - титульной нации, включают представителей соседних республик, сотни лет проживающих в едином союзе, изучение национальной самобытности хореографического фольклора татарского народа потребует исследований танцевального творчества: русских, удмуртов, чувашей, мордвы, марийцев, башкир. Следовательно, учебные планы кафедры важно привести в соответствие с этнорегиональными особенностями республики.

В качестве мер со стороны управления РТ, способствующих подготовке педагогов, учёных, руководителей, организаторов, специалистов по изучению и преподаванию татарского фольклорного и сценического танца,

положительно влиять на функционирование и развитие его в народе, можно отметить такие, как издание или переиздание:

- сборников фольклорных танцев,
- репертуарных сборников сочинений балетмейстеров,
- монографий по истории хореографического искусства РТ.

В образовательном комплексе (ССУЗ, ВУЗ, ИДПО) эти меры могут быть обеспечены следующей системой основных учебных дисциплин:

- татарский фольклорный танец;
- татарский народно-сценический танец;
- история хореографического искусства татарского народа;
- запись танца;
- постановка танца по записи;
- этнография татарского народа и народов Среднего Поволжья и Приуралья;
- история изобразительного и прикладного искусства, одежды и сценического костюма татар;
- фольклорная практика в Республике Татарстан, России, СНГ, в регионах компактного проживания народа;
- учебная научно-исследовательская работа по итогам фольклорной практики, после обработки материалов полевых экспедиций,
- производственная практика по выявлению носителей традиционного танца, по организации фестивалей фольклорного танца, стимулирующих интерес к бытованию его в народе,
- композиция и постановка танца на основе фольклорной и сценической хореографии,
- информатика с компьютерными программами: текстовый редактор, графический редактор, художественный редактор, музыкальный редактор.

Задачи фольклорной и производственной практики, т.е. полевой экспедиционной работы с носителями фольклора, обеспечивающими научно-исследовательскую деятельность студентов и учёных-фольклористов основным материалом, отличаются сложностью, зависимостью от помощи отделов культуры на местах. Они должны быть ориентированы на неё, подготовлены к ней своими навыками и знаниями, оснащены аудио и видеоаппаратурой, компьютерной техникой и т.д. Среди основных задач отделов культуры по изучению хореографического фольклора необходимо выделить такие, как:

- выявление носителей (знатоков) танцевального фольклора;
- подготовка базы данных о носителях фольклора, её обновление и пополнение;
- запись на видео и аудиокассеты бытующего в народе обрядового и внеобрядового танца, его музыкального, вокального сопровождения;
- паспортизация танцевального фольклора района;
- организация фестивалей традиционного танца.

Защитить выполнение выделенных нами задач – обязательной части научной работы на местах, не предусмотренной должностными обязанностями работников культуры, необходимо дополнительным, полноценным её финансированием и повышением квалификации специалистов в ИДПО. Отсутствие постоянных исследований татарского танца в РТ требует масштабного одновременного охвата всех её районов для эффективного выполнения первых шагов в научных изысканиях хореографического фольклора.

Необходимо обратить внимание на то, что в настоящее время нет более запущенного и более сложного научного направления в области культуры и искусств РТ, чем хореографическая фольклористика, потому наиболее приоритетного, требующего особого внимания к его образовательному и научному комплексу со стороны правительства и президента Татарстана.

Изучение татарского танцевального фольклора – художественно-исторической памяти народа является важнейшей задачей не только для науки, но и для перспективы развития национального хореографического искусства. Без постоянных исследований многое уже утрачено и возможны дальнейшие потери для истории, культуры, искусства народа. Во-первых, потому что особенности такого национального языка как танец требуют физических сил молодёжи, способной представить его полноценно и ярко. Во-вторых, его богатство быстро уходит вместе с носителями фольклора, людьми преклонного возраста, как ушли древние обряды, праздники, а вместе с ними удивительные образцы художественного творчества народа. В-третьих, традиционный народный танец неотделим от профессионального искусства танца, его создателей – балетмейстеров, различных жанров хореографии, начиная с классического балета и завершая новым современным направлением – танцем модерн. Общеизвестно, что не может писатель, не владеющий татарским разговорным языком, создавать татарские литературные произведения. Так же не может балетмейстер, не владеющий татарским танцем, сочинить татарский танец или балет.

Нужно отметить, что сегодня, именно народный танец вызывает интерес в европейских странах, утративших свою национальную хореографию, именно народный танец способствует созданию неповторимости стиля, национальному «акценту» в танце-модерн, чем привлекает внимание специалистов России, СНГ, дальнего Зарубежья. Татарский народ может быть узнаваем и интересен для других народов, удивляя своеобразием национального языка – татарского танца, который в профессиональном искусстве должен отличаться яркостью, виртуозностью, артистизмом. Основа же профессионального искусства танца в хореографическом фольклоре народа, в его творческой лаборатории, о чём свидетельствуют тысячелетия человеческой истории.

## Литература

1. Тагиров Г.Х. 100 татарских фольклорных танцев / Г.Х. Тагиров. – Казань: Таткнигоиздат, 1988.

2. Тагиров Г.Х.Татарские танцы / Г.Х. Тагиров. – Казань: Таткнигоиздат, 1984.

3. Бикбулатов К.М. Традиционные предсвадебные танцы приуральских татар / К.М. Бикбулатов // Традиционный и современный фольклор Приуралья и Сибири. – М., 1979; Татарские традиционные досвадебные танцы // Сцена и время. – Казань, 1982; Традиционная танцевальная культура татарского народа, проживающего в Марийской и Мордовской АССР (по итогам полевых исследований 1982 г.) // Этническая история тюркоязычных народов Сибири и сопредельных территорий. – Омск, 1984; Нардуганский цикл традиционных танцев-кряшен // Искусство Татарстана: пути становления. – Казань, 1985.

*Ф.Г. Ризванова,*
Кукмара районының Зур Сәрдек
гимназиясенең югары категорияле укытучысы

## *Бәетләрдә халык язмышы*

Халык авыз иҗатына халыкның гасырлар буенча буыннан буынга җыелып килгән рухи байлыгы, тормыш фәлсәфәсе, көнкүреш тәҗрибәсе һәм эстетик зәвыгы тупланган. Без һәм киләчәк буын аларны җентекләп өйрәнәбез, өйрәнәчәкбез, алардагы эстетик ләззәтне югалтмабыз. Билгеле, халык иҗаты әсәрләренең барлык жанрларын да бергә туплап бер фәнни системага салу эшенең башы – аларны язып алу. Шушы максаттан чыгып, Кукмара районы Зур Сердәк гимназиясендә “Халык иҗаты – акыл байлыгы” дигән фәнни-әдәби түгәрәк эшләп килә. Түгәрек эшчәнлегенең башында халык авыз иҗатын җыю, туплау белән шөгыльләнгән галимнәр, язучылар, мәгърифәтчеләр – Хәмит Ярми, Нәкый Исәнбәт, Каюм Насыйри, Гомәр Башировлар һ.б. турында фәнни хезмәтләр тупланды.

2002 елда Кукмара районында оештырылган конфереция вакытында районның укытучылары Татарстанның Мәдәният министырлыгы каршында эшләп килүче Татар фольклорын җыйнау, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау үзәге галимнәре һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгатъ институты фәнни хезмәткәрләре белән таныштылар. Галимнәр Зур Сәрдек гимназиясендә булып, түгәрәк эше белән танышып киттеләр. Бу вакытта халык авыз иҗатын җыйнау белән генә шөгыльләнгән укытучыларга галимнәр җыйналган материалны алга таба төркемләү юнәлешен күрсәттәләр. Бу турыда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгатъ институтының фәнни хезмәткәре, филол. фәннәре канд. Лилия Ибраһимова “Мәдәни җомга” (5 июль, 2002) санында язып та чыкты. “Кукмара авылларында йөргәндә, халык иҗатының бүгенге көндә дә мул сулы чишмә булуына янә бер кат инандык. Саекмый да, саегырга да җыенмый әле ул. Тарихыбыз битләрен, халык тәҗрибәсен, акылын, тел җәүһәрләрен һ.б. хисапсыз хәзинәләрен ияртеп, ага да ага” дип язды галимә. Чыннан да, бу шулай.

“Халык иҗаты – акыл байлыгы” түгәрәгенең оешуына инде 7 елдан артык. Шушы вакыт эчендә түгәрәк әгъзалары тарафыннан 350 бәет, 135 җыр-такмаклар, 13 легенда, 18 риваять, 228 мәзәк, 9 әкият тупланды. Аларның һәрберсе сөйләүчеләрдән аудиотасмага теркәлеп, текстологик эшкәртелде. Фольклор үрнәкләрен җыю белән беррәттән төбәкнең сөйләм стиле, фонетик, лексик системасына хас үзенчәлекләр билгеләүгә мөнәсәбәтле эзләнүләр дә алып барылды. Мондый эшләрдән тыш, түгәрәктә халык иҗаты үрнәкләренең тулырак варианталарын барлау эше дә алып барыла. Мәсәлән, халык авыз иҗаты җыетыкларына кертелгән “Комсомолец Рәхи бәете”нең 1990 нчы елда Мәмәшир авылында яшәгән (инде хәзер мәрһүм) Миңнемуллина Фагыйлә ападан язып алган вариантын алыйк.

Безнең вариантта бәетнең дәвамы бар, һәм ул түбәндәгечә:

Минем калган киемемне кемнәр киеп туздырыр,
Янып сөйгән Миңсылуым, ничек гомер туздырыр.
Аклы ситса күлмәгемне туздырганчы кимәдем,
Миңсылуым сине күреп күзләремдин туймадым.
Биек тауның башларына кибән салдым киртәләп,
Җаным-бәгърем, туя алмадым сине иркәләп.

Мондый эзләнүләр халык авыз иҗатының яшәеш даирәсен чамаларга һәм көнкүрештә үзгәрешен күзәтергә мөмкинлекләр бирә. Ул гына да түгел, татар халкының лиро-эпик жанры булып исәпләнгән бәетләр, тарихи күзаллау булдыруда да актив роль уйный. Чөнки һәр бәет татар халкының язмышы, чынбарлыгы белән бәйле. Бу нисбәттән караганда, түгәрәктә катнашычулар тарафыннан халык язмышын күзалларлык әсәрләр күпләп тупланды. Моның өчен яшь фольклорчылар махсус сораулыклар әзерләп, җәй көнендә күрше авылларда эзләнү эшләре оештыралар. Шунда олы яшьтәге апа-абыйлар белән очрашып, бәетләр, аларның язылу тарихларын барлыйлар. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышында 4 улын югалткан Нәбиуллина Өммегөлсем әбигә багышлап чыгарылган бәетне алыйк. Нәбиуллина Өммегөлсем апа Чишмәбәш авылында яшәгән. Аның 4 улы Әһлиулла, Ярулла, Сәгыйдулла, Самат сугышта һәлак булалар. Бу бәет Өммегөлсем әбинең оныгы, хәзерге көндә Башкортстанда яшәүче, укытучы Сания апа Нәбиуллинадан язып алынды.

Әлеге бәеттә газиз балаларын югалткан ананың тирән кичереше, кайгы-хәсрәтләре гәүдәләнә.

Әһлиулла улым, иң олысы минем
Председатель иде авылда.
Дошман илгә кергәч, башлап китте,
Үзе теләп дошман явына.

Шул ук вакытта горурлык хисе дә, илен сакларга теләүче батыр егет образы да тулы гәүдәләнә. Ил афәте – халык афәте.

Яше-карты бар да эшкә чыга,
Фронт өчен эшлик диелә.
Атлар җитми, һәрбер хуҗалыкның
Сыерлары эшкә җигелә.

Әлеге юлларда фронт фаҗигасе дә, тыл фаҗигасе дә күрсәтелә.

Үсеп кенә килгән тал чыбыктай
Сәгыйдулла бигрәк яшь иде.
Ат өстендә дошман куам дигән,

Зәйтүнгә язган, көт мине.

Зур һәм фаҗигале тарихи вакыйгаларның аерым кешеләр язмышындагы чагылышы халык күңелендә тирән эз калдыра.

Төнлә уйлап, таңда уйга калам,

Каршы алам көн дә ал таңны.

Дүрт улым,  Сез яуладыгыз аны,

Онытмас дим, Сезне Ватаным, - дип тәмамлана бәет.

Күренеп тора, бәеттә лиризм шатый көчле бирелгән. Сугыш  дәһшәтен, халык хәсрәтен чагылдыручы бәетләр шактый. Алар арасында Мәмәшир авылында яшәүче  Миңсылу апа Ярмиевадан язып алынган бәет тә бар.

Бисмиллаһи вә билләһи,

Җитте корбан гаете.

Без әйтәбез, сез тыңлагыз

Ватан сугышы бәетен.

Без сугышка киткәндә,

Ерак калды арабыз.

Безнең хәлне сорасагыз,

Бу бәеткә карагыз.

Бәет аерым кешеләргә багышланмаган, киресенчә, әлеге афәтнең  халык фаҗигасе икәнлегенә басым ясала.

Соңгы елларда иҗат ителгән бәетләрне барлаганда, шундый фикер туа: татар халкы бәет жанрын һаман кулланылышта йөртә, хәсрәт-кайгыларын уртаклашучы буларак янәшәсенә бастыра килә. Ләкин әлеге фикер рәтендә икенчесе дә туа. Ул халык яшәешенең  аянычлы, фаҗигале булуы. Аның баш очында эчкечелек афәтенең һаман сакта торуы. Татар кешесенең, бигрәк тә яшь ир-атларның дөнья гүзәллеген, рәхәтен аракы, шәрәбка алыштырып, фаҗигагә дучар булуларын һәр авылда чыгарылган дистәләрчә бәет дәлилли. Шуңа күрә дә бәетләрне  халык көнкүреш елъязмасы буларак та бәяләп була. Хәзер шуларны күзәтеп үтик.

1995 нче елда Алан авылында булган фаҗига күпләрне тетрәндерә. Озак та үтми Гыйләҗев Раифка багышлап чыгарылган бәет район газетасында дөнья күрә. Бәет Мәүҗидә әби тарафыннан (1923 нче елгы) латин хәрефләре белән язылган.

Улым, синең шушы  матаең

Юлдан чыгып читкә киттеме?

Әллә инде явыз җаннар килеп,

Синең газиз башыңа җиттеме?

Улым сорыйбыз синең иптәшеңнән,

Сөйлә дибез ничек булганын.

Явыз җаннар ахры куркыттылар,

Яшерә алар нәрсә кылганын,  дигән юллар бар.

Көрәшче, гармунчы Раифны юк итү нигә кирәк булган соң? Биредә, 90нчы еллар бәетләрендә сурәтләнгән халык күңеленең бер явыз сыйфаты – көнчелек турында  әйтелә. Көнчелекнең  сәбәбе – уңганлык, булганлык, парлы мәхәббәт.

Эзлим сине шулар арасыннан,

Сине эзләп күзләрем талды.

Шәкертләрең дә, синең дусларың да,
Сине яратып сөйгәнең калды.

Нәкъ шундый үлемгә дучар булган Зур Сәрдек егете Динарга багышлап сеңлесе Хисмәтуллина Римма (X сыйныф укычысы) “Динар бәете”н яза. Бәет сюжетына нигез итеп, Мәчкәрәгә кичке уенга төшкәч, Динарның бу авыл егетләре тарафыннан пычак белән чәнчеп үтерелүе алына.

Мәчкәрәнең болыннары
Хәтфәдәй яшел иде.
Иптәшләремне үгетләдем:
“Әйдәгез, төшик инде”.
Шул Мәчкәрә болынында
Чыкты минем җаннарым
Хәтфәдәй яшел үләнгә
Чәчерәде каннарым...
Сөлектәй егет чагымда
Җир астына керттеләр…

Бәеттә сурәтләнгән тар күңеллелек, көнчелек – фаҗигагә китерүче сәбәп буларак аңлатыла. Әсәр авторы  ул сәбәпләрне халык фаҗигасе итеп сурәтләргә тырыша.

Алда ассызыклаганыбызча, XXнче гасыр ахыры яшәешенең фаҗигасы – эчкечелек. Түгәрәкчеләр тупланмасында фаҗигага багышланган бәетләр зур урын алып тора. Мәсәлән, катып үлгән һәм бары тик ике айдан соң гына табылган Наил абый бәете.

Чыкты авылым халкы,
Кар өстеннән атлыйлар.
Ятам бакча артларында,
Мине эзләп тапмыйлар.

Бригадир яхшы иттең,
Бульдозерны җибәреп.
Ничек чыкмый калганмындыр,
Калагына ияреп.

Халык үзенең бөтен булганы белән илдә, дөньяда барган һәр күренешкә бик сак һәм сизгер тора һәм саклык, сизгерлекне бәетләрендә чагылдыра. Игътибарга тагын бер бәетне алыйк. Ул Россия армиясе сакларына алынып, андагы тәртипсезлекләр корбанына әйләнгән Хәмзә исемле егет фаҗигасына багышланган.

Һәркем тели сине зурларга.
Армиядә тәртип булмаганга,
Җыенмыйбыз сине хурларга.
Хакыбыз юк сине хурларга.

Шушы ук теманы Байлангар авылында яшәүче Фәйрүзә ападан язып алынган “Альберт бәете” дәвам итә.

Кабер өсте чәчәк кенә
Кулыма ала алмыйм.
Минем белән ни булганын
Беркемгә сөйли алмыйм.

Язмышмы бу, тәкъдир микән
Гомерем кыска булган.
Күбәләк тә тиңен эзләп,
Кабер ташына кунган.

“Халык иҗаты – акыл байлыгы” исемле түгәрәкнең бәетләр тупланмасында фаҗигалы үлемгә дучар булган яшь сабыйларга, бәхетсез мәхәббәт корбаннарына, тугърылыксыз хатын аркасында үзен кая куярга белмәгән, үз-үзенә кул салырга мәҗбүр булган ирләргә багышланган бәетләр дә бик күп. Югарыда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, түбәндәге фикерне җиткерергә мөмкин. Татар халкының үлмәс әдәби жанры – бәетләр халык язмышы елъязмасы вазифасын үти, аның вәкилләренә гыйбрәт сөйләп, үгет-нәсихәт, әхлак нормаларын тәкъдирли.

**Әдәбият**


1. Бәширов Г. Тормыш юлында: повесть – истәлек. Публицистик мәкаләләр / Г. Бәширов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. - 383 б.
2. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 2 томда / К. Насыйри. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1974. - 339 б.
3. Тарих мең дә сигез йөздә: Бәетләр, мөнәҗәтләр. - Казан: Мәгариф, 2000. - 159 б.
4. Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1983. - 350 б.
5. Хуҗиәхмәтов Ә. Мәгърифәт йолдызлыгы / Ә. Хуҗиәхмәтов. – Казан: Мәгариф, 2002. - 278 б.



*З.Н. Җиһаншина,*
Кукмара 2нче урта мәктәбенең
югары категорияле укытучысы


## ***Якташ язучылар иҗатында фольклор элементлары***

Әдәбиятта фольклор элементларын куллану төрле яссылыкларда бара. Каләм ияләренең халык авыз иҗатындагы теге яки бу әсәрнең сюжетын, персонажларын, баба образларны, тел-сурәтләү чараларын, сюжет-композиция алымнарын укучыга материалны җиткерү юлларында файдалануы турында сүз алып барылды. Фольклор элементларыннан файдалану максатчан да, табигый рәвештә дә бара, чөнки халык иҗатыннан үсеп чыккан әдәбиятның һәрбер формасы фольклор жанрлары белән тыгыз бәйләнештә, аларның эзлекле үсеш нәтиҗәсе булып тора. Прозада, эпик шигърияттә кулланылган фольклор элементларын табу укучылар өчен зур авырлык тудырмый. Әйтик, әкиятнең башламына, тәмамланышына охшаган урыннар, дини-мифологик образлар, моңа кадәр таныш сюжетлар, кече

формалар саналган мәкаль-әйтемнәр һәм җырлар аларның игътибарын шунда ук җәлеп итә.

Кукмара районында туып үскән һәм бүгенге көндә татар әдәбиятында әйдәп баручы көчкә әверелгән каләм ияләре байтак. Докладта һәр шагыйрьгә махсус тукталу мөмкин түгел, шунлыктан без игътибарны әдәби тәнкыйтьтә һәрвакыт игътибар үзәгеннән читтә калып килүче якташыбыз Рифә Рахман иҗатына юнәлтсәк, дөресрәк булыр дип саныйбыз.

Фольклор элементлары матур әдәбиятның эчтәлегендә дә, формасында да чагылыш таба. Форма күчемлелегенә мисал итеп, шигъри калыпларны китерергә мөмкин. Рифә Рахман поэзиясендә төрле үлчәмнәр очрый. Алар арасында фольклордан килгәннәре дә бар.

Син мине яратмыйсың дип,
Туйдым битәрләвеңнән.
Һәм сине аттым сызып ук
Күңелем дәфтәреннән, - ди шагыйрә.

Төрки поэзиянең килеп чыгуын өйрәнгән М.Х. Бакиров хезмәтләрендә дә 8-7 үлчәмендәге җырларны очратырга мөмкин:

Зәңгәр һава, зәңгәр болыт
Зәңгәрләтә диңгезне,
Зәңгәр һавалардан эзлим
Бик сагынганда сезне.[1]

Шигырь калыплары турында сүз йөрткәндә, Р. Рахман шигъриятендә ирекле формаларның шулай ук киң кулланылуын, аларның бигрәк тә "Ничек хәлләрегез?", "Кемнеке?", ""Яшьлек дәфтәре"ннән" тибындагы сюжетлы әсәрләр өчен сайлануын әйтеп узарга кирәк. Х. Госман, Ф.И. Урманчеев һәм М.Х. Бакиров кебек галимнәр фикеренчә, ирекле форма бик борынгы заманнардан ук килә, димәк, фольклор әсәрләребезгә хас.[2] Шушы рәвешчә фикер йөртеп, без башка уртак үлчәмнәрне дә барлый алыр идек.

Шагыйрә еш кына рифма калыпларын да фольклордагыча ала. Татар халык авыз иҗатында көйле текстта һәр юлны охшаш яңгырашлы тәмамлау, шуның белән әсәргә санау интонациясе бирү гадәти бер күренеш, ә кайвакыт халыкның сүз осталары, өч юлны үзара яраштырып, берсен үзенчәлекле калдырганнар. "Әйтелмәгән уй" шигыре, мәсәлән, ааба рәвешендә рифмалаша:

Узар юлчы, ник кулыма кагыласың?
Беләм, беләм, син кемнедер сагынасың.
Минем кара күзләремә карыйсың да,
Кем күзләрен күргән төсле абынасың? (Шук алма, моңсу алма)

---

[1] Бакиров М.Х. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары / М.Х. Бакиров. - Казан: Мәгариф, 2001. - Б. 272.

[2] Бакиров М.Х. Иң борынгы шигырь нинди булган? / М.Х. Бакиров // Казан утлары. - 2005. - №2. - Б.161; Госман Х. Яшьләр һәм остазлар / Х. Госман // Казан утлары. - 1978. - №5. - Б.153-162; Курбатов Х. Татар әдәбиятында ирекле шигырь / Х. Курбатов // Метод, стиль, жанр. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. - Б. 12-30; Урманчеев Ф. И. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь / Ф. И. Урманчеев // Казан утлары. - №6. - Б. 129-141.

Без шагыйрьләр кулланган эпитетларның, шул исәптән төсләрнең поэтикада куллану тарихын тикшерсәк тә, фольклорга барып чыгачакбыз.

Шагыйрә сагыш билгесен белдергән сары, мөселман халыклары өчен аеруча кадерле һәм, яшәрүне аңлатканда, телгә килә торган яшел төсләрне куллана, күңелдәге эчпошыргычлыкны күрсәтергә теләгәндә, сорырак, тоныграк буяларга мөрәҗәгать итә, әмма тышкы тәэсир көче зур булган, кайнар холыкны, хисләр җетелеген аңлаткан кызыл төс һәм антитезалы сурәт тудыру чараларыннан булган ак-кара аның иҗатында күбрәк очрый шикелле.

Халык авыз иҗаты - тел-сурәтләү чараларының төпсез коесы. Үзе галимә булган Рифә Рахман аларның килеп чыгышы хакында уйланган, ерак гасырларга барып тоташкан мәгънәләрен төгәл белә дип уйларга кирәк. Әйтик, шагыйрәнең лирик мине ялгызлык утларында янса, парын югалтса, аның әсәрләренә пар бәхет, пар ишкәк, көймә кебек сүзтезмәзләр, традицион образлар килеп керә.

Татар фольклорында көймә образы еш кына ялгызлык, юл эзләү мотивларын белдерә, Рифә Рахман иҗатында да күпчелек очракта бу шулай. Аның иҗатында килгән көймә образы гомер мәгънәсен аңлатырга да мөмкин:

Чалкан яткан карт көймәнең
Янында ятты оеп.
Таралган гомер көймәсе...
Кайда яр булган элек?
Таралган гомер көймәсе.
(Карт. Көймә)

Р. Рахман фольклорда мулдан кулланылган алма образын ярата. Әлеге төшенчә аның “Шук алма, моңсу алма” исемле китабының атамасына да кергән һәм, шагыйрәнең әйтүенә караганда, аның лирик минен, һәм хәтта шагыйрәнең үзен дә характерлаучы образ булып тора. Мәхәббәт темасы шагыйрә иҗатының төп юнәлешен тәшкил итә, шунлыктан без гөл-күбәләк, тирәк-былбыл, мәхәббәт бакчасы, ай-кояш кебек образлар белән еш очрашабыз, әмма алар шигырьдән шигырьгә төрле мәгънә йөге алып киләләр, төрле контекстларда урын алалар. Мисаллар китереп узыйк:

Ханымнарның мәгъшугы! Әй, сал колак!
Кызыйның гашыйклык дәрденә син бак!
Мәхәббәт бакчасының түрендә ул -
Атларга сукмак тапмый торган куак.
(Ханымнарның мәгъшугы // Сиңа)

Яисә:

Кун гөлемнең иң-иң матурына,
Бул былбылым минем түтәлдәге.
Син сайрасаң, җанны телеп-телеп,
Учларыма алып китәргәме?
(Былбылым бул // Сиңа)

Халыкта агачта калган соңгы алмага бәйле бәхет алмасы дигән гыйбарә бар, әсәрдән әсәргә шагыйрә аны гел яңача ача. Әйтик, без алманың мәңгелек түгеллеген беләбез, Рифә Рахман:

Бәхет татлы алма булса,
Таты җитсен гомерегезгә, - дип укучыларына үтмәс тәмнәр тели.

Яисә:

Татлы төш үтеп китәр дә,
Булмас күк яңадан ул:
Бакчада коеп йөрибез
Мәхәббәт алмаларын.

Җилкәләрне уйнаклатып,
Коела ул шып та шып.
Алмагачның юк ышыгы,
Торабыз кочаклашып
Бәреләләр авырттырып
Эп-эре бу тамчылар.
Мәхәббәтнең алмалары
Ява, ява камчылап...
(Шук алма, моңсу алма)

Китерелгән соңгы мисалдан күренгәнчә, шагыйрә образларны фольклор әсәрләрендәгечә абстракт мәгънәдә генә кулланмый, ике планлы итә, шунлыктан тәгаен бер күренеш сурәте дә барлыкка килә.

Шагыйрә иҗатында борынгыдан килгән Су кызы, Урман кызы, Шүрәле (Син кач миннән // Шук алма, моңсу алма), Пәри кызы (Айлану // Сиңа) кебек мифик образлар да, дини эчтәлектәге әдәбияттан килгән пәйгамбәр, шайтан, Алла, Адәм кебекләре дә еш очрый. Ул хәтта грек мифологиясендәге Руфь, Рафаэль кебек персонажларга да мөрәҗәгать итә, һәм аларның яшәү рәвешен, холык сыйфатларын, биографик детальләрен аерым геройларның психологиясен, тормышын чагылдыру өчен куллана:

О Руфь! Сине кешеләрне яратуның,
Изгелекнең чагылышы дип белгәннәр.
Гашыйк булган синнән күзен алалмаган,
Җан җылысы тапкан синнән сөелгәннәр.
(Шук алма, моңсу алма)

Рифә Рахман иҗатына бик оригиналь рәвештә мәкаль-әйтемнәр үтеп керә. Ул кайвакыт аларның бер өлешен халык авыз иҗатындагыча калдыра, ә икенчесен үзгәртә. Мәсәлән, "Балыкчының тамагы ач..."("Сиңа") шигырендә шул рәвешчә башланган мәкальнең икенче өлешен "ыштаны лач" дип язмый, ә "юп-юеш балаклары" формасында бирә.

Р.Рахманның кайбер әсәрләрендә халык ырымнары, ышанулары да чагылыш таба. "Бабай печән чаба", "Яр карлыгачлары", "Сәях җан" (Көзге төн күбәләге) шигырендә шундый юллар бар:

"Уф дигән шайтан булыр", дип,
Кабатлый: "Ухалла"сын.
һәм:
Елтыр кашык яткан ярда
Шактый гына эзләр бар.
Бездә: "Карлыгач көймәсен
Ватма!" - дигән сүзләр бар.

Шагыйрә фольклор әсәрләрендәгечә төш алымын яратып куллана. Ул, гадәттә, хәбәр бирүче төшләрне тасвирлый, һәм аның лирик мине көчле

интуициягә ия, ул төш ярдәмендә башкалар белән аралаша, киләчәкне белә, хәсрәт-кайгыларыннан бушана, үткәненә кайта ("Вәгъдә", "Син - гадәтем"...).

Рифә Рахманда халыкның начар мәгънәле юрауларын кире каккан әсәрләр күп, шуның белән ул, әйтерсең, лирик минен бәхетле итәргә, күңеленә рух өрергә тырыша. Кайвакыт шагыйрә ислам дине өйрәтмәләренә каршы килгән ырым, юрау кебек нәрсәләргә каршы фикерләрне турыдан-туры да уздыра:

Кипкән чәчәк киптерә дип,
Юрамагыз начарга.
Башларыма кайгы алып,
Сөймим фаллар ачарга.
Сөймим төшләр юраганны,
Сөймим сүзләр йөрткәнне.
Өзмәгез миңа дип гөл дә,
Кадерле бик кипкәне.
(Кипкән чәчәк - киптерә // Сиңа)

Әлеге әсәрдә шагыйрәнең лирик мине "юраганның юш килүе"ннән куркуын әйтә. Кайбер әсәрләрендә исә сихердән ырымнар ярдәмендә саклану юлларын да күрсәтеп бирә. Мәсәлән шундый эчтәлектәге "Сихердән саклан" әсәрендә ( Шук алма, моңсу алма) ул яктылык образларына, ягъни предметларына туры карап сихерләнү кебек ышану, чәч ярдәмендә әфсенләү кебек фольклор мотивларын, агар суны болгаткан таш кебек шигъри яңгырашлы гыйбарәләрне файдалана.

Әйе, шагыйрә тудырган иҗат халык мирасының бөтен матур якларын үзенә җыйган, аның йөгерек теленә ия, ә образларын үзенчә яңарта, аларга яңа заман яшьләренең күңелендә урын бирергә омтыла.

## Әдәбият


1. Бакиров М.Х. Иң борынгы шигырь нинди булган? / М.Х. Бакиров // Казан утлары. - 2005. - №2. – 161 б.
2. Бакиров М.Х. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары / М.Х. Бакиров. - Казан: Мәгариф, 2001. – 272 б.
3. Госман Х. Яшьләр һәм остазлар / Х. Госман // Казан утлары. - 1978. №5. - 153-162 б.
4. Курбатов Х. Татар әдәбиятында иректе шигырь / Х.Курбатов // Метод, стиль, жанр. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 12-30 б.
5. Урманчеев Ф.И. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь / Ф.И. Урманчеев // Казан утлары. - №6. – 129-141 б.


## Чыганаклар


6. Рахман Р. Шук алма, моңсу алма / Р. Рахман. - Казан: Таң-Заря, 1995. – 76 б.
7. Рахман Р. Күзләрең төймәләнсә / Р. Рахман. - Казан: Таң-Заря, 1995. - 152 б.
8. Рахман Р. Төнге кояш (Зөлфәтнең кереш сүзе белән) / Р. Рахман. -

Казан: Мәгариф, 1999. - 159 б.

9. Рахман Р. Керфекле тәрәзәләр / Р. Рахман. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2002. - 191 б.

10. Рахман Р. Коела йолдыз / Р. Рахман. - Казан: Гарт, 2002. - 152 б.

11. Рахман Р. Мине генә уйла (Роберт Әхмәтҗанның кереш сүзе белән) / Р. Рахман. - Казан: Мәгариф, 2003. - 127 б.

12. Р. Рахман. Сиңа! / Р. Рахман. - Казан: Мәгариф, 2003. - 160 б.

13. Р. Рахман. Болытка ятып йокласаң / Р. Рахман. - Казан: Прогресс, 2004.

Эчтәлек

**Төзүчедән**...........................................................................................

**I БҮЛЕК**...........................................................................................

*Җәүһәрова Ф.Х.*
Татар фольклоры дәүләт үзәгенең үткәне, бүгенгесе, киләчәге...................
*Урманче Ф.И.*
Борынгы традицияләрнең яңаруы...............................................................
*Гыйләҗетдинов С.М.*
Фольклор үзәге фондындагы гарәп, фарсы һәм татар телендәге кульязмалар
*Ганиева Д.Х.*
Милли һәм региональ компонент буларак мәктәптә фольклор традицияләрен саклау мәсьәләсе...........................................................................................
*Ханнанова Г.М.*
Соңгы елларда Татар фольклоры дәүләт үзәге фондын тулыландыру мөмкинлекләре...........................................................................................
*Арикеева З.М.*
Казан арты татарлары фольклорының бүгенге халәтен өйрәнү: проблемалар, тәҗрибә, перспективалар.........................................................................
*Гыйләҗетдинов И.С.*
XIV гасыр татар әдибе Мәхмүд әл-Болгариның “Нәһҗел-Фәрадис” әсәрендә һәм татар мөнәҗәтләрендә гомүмкешелек әхлак мәсьәләләре......................

**II БҮЛЕК**

*Бакиров М.Х.*
Шигъриятнең чишмә башына сәяхәт.............................................................
*Урманче Ф.И.*
Борынгы төрки-татарларда Тәңре................................................................
*Давлетшина Л.Х.*
Функциональный аспект образа Мудреца в фольклоре татарского народа....
*Арикеева З.М.*
Казан арты татарларының хәзерге йола комплекслары..................................
*Макаров Г.М.*
Возрождение традиционных музыкальных инструментов татар: проблемы и перспективы...........................................................................................
*Баязитова Ф.С.*
Чәчти очларында көмеш тәңкә....................................................................
*Баязитова Ф.С., Мухаметова Г.Ф.*
Татарстанның Кама аръягы сөйләшләрендә кышкы йолалар лексикасы һәм фольклор үрнәкләре.....................................................................................
*Умеров Д.И.*
Фольклорные пляски астраханских татар: проблемы исследования, сбора и сохранения...........................................................................................
*Мусина Н.Д.*

Хореографический фольклор татарского народа – наиболее приоритетное направление образовательного и научного комплекса в области культуры и искусства Республики Татарстан......................................................................
*Ризванова Ф.Г.*
Бәетләрдә халык язмышы.............................................................................
*Җиһаншина З.Н.*
Якташ язучылар иҗатында фольклор элементлары..........................................

**ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ**

**Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре**

**Татарское народное творчество**

**Научные исследования и фольклорные образцы**

**Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы**

**Сборник материалов научных конференций**

**Икенче китап**

**Вторая книга**

Составитель и редактор: Л.Х. Давлетшина

Дизайн обложки: Л. Леронова